# ШУРА

№ 34
2021



2000999959622

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . 5
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . 11

ВӘГАЗЬЛӘР . . . 15
Пәйгамбәребез юлыннан тайпылмыйк . . . 16
Галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән... . . . 23
Диндә ныклык сорыйк . . . 30
Күңел тынычлыгын табу . . . 36
Барыбыз да Аллаһы мәхлүкълары . . . 41
Мөселман – исламның көзгесе . . . 45
Биш нәрсәнең кадере . . . 52
Оятың булмаса – ни теләсәң, шуны эшлә . . . 56
Аяк кузгалмас көн . . . 60
Киң ризыклы булыйм дисәң... . . . 66
«Әдәпле надан тәрбиясез галимнән хәерлерәк» . . . 74
Җәһәннәм хакында . . . 79
Гөнаһ кылуның кайтавазы . . . 85
Никах кылу – җитди адым . . . 88

ҮРНӘК ЗАТЛАР . . . 92
Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе . . . 93

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . 97

ТАРИХ . . . 114
Фин татарларының «Тампере шәһәре Төрекләр җәмгыяте»н төзүе . . . 115
Швециядә төпләнүче беренче мөселман . . . 119
Швециядә беренче татарлар: мөселман татар җәмәгатьчелегенең барлыкка килүе . . . 122

МИРАС . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
«Татарларда – Ислам һәм каллиграфия сәнгате» . . . . . . . . . . . . 126

ФӘН . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Галимнәребезне тану һәм аларны хөрмәт
итү әһәмиятлелеге турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130

МӘҮЛИД . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Мәүлид бәйрәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Салават . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Җомга көн салаватлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148

ХӘДИС . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Кояш һәм ай тотылу бүлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Намазны кыскарту бүлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Тәһәҗҗөд китабы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
Мәккә (Әл-Харам мәчете) һәм Мәдинә (Пәйгамбәребез мәчете)
мәчетләрендә намаз укуның өстенлеге хакындагы бүлек . . . . . . 167

ТӘФСИР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Гозәер галәйһиссәлам кыйссасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170

НӘСЫЙХӘТ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Тәмугның рәвеше һәм тәмуг әһелләре бүлеге . . . . . . . . . . . . 178

ӘДӘБИ СӘХИФӘ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 192

**«ШУРА» дини альманах, №34**

*октябрь–декабрь 2021*
*рабигыль әүвәл-җөмәдәл-әүвәл1443*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕР:**
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Ленар Хамматов

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Илшат Хәйретдинов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*

*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 21.09.2021
Чыгу көне: 5.10.2021

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِي هَدَانَا لِهٰذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللّٰهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللّٰهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللّٰهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللّٰهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللّٰهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللّٰهِ۞ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللّٰهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللّٰهِ! ۞ اِتَّقُوا اللّٰهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللّٰهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللّٰهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ:

________________________________۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللّٰهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

______________________________ ۞

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللّٰهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللّٰهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللّٰهِ الْإِسْلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللّٰهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلّٰه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللّٰهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞

اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللّٰهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللّٰهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللّٰهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһү. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мүъминиинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыйҙү билләһи: ________________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________

____________________________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галлләәми, кәмәә кааләллаһу тәбәәракә вә тәгаалә филкәләәми. Вә иẓәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйẓү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәлләẓиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәруун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

---

1 Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын[1]. Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары, элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

**«Һичшиксез, Аллаһы – [гөнаһлардан] курыккан һәм [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

______________________________________________

[1] 3 тапкыр әйтелә.

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ____
________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез [Аллаһы тарафыннан] рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында [хакыйкый һәм кабул ителгән] дин – Ислам [дине генә]».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа ияручеләргә

сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

**«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгелә.

**Иң соңыннан, «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

**«Һичшиксез, Аллаһы [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] гадел булырга, изгелек кылырга һәм [бигрәк тә] якын туганнарга [мохтаҗ булган нәрсәләрен] бирергә [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] әмер итә. [Зина кебек] Фәхешлектән,**

**[көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] тыелганнан һәм [кешеләргә] җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*8 нче октябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Пәйгамбәребез юлыннан тайпылмыйк

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн. Галәмнәрне юктан бар итеп, безгә төрле нигъмәтләр, төрле ризыклар биргән, туры юлны, хәерле гамәлләр кылу юлын күрсәткән Аллаһы Тәгаләгә күңелебездәге барча хәмед вә сәналәр булса иде. Пәйгамбәрләрнең иң нурлысына, галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелмеш булган Расүли Әкрам Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават вә шәрифәләребез булса иде. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримне безгә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм аша иңдерә һәм безгә туры юлны табып, шушы Коръән белән, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте белән яшәүне боера. Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аша туры юлны күрсәтеп, безгә пәйгамбәрләр юлыннан, Аллаһы Тәгаләгә иң якын һәм иң хәерле булган кешеләр юлыннан барырга боерадыр.

Кешелек дөньясы төрледән төрле бәлаләр, авырлыклар, начарлыклар, куркыныч хәлләр белән даими очрашып тора. Галәмнәрдә Аллаһы Тәгаләгә карата иң беренче булып гөнаһ кылган зат – ул иблис шәйтан иде. Аллаһы Тәгалә безне аннан сакласын. Ул үзенең мин-минлеге сәбәпле, Адәм галәйһиссәламгә сәҗдә кылмады, сәҗдә кылудан баш тартты. Ахырда, Адәм галәйһиссәламне фетнәләп, аның җәннәттән чыгуына сәбәпче

булды. Ә соңында инде, Адәм галәйһиссәламнең ике улы арасында булган низагта, шулай ук вәсвәсә кылып, Кабилгә Һабилне һәлак иттерде.

Усаллык, золымлык һәрбер заманда да булган. Төрле вакытта аның исеме төрлечә аталган. Кызганычка, бүгенге көндә дә шушы начарлык һәм бозыклык безнең янәшәбездә яшәп килә. Бүгенге көндә аны экстремизм дип атыйлар, ягъни кешеләр динне, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйрәткән юлны дөрес аңламыйча, буталчык юлларга кереп, үзләренең киләчәкләрен, бүгенге көннәрен куркыныч астына куялар. Әйе, экстремизм дигән нәрсә чыннан да бар, әмма ул нинди генә исем белән аталса да, нинди генә дин астында, кайсы чорда барлыкка килсә дә, усаллык, җинаятьчелек – җинаять булып кала бирә. Хәтта ул үз исемен бик матур ислам исеме белән бутаса да, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйрәткән юл түгел. Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хакында Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَآ أَرْسَلْنَٰكَ إِلَّا رَحْمَةً لِّلْعَٰلَمِينَ ﴿١٠٧﴾

**«[Расүлем!] Без сине [җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп] бөтен галәмнәр өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107

Икенче бер аятьтә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

لَّقَدْ كَانَ لَكُمْ فِى رَسُولِ ٱللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ لِّمَن كَانَ يَرْجُوا۟ ٱللَّهَ وَٱلْيَوْمَ ٱلْءَاخِرَ وَذَكَرَ ٱللَّهَ كَثِيرًا ﴿٢١﴾

**«Сезнең өчен [бигрәк тә] Аллаһыга һәм Соңгы көнгә өмет баглаган һәм [курку, теләү, муллык һәм тарлык кебек бөтен хәлләрендә] Аллаһыны күп итеп искә алган кешеләр өчен Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмдә күркәм үрнәк бар».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:21

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең тормыш юлы үрнәгендә башка диндә, икенче бер милләттән, башка төрле уй-фикердә булган кешеләргә карата нинди мөнәсәбәт булырга; нинди гамәлләр кылырга; алар белән сату-алу һәм башка мөнәсәбәтләрне ничек булдырырга; аларга карата нинди караш булырга тиешлеген безгә ачыктан-ачык күрсәтә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәтта үзенең ишек төбенә чүп атып киткән кешеләргә дә мәрхәмәтлелек белән карый торган булган. Аларга беркайчан да орынып, начар сүзләр әйтеп, начар гамәлләр кылмаган. Беркайчан да үзенә дорфа дәшкән кешеләргә дорфа итеп җавап кайтармаган. Аның динендә булмаган кешеләргә ул нәфрәт белән карамаган. Әгәр дә берәр кеше аның кебек фикерләмәсә, ул кешегә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм беркайчан да начарлык белән кычкырып, аны мыскыл итеп түбәнсетмәгән.

Әгәр дә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлын карасак, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне күпме генә рәнҗетсәләр, күпме генә кыерсытсалар да, ул бер кешегә барып та: «Син минем динемне мыскыл иттең», – дип сукмаган, рәнҗетмәгән, кыерсытмаган. Беркайчан да башкаларга: «Сезнең динегез дөрес түгел. Сез мәсхәрәле кешеләр», – дип аларга ярамаган сүзләр әйтеп каты бәрелмәгән. Киресенчә, аларга ягымлы караш белән, яхшы сүз әйтеп, күркәм мөгамәлә кылып яшәргә тырышкан.

Без – мөселманнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Мөселман шул кешедер – кешеләр аннан беркайчан да курыкмаслар. Үзләренең малларын, җаннарын, тәннәрен, милекләрен иминлектә, дип хис итәрләр». Ягъни мөселман булган кеше беркайчан да гайбәткә, начар сүзләргә, начар гамәлләргә, мыскыллауларга, җәберләүләргә күчмәс. Киресенчә, ул бик мөлаем итеп аралашырга тырышыр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм намаз укыган вакытта аның өстенә дөя эчәкләрен һәм башка төрле нәҗесләрне ташласалар да, ул беркайчан да алар белән дорфа сөйләшмәгән. Киресенчә, мәрхәмәтле булырга тырышкан. Үзенең оныклары белән дә һәрвакыт көләч йөзле булып, шатланып алар белән уйнаган. Әгәр дә начарлыкны күрсә, ул матур итеп, хикмәт белән әйтә белгән. Ислам дине тынычлык, матурлык һәм күркәм дин буларак таралды. Коръәни Кәримнең беренче булып иңгән аяте дә «Укы!» дигән сүз белән башлана, ягъни Раббыбыз безне гыйлем алырга чакыра. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә гыйлем туплап, шушы юлда үзеңнең малыңны кызганмыйча укырга, тырышырга, хезмәт куярга кирәк икәнлеген һәрвакытта да ассызыклаган.

Бервакыт бер көрәштән кайткач, сәхабәләре бик нык сөенгәндә, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Без кечкенә көрәшне җиңдек, әмма алдыбызда иң зур яу бар». Сәхабәләре бу сүзләргә гаҗәпләнеп, Аллаһының Расүленнән: «Нинди яу соң ул? Моннан да көчлерәк яу була аламыни?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип җавап биргән: «Әйе. Әле алдыбызда иң зур яу бар. Ул да булса – нәфесебез белән көрәшү». Нәфесебезгә каршы тору, нәфесебез теләгән начарлыкларны булдырмау, ягъни һәр мөселманның каршысында иң зур көрәш – ул үз-үзе белән, үзенең нәфесе белән. Төннең уртасында намазга уяну, йокыңны җиңү – зур бер көрәш, нәфесеңне җиңү. Рамазан аенда ризыктан, эчемлекләрдән аерылып тору – шулай ук зур бер көрәш, нәфесеңне җиңү. Вакытыңны дөрес итеп куллану, гыйлем алырга тырышу да нәфесеңне җиңү. Ачуыңны чыгарган кешегә беренче булып елмаеп, янына килеп исәнләшү – зур бер батырчылык. Боларның барысы да безгә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм тарафыннан өйрәтеп калдырылган гамәлләр. Башка кешеләргә диннәре, фикерләре башка төрле булу сәбәпле ачу белән карау, төрле экстремистик юлларга керү – начар гамәлләрдән санала, чөнки

пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрвакытта да гел хәерлегә өндәгән. Аллаһы Расүленең үзеннән соң пәйгамбәрләр булмаячагы хакында әйткәнен беләбез. Расүлебездән соң аның гыйлемен безгә галимнәр ирештерәчәк. Пәйгамбәребезнең өммәтенә, ә бигрәк тә сәхабәләргә мөрәҗәгать итеп, Раббыбыз әлеге сүзләрне әйтә:

كُنتُمْ خَيْرَ أُمَّةٍ أُخْرِجَتْ لِلنَّاسِ تَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَتَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ وَتُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ ۗ

«**Кешеләр [мәнфәгатьләрен кайгыртыр] өчен [мәйданга] чыгарылган өммәтләрнең иң яхшысы сез булдыгыз [Ий Мөхәммәд өммәте! Аллаһының мәңгелек гыйлемендә дә, Ләүхүл-Мәхфүздә дә бу саклана]. Яхшы гамәлләрне әмер итәсез, начар гамәлләрдән тыясыз һәм Аллаһыга ышанасыз**».

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:110

Кызганычка, бүгенге көндә мөселман кешесенең сурәте дөньяда бик куркыныч халәт белән тасвирлана. Ислам исеменнән начарлык эшләүче кешеләр башкаларга түгел, нәкъ менә мөселманнарга зур зарар китерәләр. Шушы начар кешеләр аркасында Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен үтәп яшәргә тырышкан кешеләргә, матур яулыкларын япкан мөслимәләргә кырын карыйлар. Шушы кешеләрнең начар гамәлләре аркасында бүтән дин, милләт кешеләрендә мөселманнарга һәм сөекле Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата үзенә күрә бер нәфрәт һәм аңлашылмаучанлык туа. Әмма хакыйкый мөселман кешесе беркайчан да начарлык кылмас, хәтта үзенә начарлык эшләсәләр дә, ул аларга күркәм рәвештә җавап кайтарыр. Чын хакыйкый мөселман булган кеше һәрвакытта күңелендә изгелек йөртү сәбәпле, бөтен кешегә дә бәхет телә, чөнки ул зур бәхетнең иманлы булып, кешеләргә изгелек кылып яшәү икәнен аңлый һәм башкаларга да шуны

тели. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Үзегезгә теләгәнне башкаларга да теләмичә сезнең иманнарыгыз камиллеккә ирешмәс», – дип әйткән. Үзебезгә теләгән бәхетне калганнарга да теләсәк, алар белән яхшы мөнәсәббәттә булсак, һичшиксез, Аллаһы Тәгалә безнең шушы матур үрнәгебез, әхлагыбыз сәбәпле калган кешеләрне дә ислам диненә китерер. Без кешеләргә динебезнең никадәр матур, гүзәл, күркәм икәнен күрсәткән саен, алар безнең динебезгә тартылырлар.

Кайбер сәхабәләр, галимнәр үзләренең диннәрен тел белән түгел, ә гамәлләре белән күрсәтә торган булганнар. Сату-алуда булган гаделлек, кешеләр белән аралашуда тугрылык, өстендәге әманәтне җиренә җиткереп үтәү сәбәпле, күп кенә кешеләр аларга сокланып, Ислам диненең шуның кадәр олы дәрәҗәгә күтәрүен аңлап, динебезне кабул иткән. Безгә дә шушы үрнәкне алырга кирәк. Матур сүзләрне ешрак әйтергә, күркәм гамәлләрне күбрәк кылырга кирәк. Матур сүзләрне никадәр ешрак әйтсәк, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтенә шуның кадәр ныграк, көчлерәк ияргән булабыз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтенә никадәр ныграк ияргән булсак, Кыямәт көнендә аның шәфәгатьчелеген алу мөмкинлеге шуның кадәр арта барыр, иншәАллаһ.

Газиз дин кардәшләрем, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хакыйкый мирасын дөрес итеп аңлыйк, күркәм гамәлләр кылыйк һәм тормышыбызны Аллаһы рәхмәтенә ирешерлек итеп үткәрик. Аллаһы Тәгалә барчабызга да динне дөрес аңлап, Аллаһы Тәгалә рәхмәтендә яшәү әҗерен, нигъмәтен насыйп итсә иде. Кылган һәрбер гамәлләребездән Раббыбыз разый булса иде. Аллаһы Тәгалә һәрбарчабызга хәерле, бәрәкәтле тормышлар насыйп кылсын. Әәмин.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*

*Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе,*

*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

*15 нче октябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән...

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрне юктан бар итеп, безгә иксез-чиксез нигъмәтләрен биргән, безнең тәнебезгә җан керткән һәм Үзенең рәхмәтендә яшәргә мөмкинлек биргән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча мактаулар булса иде һәм дә галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелмеш булган, безнең калебләребезнең табибы, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән безгә тугры юлны күрсәткән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифәләребез булса иде.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә бу дөньяны халык кылганнан соң, адәм балаларын шушы дөнья «мәдрәсәсенә» җибәрә. Адәм баласы һәрвакытта нәсыйхәтләргә, яхшы киңәшкә һәм дөрес юлны күрсәтүгә мохтаҗ. Шул сәбәпле, нинди генә кавемнәр, нинди генә халыклар яшәсә дә, Аллаһы Тәгалә адәм балаларына рухи укытучыларны җибәргән. Рухи укытучылар дөнья малына баткан кешеләргә җаннарын ризыкландырырга ярдәм иткәннәр. Шушы укытучылар адәм балалары арасыннан иң хәерлеләре. Алар – пәйгамбәрләр. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә аларны безгә нәсыйхәт итеп, бер нур итеп, шушы дөньяның пычраклыгына баткан, күп вакыт наданлыкка төшкән бәндәләрне дөрес юлга бастырыр өчен рухи укыту-

чылар итеп җибәргән. Алар бихисап. Әмма араларыннан Аллаһы Тәгалә олылап, Үзенең китапларында бәян иткәннәре бар. Пәйгамбәрләрнең иң ахыргысы, иң нурлысы, Аллаһы каршында иң яратканы – ул пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу дөньяга пәйгамбәрләрнең ахыргысы булып, нигъмәт буларак җибәрелә. Аллаһының Расүле бу дөньяга килгән вакытта дин зәгыйфьләнгән, кешеләр рухи бушлыкка, түбәнчелеккә төшкән булалар.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм килеп, 63 ел гомере аралыгында йөз меңләгән сәхабәне тәрбияләп калдырган. 40 яшендә аңа пәйгамбәрлек килгән. Үз тормышында нинди генә авырлыклар булуына карамастан, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм беркайчан да сынмаган, сыгылмаган, Раббысының ярдәмен тоеп яшәгән. Бер Аллаһы Тәгаләгә генә инанып, Аннан гына ярдәм өмет иткән. «Өммәтем, өммәтем, өммәтем», дип әйтә-әйтә, төннәр буе намазларын укыган, күп догалар кылган. Һәрвакытта кешеләр тынычлыгы, иминлеге хакына нәсыйхәтләрен ирештереп, изге гамәлләр башкарган. Үзенә начарлык эшләгән кешеләргә дә начарлык белән җавап кайтармаган. Киресенчә, яхшылык белән җавап кайтарган. Гомумән, бу үзе зур үрнәк булып тора. Аның мәрхәмәтлелеге турында, киң күңеллелеге хакында бик күп вакыйгалар бар.

Бервакыт бер бәдәви гарәбе мәчет эченә кереп, үзенең йомышын башкарган. Сәхабәләрнең бу күренешкә ачулары чыгып, алар бу бәндәгә ябырылганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларны тынычландырып, шушы нәҗесле җиргә бер савыт белән су алып килеп, шуны сибәргә кушкан. Ул беркайчан да начарлыкка, әдәпсезлеккә өндәмәгән. Сәхабәләр аннан: «Аллаһы Тәгалә бу дөньяга сине нәрсә өчен җибәрде?» – дип сорагач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Күркәм әдәпне вә әхлакны югары рәвешкә җиткерер өчен», – дип җавап кайтарган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм акыллы, нурлы, пакь күңелле булган. Аның күңелендә усаллык булмаган. Күңелендә ризасызлык булса да, ул фәкать Аллаһы Тәгаләнең динендә ярамаган, булмаган эшләрнең эшләнүенә ризасызлыгын белдергән. Беркайчан да кешене рәнҗетмәгән, начар сүзләр белән эндәшмәгән. Әгәр дә аз гына ялгышса, һәрвакыт гафу үтенә торган булган.

Аллаһы Тәгалә сөекле Пәйгамбәребезне туганда ук пәйгамбәрлек нуры белән бүләкләгән. Аллаһының Расүле сабый яшеннән үк ятим калган. Ул туганчы ук аның әтисе вафат булган. Ул туып, бераз вакыт яшәгәннән соң, аның әнисе дә бакыйлыкка күчкән. Соңыннан бабасының тәрбиясенә калып, бабасы вафат булганнан соң, Әбү Талиб исемле абзасының гаиләсендә тәрбияләнгән.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кечкенә яшеннән үк бик зирәк, акыллы, күркәм холыклы, ышанычлы булган. Шуңа күрә Мәккә халкы аңа «Мөхәммәд, «Әл-Әмин» дип эндәшкән, ягъни ышанычлы, әманәтне саклый, беркайчан да үзенең вәгъдәсен бозмый, ялганламый, кешеләргә начарлык эшләми дигән сүз. Шул сәбәпле, аңа шундый олы исем биргәннәр.

40 яше җиткәч, мәгарәдә утырган вакытында аның янына Җәбраил галәйһиссәлам килгән. Шушы мизгелдән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә вәхи иңә башлаган. Аллаһының Расүле иң элек бу вакыйгалардан курыккан, ләкин соңрак үзенең пәйгамбәр итеп җибәрелүен белгән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм 23 ел дәвамында дәгъват кылган. Бакыйлыкка күчеп, үзеннән соң йөз мең сәхабәне калдырган. Шушы сәхабәләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән соң Ислам динен бөтен дөньяга таратканнар. Алар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен, Аллаһы Тәгаләнең Китабын бөтен нәрсәдән дә өстен куеп, Аллаһы Тәгаләне нык

яратып, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне әти-әниләренә караганда да ныграк яратып, аны үзләренә үрнәк итеп алганнар. Бүгенге көндә берәүләр җырчыларны, икенчеләре спортчыларны, кино актерларын үзләренә үрнәк итеп алалар, аларга охшарга, нәкъ аларныкы кебек тормыш рәвеше алып барырга тырышалар. Әмма һәрберебез Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне үзебезгә үрнәк итеп алсак, һичшиксез Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безгә бик яхшы тормыш бирер иде. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән тынычлыкта яшәр идек, иншәАллаһ.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм – безнең күңелләребезнең нуры, калебләребезнең табибы, Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән иң күркәм, иң сөекле затларның берсе. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу дөньяга бер рәхмәт буларак җибәрелде.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлына карасак, аның хатыны Хәдичә радыяллаһу ганһә һәрвакыт аның янында булган, кызлары аңа һәрвакыт ярдәм иткәннәр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә нинди генә сүзләр әйтсәләр дә, нинди генә әшәкелекләр кылсалар да, ул беркайчан да аларга начарлык белән җавап кайтармаган.

Таиф шәһәреннән аны ташлар атып куып чыгарганнар. Бик яраланган булса да, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларга бәддога кылмаган. Киресенчә, ул аларга хәерлесен теләп дога кылган.

Мәккә мөшрикләре аның артыннан куып эзләгән вакытта, якын сәхабәсе Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе белән мәгарәдә булганда, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл итәргә кушкан. Хәтта үрмәкүч мәгарәгә пәрәвез ясап куйган. Агачлар, үсемлекләр, ташлар да Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәрвакыт салават әйтә торган булганнар. Аллаһының Расүле ятимнәргә, тол хатыннарга, мескен фәкыйрьләргә бик яхшы мөнәсәбәттә булган. Ул иң күркәм әхлак иясе булган. Хатыны Гайшә анабыз «Аның әхлагы нинди иде?» дигән сорауга:

«Аның әхлагы Коръән иде», – дип җавап кайтарган. Ягъни Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгалә иңдергән Коръәни Кәрим аятьләренә туры китереп яшәгән.

Әйткәнебезчә, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрвакытта ятимнәргә, мескеннәргә ярдәм иткән. Йортында аз гына ризыгы булса да, ул аның белән бүлешкән. Төннәр буе намаз укып, дога кылып, өммәте өчен иң хәерлесен сораган. Ач булган вакытында да зарланмаган.

Бервакыт Билал исемле мөәзине Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең янына килеп зарланган. Кара тәнле булганга, берәү аңа: «Син кара хатынның улы», – дип әйткән. Билал радыяллаһу ганһе бу хакта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сөйләгәч, Аллаһының Расүле Билал радыяллаһу ганһегә начар сүзләр әйткән сәхабәгә: «Синең күңелеңдә әле җәһиллек калган икән», – дип әйткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәсыйхәтләре шуның кадәр үтемле булган ки, теге сәхабә тиз арада Билал радыяллаһу ганһе янына барып, аннан гафу үтенгән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән хәтта Җәбраил галәйһиссәлам дә иң күркәм сүзләр белән эндәшкән. Аллаһының Расүленә «Хәбибулла» дип тә дәшә торган булганнар, чөнки ул Аллаһы Тәгаләнең яратканы. Шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә аны иң хәерле рәвештә, иң олы дәрәҗәләргә күтәрә. Кыямәт көнендә дә, бөтен кешеләр куркып басып торганда, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шәфәгать кылачак. Аның яратуына ирешергә теләгән һәр мөселман аңа иксез-чиксез салаватлар әйтеп, догалар кылып, аны чын күңелдән яратып, аңа охшарга тырышып яшәргә тиеш һәм шушы очракта Аллаһы Тәгалә безне яратыр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

قُلْ إِن كُنتُمْ تُحِبُّونَ ٱللَّهَ فَٱتَّبِعُونِى يُحْبِبْكُمُ ٱللَّهُ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ ۗ وَٱللَّهُ غَفُورٌ رَّحِيمٌ ﴿٣١﴾

**«[Расүлем!] Әйт: «Әгәр сез Аллаһыны сөясез икән, миңа иярегез, шулвакыт Аллаһы да сезне сөячәк һәм гөнаһларыгызны гафу итәчәк. Аллаһы – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:31

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә гыйлем мирасын, күркәм әдәп-әхлак калдыручыларның иң хәерлесе, безнең калебләребезнең табибы, рухи укытучыбыз, үрнәк алырдай затыбыз. Шул сәбәпле, Аллаһы Тәгалә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күркәм әхлак белән охшарга, аны яратырга, аңа һәрвакыт салават әйтергә насыйп вә мәяссәр кылса иде һәм дә Кыямәт көнендә шәфәгатьчелеген насыйп кылып, турыдан-туры җәннәтләргә кертсә иде. Шушы рабигыль-әүвәл аенда, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган аенда, без Расүлебезне зурлап салаватлар әйтик, бөтен мөселман дөньясы аны иң хәерле рәвештә искә алып, һәр мөселман бер-берсенә карата Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм васыять иткән мәхәббәтне булдырса иде. Бер-беребездән гафу үтенеп, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хакына булса да бер-беребезгә яхшы мөнәсәбәттә булсак иде һәм, һичшиксез, Аллаһы Тәгалә безгә Үз рәхмәтен кайтарыр иде.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә шушы айда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне күп итеп искә алып, бу айда алган гыйлемнәребезне, әйткән салаватларыбызны киметмичә, калган айларда да Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне искә алып, салаватлар әйтеп, аның тормыш юлын өйрәнергә насыйп кылса иде. Раббыбыз җирләребезне, көннәребезне, күкләребезне хәерле вә исән-имин кылып, Пәйгамбәре-

без өммәтеннән яшәргә һәм Ахирәткә дә аның өммәтеннән булып күчәргә насыйп вә мәяссәр кылса иде. Әәмин.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*

*Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе,*

*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

*22 нче октябрь вәгазе,*
*рабигыль-әүвәл аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Диндә ныклык сорыйк

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Аллаһы Раббыбызга барча мактауларыбыз булсын. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез ирешсен. Пәйгамбәребезнең сәхабәләренә, табигыйннәргә, тәбге-табигыйннәргә, хәер-дога, сәламнәребез булсын.

Мөхтәрәм кардәшләр! Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән нигъмәтләре бихисап. Болар – кояш, сулаган һавабыз, һәр сулыш алуыбыз, акыл, сәламәтлек, ашаган ризыгыбыз, кигән киемнәребез һәм безнең әйләнә-тирәбездә булган бик күп башка нигъмәтләр. Аллаһы Тәгалә «Ән-Нәхл» сүрәсендә болай дип әйтә:

وَإِن تَعُدُّواْ نِعْمَةَ ٱللَّهِ لَا تُحْصُوهَآ ۗ ...﴿١٨﴾

**«Аллаһының [сезгә биргән бөтен] нигъмәтләрен саный башласагыз, аларны санап бетерә алмассыз».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:18

Аллаһы Тәгалә безгә биргән нигъмәтләрнең иң кыйммәтлесе иман булып тора. Аллаһы Коръәннең «Ән-Ниса» сүрәсендә болай дип әйтә:

يُرِيدُ اللَّهُ لِيُبَيِّنَ لَكُمْ وَيَهْدِيَكُمْ سُنَنَ الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ وَيَتُوبَ عَلَيْكُمْ ۗ وَاللَّهُ عَلِيمٌ حَكِيمٌ﴿٢٦﴾

**«Аллаһы сезгә [белмәгән нәрсәләрегезне] бәян итәргә, сезне дә сездән элгәреләрнең [Нәбиләр һәм изгеләрнең] юлларына**

**күндерергә һәм сезнең [ялгышларыгыз өчен кылган] тәүбәгезне кабул итәргә тели. Аллаһы – [һәрнәрсәне] Белүче, Хикмәт иясе».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:26

Галәмдәге бөтен мәхлукат, бөтен тереклек ияләре үзләрен бар кылган Аллаһы Тәгаләне үз телләре белән зикер итә, тәсбих кыла, Аңа мактау сүзләрен әйтә. Бу хакта Раббыбыз Коръәннең «Әл-Исра» сүрәсендә болай дип әйтә:

تُسَبِّحُ لَهُ السَّمَاوَاتُ السَّبْعُ وَالْأَرْضُ وَمَن فِيهِنَّ وَإِن مِّن شَيْءٍ إِلَّا يُسَبِّحُ بِحَمْدِهِ وَلَكِن لَّا تَفْقَهُونَ تَسْبِيحَهُمْ إِنَّهُ كَانَ حَلِيمًا غَفُورًا﴿٤٤﴾

**«Җиде [кат] күкләр белән җир һәм аларда булганнар Аңа тәсбих әйтеп торалар. [Диңгездәге балыклардан алып, һавадагы кошларга кадәр] Аны мактау белән мактамаган һичбер нәрсә юк, ләкин [телләрегезнең төрлелеге, фикерләвегезгә киртә булган бер гафләттә тотылуыгыз сәбәпле] сез аларның тәсбихләрен аңламыйсыз. Һичшиксез, Ул – Мәрхәмәтле һәм Гафу итүче».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:44

Инсан акыллы, камил зат итеп яратылган. Аллаһы безгә биргән иман нигъмәте өчен Раббыбызны искә алу, мактау, Аллаһыга шөкер итү – инсанның бурычы. Безне даими исенә төшереп торучы һәм һич кенә дә онытмаучы Аллаһыны искә алып зикер итү – кешеләрнең иң мөһим вазифаларының берсе. Аллаһы «Локман» сүрәсендә болай дип әйтә:

وَلَقَدْ آتَيْنَا لُقْمَانَ الْحِكْمَةَ أَنِ اشْكُرْ لِلَّهِ وَمَن يَشْكُرْ فَإِنَّمَا يَشْكُرُ لِنَفْسِهِ وَمَن كَفَرَ فَإِنَّ اللَّهَ غَنِيٌّ حَمِيدٌ﴿١٢﴾

**«Без Локманга хикмәтне [сүздә һәм эштә урынлы өстен белемне] «Аллаһыга шөкер ит!» – дип бирдек. Кем дә кем шөкер**

**итсә, үз файдасына шөкер иткән булыр, кем дә кем инкяр итсә, һичшиксез, Аллаһы – [беркемнең дә ярдәменә мохтаҗ булмаучы] Бай, Мактауга лаеклы».**

«Локман», 31:12

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

فَٱذۡكُرُونِيٓ أَذۡكُرۡكُمۡ وَٱشۡكُرُواْ لِي وَلَا تَكۡفُرُونِ ﴿١٥٢﴾

**«Мине искә алыгыз, Мин дә сезне искә алырмын. Миңа шөкер итегез, [әмеремә буйсынмыйча, нигъмәтләремне күрмәгәндәй] Миңа карата шөкерсез булмагыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:152

Кайберәүләр, дин юлына баскач, үзен башкалардан өстен күрә. Әлбәттә, Ислам дине бу гамәлне хупламый. Мөселманга башка кешеләрне яхшылык кылуга өндәп, аларны нәсыйхәтләп, ләкин үзен җәннәткә лаек булдым, дип хис итү дөрес булмас, чөнки без гомеребез дәвамында тырышып иманыбызны саклап яшәргә тиешбез. Без гөнаһны гөнаһ дип күрергә, тәкәбберлектән, горурланудан читләшергә тиеш.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә: «Тәкәбберлек сыйфаты Минем киемем һәм шулай ук олуглык сыйфаты да Минем киемем. Кем дә кем аларның берсен Миннән тартып алырга теләсә, Мин аны җәһәннәм утына атачакмын», – дип әйтә»[1].

Тәкәбберлек сыйфатыннан котылу өчен, Аллаһыга дога кылырга кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһыга болай дип дога кыла иде:

رَبِّ أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْكَسَلِ وَسُوءِ الْكِبَرِ، رَبِّ أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابٍ فِي النَّارِ

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

وَعَذَابٍ فِي الْقَبْرِ

«Рабби әгууҙү бикә минәл-кәсәли вә сүү’ил-кибәри, Рабби әгууҙү бикә мин гаҙәәбин фин-нәәри вә гаҙәәбин фил-кабри».

Мәгънәсе: «Раббым Аллаһы! Мин Сиңа ялкаулыктан, тәкәбберлек сыйфатыннан, җәһәннәм утыннан һәм кабер газабыннан саклауны сорап сыенам»[1].

Мөселман кешесе Аллаһы Тәгаләдән диндә булмаган кешеләр өчен, аларны туры юлга күндерүне, җәһәннәм утыннан саклауны һәм җәннәткә кертүне сорап дога кылырга тиеш.

Ислам дине кешеләрне дөнья эшләре белән бәйле нигъмәтләргә: ризыкка, саулык-сәламәтлеккә, байлыкка, эш урынына канәгать булырга өнди. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм канәгать булуның фазыйләтен аңлатып болай дип әйтә: «Кем иртә белән иминлектә, саулыкта, бер көнлек ризыгы булган халәттә йокыдан уянса, ул җир йөзенең бөтен байлыгына ия булган кеше кебек булыр»[2].

Әгәр дә кеше матди яктан үзеннән түбәнрәк кешеләргә караса, аның күңеле үз халәтеннән канәгать кала һәм ул Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләргә шөкер итә башлый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Сездән югары булганнарга түгел, ә сездән түбән булучыларга карагыз. Бу сезгә Аллаһының нигъмәтләрен ким итеп күрмәүдә ярдәм итәчәк».

Аллаһы Тәгалә адәм баласына башта Раббысына, аннары ата-анасына шөкер итәргә куша, чөнки баланы дөньяга Аллаһының рәхмәте белән әти-әнисе тудыра. Безгә Раббыбыз каршысына барачагыбызны онытмау, хәерле гамәлләребезне арттыру, һәрчак шөкердә булу тиешле.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

---

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

فَٱسْتَبِقُوا۟ ٱلْخَيْرَٰتِ ۚ ... ﴿١٤٨﴾

**«Сез яхшы гамәлләргә ашыгыгыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:148

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм көненә йөзләгән мәртәбә болай дип дога кылган:

يَا مُقَلِّبَ الْقُلُوبِ ثَبِّتْ قَلْبِي عَلَى دِينِكَ

«Йәә мүкаллибәл кулүүби ҫәббит кальбиии галәә диииник».

Мәгънәсе: «Йә, калебләрне әйләндерүче, минем калебемне Синең динеңдә нык ит».

Шулай ук Пәйгамбәребез мондый дога да кылган:

اللَّهُمَّ مُصَرِّفَ الْقُلُوبِ صَرِّفْ قُلوبَنَا عَلَى طَاعَتِكَ

«Аллааһүммә мусаррифәл кулүүби сарриф кулүүбәнә галәә таагәтик».

Мәгънәсе: «Йә, Аллаһы, калебләрне юнәлтүче, безнең калебләребезне Сиңа итагать кылуга юнәлт»[1].

Һәм без дә шушы догаларны кылып, Аллаһы Тәгаләдән тәкъвалык ияләреннән булуыбызны сорыйк.

Әбү Гамр Суфьян бине Габдулла Сәкафи радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Бервакыт мин: «Әй, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм, миңа Ислам турында мин синнән соң беркемнән дә сорамаслык сүзләр әйт», – дидем. Ул: «Мин Аллаһыга ышандым», – дип әйт тә, аннары тугры бул!» – диде»[2].

Мөхтәрәм кардәшләр! Раббыбыз Үзенең кушканнарын үтәп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең юлында булып, динебездә тугры булуны насыйп итсен!

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рамил хәзрәт Хөснетдинов,*

*Бөгелмә районы һәм шәһәре имам-мөхтәсибе*

*28 нче октябрь вәгазе,*
*рабигыль-әүвәл аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Күңел тынычлыгын табу

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Аллаһы Раббыбызга барча хәмед-сәналәребез булсын! Барча пәйгамбәрләрнең хәерлесе булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез ирешеп торсын. Пәйгамбәребезгә чын күңелдән ярдәм иткән сәхабәләренә, табигыйннәргә, тәбге-табигыйннәргә, иман-исламда Кыяматкә хәтле булырга тырышкан мөэмин-мөселманнарга хәер-дога, сәламнәребез булсын! Мөхтәрәм кардәшләрем! Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Ислам динендә күңел тынычлыгы Аллаһы Тәгаләнең мөселманнарга биргән бүләге булып тора. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

هُوَ الَّذِي أَنزَلَ السَّكِينَةَ فِي قُلُوبِ الْمُؤْمِنِينَ لِيَزْدَادُوا إِيمَانًا مَّعَ إِيمَانِهِمْ ۗ
...﴿٤﴾

**«Ул – [ия булган] иманнары белән иманнарын ныгытсыннар өчен, иман китерүчеләрнең күңелләренә тынычлык [рәхмәт, Аллаһыга һәм Аның расүленә хөрмәт, Исламның хөкемнәренә авышу һәм тартылу] иңдергән Зат».**

«Әл-Фәтх / Җиңү», 48:4

Һәрберебезнең күңел тынычлыгына ия буласы килә, әмма аңа омтылу юлларыбыз төрле: кемдер аны байлыктан, кемдер дан-дәрәҗәдән эзли. Ә динебез күңел тынычлыгына чын дәрәҗәдә ирешүнең бердәнбер юлы – Аллаһыга мөрәҗәгать итүдә дип өйрәтә. Аллаһының безгә мәҗбүри эшләргә кушкан әйберләрнең асылында үзебез өчен физик һәм рухи як-

тан кирәкле кыйммәтләр ята. Коръән укыйбыз, намаз гыйбадәтен кылабыз, зикер әйтәбез – тынычланабыз. Ураза тотабыз – нәфесебезне тыярга, үзебезне кулда тотарга, булганына канәгать булырга өйрәнәбез. Болар шулай ук кешегә тынычлык алып килә. Безнең күңелдә нәрсә икәнен белүче бердәнбер зат – Ул Аллаһы, чөнки күңелне, рухны барлыкка китерүче дә Ул бит. Коръәндә бу турыда болай дип әйтелә:

ٱلَّذِينَ آمَنُوا وَتَطْمَئِنُّ قُلُوبُهُم بِذِكْرِ اللَّهِ أَلَا بِذِكْرِ اللَّهِ تَطْمَئِنُّ الْقُلُوبُ ﴿٢٨﴾

**«Алар – иман китергән һәм күңелләре Аллаһыны зикер итү белән [бөтен буталчыклардан, шик-шөбһәләрдән котылып] тынычланган кешеләр. Күңелләр Аллаһыны зикер итү белән тынычланмыймы?»**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:28

Шуннан чыгып, Ислам галимнәре күңел тынычлыгына ирешү өчен түбәндәгеләрне киңәш итә: Аллаһы минем янәшәдә, мине ишетә, аңлый һәм ярдәменнән ташламый дип уйларга кирәк. Бу – кешене тынычландыра.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәте вакытында Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе белән Мәккәгә бер сәгатьлек ераклыкта булган Сәүр тавы түбәсендәге бер мәгарәдә өч көнгә Мәккә мөшрикләреннән яшеренәләр. Бу вакытта мөшрикләр, мәгарә янына килеп, аларны эзли башлагач, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе: «Әгәр бүген тотылсак, Аллаһының дине бетәр!» – дип уйлап, бик куркуга кала һәм Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә: «Йә, Расүлуллаһ, аларның берәрсе аяк астына караса, безне күрәчәк!» – дигәч, Расүлуллаһ: «Өченчесе Аллаһы булган ике кеше хакында син нәрсә уйлыйсың?!» – дип әйтә һәм Аллаһы Тәгаләнең ярдәме һәм саклавы үзләре белән булганын аңлата. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

إِذْ يَقُولُ لِصَاحِبِهِ لَا تَحْزَنْ إِنَّ اللَّهَ مَعَنَا فَأَنزَلَ اللَّهُ سَكِينَتَهُ عَلَيْهِ

**«Шулчак ул [аның өчен хәвефләнгән] юлдашына: «Борчылма, Аллаһы [ярдәме һәм саклавы] бит безнең белән!» – дип әйтте, һәм Аллаһы аңа [рәхмәтен һәм] тынычлыгын иңдерде».**

«Әт-Тәүбә», 9:40

Күңел авырулары өчен иң яхшы дару һәм тынычландыру чарасы – ихлас күңелдән Коръән аятьләрен уку, аларның мәгънәсе турында уйлану. Пәйгамбәребез үзенең бер хәдисендә: «Кешеләр Аллаһы йортларының берсендә бергәләп Коръән уку һәм өйрәнү өчен җыелсалар, аларга, һичшиксез, иминлек иңәчәк, аларны рәхмәт каплаячак, фәрештәләр әйләндереп алачаклар һәм Аллаһы Үз каршындагылар алдында аларны искә алачак.[1]

Тынычлануга якынаюның иң җайлы юлы күп тапкырлар Аллаһыны зикер итү. Юныс галәйһиссәламне балык йоткач, ул бик җайсыз, чарасыз хәлдә кала. Шулчакта Аллаһыны зикер итеп, бу доганы укый:

لَا إِلَهَ إِلَّا أَنتَ سُبْحَانَكَ إِنِّي كُنتُ مِنَ الظَّالِمِينَ

«Ләә иләһә илләә әнтә, субхәәнәкә инниии күнту минәз-ӟаалимииин».

Мәгънәсе: «Синнән башка һичбер илаһ юк! Син пакь! Һичшиксез, мин залимнәрдән булдым!»

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

فَاسْتَجَبْنَا لَهُ وَنَجَّيْنَاهُ مِنَ الْغَمِّ وَكَذَلِكَ نُنجِي الْمُؤْمِنِينَ ﴿٨٨﴾

**«Без аңа җавап бирдек һәм аны [йоткан балыкка: «Бераздан аны диңгез ярына илтеп чыгар!» – дип әмер итеп] хәсрәтеннән коткардык. Мөэминнәрне дә шулай коткарырбыз».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:88

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Пәйгамбәребез бу сүзләрне бик еш кабатлый торган булган:

اللَّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْهَمِّ وَ الْحَزَنِ، وَ الْعَجْزِ وَ الْكَسَلِ، وَ الْبُخْلِ وَ الْجُبْنِ، وَ ضَلَعِ الدَّيْنِ وَ غَلَبَةِ الرِّجَالِ

«Аллааһүммә иннии әгуузү бикә минәл-һәмми вәл-хәзәни вәл-гаҗзи вәл-кәсәли вәл-бүхъли вәл-җүбни вә даләгыйд-дәйни вә галәбәтир-риҗәәл».

Мәгънәсе: «Әй, Аллаһы, чыннан да, мин борчылудан һәм хәсрәт-сагыштан, көчсезлегемнән һәм ваемсызлыгымнан, саранлыгымнан һәм төшенкелеккә бирелүчәнлегемнән, бурычлар авырлыгыннан һәм кешеләрнең кыерсытуларыннан Сиңа сыенамын».

Һәр ниятне Аллаһыга тәвәккәлләп тормышка ашырырга, һәрбер эшне Аллаһыга тапшырып башкарырга тиешбез. Аллаһыга тәвәккәл кылучы кеше эшләрнең ахыры нәрсә белән төгәлләнүенә карамастан, күңеле белән риза була һәм үзен тыныч тота. Хәтта ул теләгән максатына ирешмәсә дә – зарланмый. Тәвәккәл кылганга күрә Аллаһы Тәгалә Ибраһим пәйгамбәрне дә һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне дә зарардан саклады. Ибраһим пәйгамбәр Нәмруд патша яккан уттан, ә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккә кяферләренең һөҗүменнән котылды. Габдулла бине Габбас радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Безгә ярдәмче буларак Аллаһы җитә. Нинди яхшы ярдәмче Ул», – дигән сүзләрне Ибраһим пәйгамбәр утка атылган вакытында, ә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккә кяферләре белән куркытылган вакытта әйтте»[1].

Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Раббыбыз һәрберебезгә дә күңел тынычлыгы насыйп итсен. Аллаһы Раббыбызга даими зикер-гыйбадәттә булырга насыйп кылсын!

1 Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рамил хәзрәт Хөснетдинов,*

*Бөгелмә районы һәм шәһәре имам-мөхтәсибе*

*5 нче ноябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 30 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Барыбыз да Аллаһы мәхлүкълары

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн. Аллаһы Тәгалә бар, Аллаһы Тәгалә бер, Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһ юк, Аннан башка гыйбадәткә лаеклы зат юк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм – Аның Расүле.

Барча мактау-данлау Аллаһы Тәгаләгә! Без Аңа шөкрана кылабыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аннан ярлыкавын үтенәбез! Үзебезнең начарлыгыбыздан, бозык гамәлләребездән Аллаһы Тәгаләдә сыену эзлибез! Аллаһы туры юлга күндерсә, берәү дә адаштыра алмас, Аллаһы адаштырганнарны исә берәү дә туры юлга кертмәс.

Аллаһы Тәгалә төрле кешеләрне халык кылды, аларга расүлләр җибәрде. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә тән төсенә, милләтенә, җәмгыятьтәге урынына карамастан, бөтен кешене берләштерде. Монда «Аллаһы Тәгалә ни өчен төрле халыкларны һәм кавемнәрне булдырган соң?» дигән сорау туарга мөмкин. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримнең түбәндәге аятендә әлеге сорауга болай дип җавап бирә:

يَٰٓأَيُّهَا ٱلنَّاسُ إِنَّا خَلَقۡنَٰكُم مِّن ذَكَرٖ وَأُنثَىٰ وَجَعَلۡنَٰكُمۡ شُعُوبٗا وَقَبَآئِلَ لِتَعَارَفُوٓاْۚ
إِنَّ أَكۡرَمَكُمۡ عِندَ ٱللَّهِ أَتۡقَىٰكُمۡۚ إِنَّ ٱللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٞ ﴿١٣﴾

**«Ий кешеләр! Һичшиксез, Без сезне [Адәм исемле] бер ирдән һәм [Хавва исемле] бер хатыннан яраттык. [Һәммәгезнең дә ата-анасы бер булганга күрә, нәсел-чыгыш белән мактануның**

**ни мәгънәсе бар?] Без сезне [бер-берегезгә уйламый-нитми теләсә ни сөйләр өчен түгел] танышуыгыз өчен кавемнәр һәм кабиләләр иттек. Аллаһы хозурында иң кадерлегез – [иң асыл нәселдән булганнарыгыз түгел, Аллаһы Тәгаләнең харамнарыннан сакланган] бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз. Һичшиксез, Аллаһы – [һәрнәрсәне] Белүче, [һәрнәрсәдән] Хәбәрдар».**

«Әл-Хуҗүрат / Бүлмәләр», 49:13

Аллаһы Тәгалә мөселманнарны гына түгел, дөньяның барлык халыкларын да бер-берсен танып белергә, ислам тәгълиматлары астында берләшергә һәм гөнаһлардан сакланырга чакыра.

Әлеге аятьтә халыклар бер-берсен белергә, ягъни дусларча мөгамәлә алып барырга, мәгълүмат алмашырга, җәмгыятьнең төрле өлкәләрендәге казанышлар белән уртаклашырга тиеш, дигән фикер төгәл яңгырый. Монда ниндидер бер халык башка халыклар алдында өстенлек ала дигән ишарә юк. Бары тик тәкъвалык кына кешене һәм халыкларны Аллаһы алдында аера ала. Димәк, Аллаһы алдында теге яки бу кешенең нинди милләттән булуы әһәмиятле түгел.

Әбү Нәзрат радыяллаһу ганһедән риваять ителә: «Саубуллашу хаҗындагы вәгазендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Ий кешеләр! Онытма, Раббың бер, әтиең бер (барлык кешеләр Адәм белән Хавва нәселеннән). Онытма, гарәп булганнар гарәп булмаганнардан өстен түгел, һәм гарәп булмаганнар гарәпләрдән өстен түгел; акның карадан өстенлеге булмаган кебек, карада акның өстенлеге юк, диндарлык һәм яхшы гамәлләрдән кала»[1].

Җәмгыять, халык кебек социаль төркемнәрнең булуы, теге яки бу төркемгә кергән кешеләр арасындагы каршылыкларның булуы – кешеләрнең вөҗдан һәм дин иреге хокукларын тануның сәбәбе һәм нәтиҗәсе.

[1] Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

Кешеләр, ихтыяр көче белән, бу аермаларны һәм каршылык тудырырга мөмкин булган начар нәрсәләрне җиңәргә тиеш, һәм бар нәрсәгә карамастан, тормышта мөселман хәлендә кардәшләре белән бергә яшәү фикерен тормышка ашырырга тиеш. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләә безгә бу максатны Үзе куйды.

Ундүрт гасырдан элек Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм милләтара мөнәсәбәтләр проблемасын чиште. Мөселман җәмгыяте раса, милли һәм башка аермаларны җиңүдә беренче урында тора.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе риваять иткән хәдистә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Милләтчелеккә өндәгән кеше бездән түгел. Милләтчелек өчен көрәшкән кеше бездән түгел. Милләтчелек дип һәлак булган кеше бездән түгел»[1].

Ислам дине милләтчелекнең, тән төсенә карауның һәм фанатиклыкның барлык күренешләренә каршы. Мондый ышанулар исламга кадәрге наданлыкка (җәһилият) хас. Исламда барлык милләтләр, кабилә төркемнәр тигез, кешеләр тән төсе буенча аерылмый һәм кешене башкалардан югарырак итә торган бердәнбер үзенчәлек – аның тәкъвалыгы (диндарлыгы).

Чиксез кодрәтле Аллаһы Тәгалә Адәмнең барлык балаларын милләтенә, расасына һәм этносына карамастан күтәрде:

وَلَقَدْ كَرَّمْنَا بَنِىٓ ءَادَمَ وَحَمَلْنَٰهُمْ فِى ٱلْبَرِّ وَٱلْبَحْرِ وَرَزَقْنَٰهُم مِّنَ ٱلطَّيِّبَٰتِ
وَفَضَّلْنَٰهُمْ عَلَىٰ كَثِيرٍ مِّمَّنْ خَلَقْنَا تَفْضِيلًا ﴿٧٠﴾

> **«Без Адәм улларын шәрәфле кылдык. Аларны корыда һәм диңгездә йөрттек. Аларга ризыклар бирдек һәм Без бар иткән мәхлүкъларның күбесеннән аларны өстен кылдык».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:70

---

1 Имам Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан.

Газиз дин кардәшләрем, без барыбыз да Аллаһының бәндәләре. Аллаһы Тәгалә безне барлыкка китерде, без Аңа гына табынабыз һәм Аның күрсәтмәләрен үтибез. Раббыбыз һәммәбезгә дә бик күп мөмкинлекләр бирде. Без моны һәр мизгелдә истә тотарга, беркайчан да онытмаска тиешбез. Аллаһы Тәгаләгә һәрдаим шөкер итеп, Аның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәсәк иде. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә барчаларыбызны да Үзенең яраткан колларыннан кылса иде. Әәмин.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Раушан хәзрәт Хөснетдинов,*

*Актаныш авылы 2 мәхәллә имам-хатыйбы*

*12 нче ноябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Мөселман – исламның көзгесе

Барча мактау-данлау Аллаһы Тәгаләгә булсын! Без Аңа шөкерана кылабыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аның ярлыкавын үтенәбез! Үзебезнең начарлыгыбыздан, бозык гамәлләребездән Аллаһы Тәгаләдә сыену эзлибез! Аллаһы туры юлга күндерсә, берәү дә адаштыра алмас, Аллаһы адаштырганнарны берәү дә туры юлга кертә алмас. Аллаһыдан башка гыйбадәткә лаеклы илаһи зат юк, Ул – Берүзе, Тиңдәшсез дип шәһадәт бирәмен һәм Мөхәммәд – Аның колы һәм расүле дип шәһадәт бирәмен.

Исламга йөрәкләребезне ачкан, безгә яхшылыкны яманлыктан, хакыйкатьне ялганнан аерырга мөмкинлек биргән һәм безне хакыйкать юлыннан алып барганы өчен Аллаһыга мактау булсын.

Әйе, Аллаһы Тәгалә безгә Үзенең дине – Ислам, ягъни «тынычлык» һәм «тыңлаучанлык» аша бәхетле булырга мөмкинлек бирде. Без, мөселманнар, Ислам динен кабул итеп, Аллаһыга буйсынабыз һәм Аның ризалыгына омтылабыз. Әйе, хакыйкать юлы авыр, анда күп сынаулар һәм кыенлыклар бар.

Ни өчен мөселманнар бер-берсенә Ислам динен тотарга комачаулыйлар? Ни өчен алар көферлек һәм ширек белән көрәшү урынына үз кардәшләренә каршы торалар? Ислам моны тыя бит…

Бу сорауның сәбәпләре күп:

1. Без Коръән аятьләре турында фикерлибезме?

لَوْ أَنزَلْنَا هَٰذَا ٱلْقُرْءَانَ عَلَىٰ جَبَلٍ لَّرَأَيْتَهُۥ خَٰشِعًا مُّتَصَدِّعًا مِّنْ خَشْيَةِ ٱللَّهِ ۚ
وَتِلْكَ ٱلْأَمْثَٰلُ نَضْرِبُهَا لِلنَّاسِ لَعَلَّهُمْ يَتَفَكَّرُونَ ﴿٢١﴾

**«Әгәр дә Без бу [кадәрле әһәмиятле мәсьәләләрне эченә алган] Коръәнне бер тауга иңдергән [һәм аңа да сезгә биргән кебек акыл биргән] булсак, син аны Аллаһыдан куркудан буйсынган хәлдә яргаланганын күрер идең. Бу мисалларны Без кешеләргә фикерләсеннәр дип китерәбез».**

«Әл-Хәшр / Җыен», 59:21

إِنَّ فِى ٱخْتِلَـٰفِ ٱلَّيْلِ وَٱلنَّهَارِ وَمَا خَلَقَ ٱللَّهُ فِى ٱلسَّمَـٰوَٰتِ وَٱلْأَرْضِ لَـَٔايَـٰتٍ
لِّقَوْمٍ يَتَّقُونَ ﴿٦﴾

**«Һичшиксез, төн белән көннең [бер-берсе артыннан килеп һәм артып-кимеп] алмашуларында һәм Аллаһының күкләрдә һәм җирдә яраткан [тиңсез] нәрсәләрендә тәкъвалык ияләре булган кешеләр өчен [Яратучының барлыгына, берлегенә, чиксез көченә һәм өстен хикмәтенә ап-ачык ишарә ясаган бик күп] билгеләр бар».**

«Юныс», 10:6

إِنَّمَا مَثَلُ ٱلْحَيَوٰةِ ٱلدُّنْيَا كَمَآءٍ أَنزَلْنَـٰهُ مِنَ ٱلسَّمَآءِ فَٱخْتَلَطَ بِهِۦ نَبَاتُ ٱلْأَرْضِ
مِمَّا يَأْكُلُ ٱلنَّاسُ وَٱلْأَنْعَـٰمُ حَتَّىٰٓ إِذَآ أَخَذَتِ ٱلْأَرْضُ زُخْرُفَهَا وَٱزَّيَّنَتْ وَظَنَّ
أَهْلُهَآ أَنَّهُمْ قَـٰدِرُونَ عَلَيْهَآ أَتَىٰهَآ أَمْرُنَا لَيْلًا أَوْ نَهَارًا فَجَعَلْنَـٰهَا حَصِيدًا كَأَن لَّمْ
تَغْنَ بِٱلْأَمْسِ ۚ كَذَٰلِكَ نُفَصِّلُ ٱلْـَٔايَـٰتِ لِقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ ﴿٢٤﴾

**«Дөнья тормышының хәле – бер су кебек: Без аны күктән иңдердек һәм кешеләр белән терлекләр туенган туфракның үсемлекләре, аның сәбәпле, бер-берләренә [үрелеп] бәйләнделәр. Туфрак матурлыкка күмелеп бизәлгәч, аңарда яшәүчеләр исә**

**үзләрен [өлгергән уңышлардан файдалануга] көчләре җиткән кешеләр дип санаган бервакытта, төнлә яки көндез [боз, кырау, чикерткә, күсе һәм давыл кебек газапларыбыз белән бәйле] әмеребез аңа [җиргә] килде. Без аны [агачларын, үләннәрен һәм игеннәрен], гүя әле генә булмаганнар кебек, тамырыннан куптарылган бернәрсәгә әйләндердек. Фикер йөрткән кешеләр өчен Без аятьләребезне әнә шулай тәфсилләп аңлатабыз».**

«Юныс», 10:24

2. Динне тулысынча аңларга тырышабызмы?

Кеше белмичә яисә оныту аркасында дөрес булмаган гамәлләр кыла ала. Ләкин бу аның эшләрен акларга сәбәп булып тормый. Аятьләрне һәм хәдисләрне үзенең белем дәрәҗәсеннән генә чыгып аңлаткан, шул рәвешле башкаларны адаштырган һәм Исламны дөрес итеп аңлатмаган кешеләр дә бар. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

شَهِدَ ٱللَّهُ أَنَّهُۥ لَآ إِلَٰهَ إِلَّا هُوَ وَٱلْمَلَٰٓئِكَةُ وَأُو۟لُوا۟ ٱلْعِلْمِ قَآئِمًۢا بِٱلْقِسْطِ ۚ لَآ إِلَٰهَ إِلَّا هُوَ ٱلْعَزِيزُ ٱلْحَكِيمُ ﴿١٨﴾

**«Аллаһы, фәрештәләр һәм гыйлем ияләре Аннан башка гаделлек урнаштыручы һичбер илаһ булмаганына шаһитлык итәләр. Ул – [җиңелмәс] Бөек һәм Хикмәт иясе. Аннан башка һичбер илаһ юк».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:18

3. Мөселманнар бер-берләренә карата мөселманга караган кебек карыйлармы?

Без нәрсә күрәбез? Булырга тиешленең капма-каршысы: мөселман кардәшебезнең берәр ялгышын күреп, берәр төрле киңәш бирсәк, ул аны кабул иткәнче, башта үзен аклый башлый. Яисә, икенче бер мөселманга: «Син безнең төркемнән түгел», – дип яла ягалар. Бер мөселман икенче-

сенә хыянәт иткән очраклары юкмы? Кардәшенә авыр чакларда булышмый калганы юкмы? Ләкин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә болай дип әйтә: «Бер-берегездән көнләшмәгез, товар бәясен арттырмагыз, бер-берегез белән бәхәсләшмәгез, әй, Аллаһы коллары, кардәшләр! Мөселман – мөселманның кардәше (туганы): ул аны җәберләми, ярдәменнән калдырмый һәм алдамый.[1]

4. Бу дөньяга карата мәхәббәт.

Әлбәттә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм өчен Ахирәт тормышы бер башка өстен булган. Бүгенге көн мөселманнары дөнья тормышына сеңә башлады. Хәтта, кайберләребезнең шәригать бурычларын үтәр өчен вакытыбыз җитми башлады. Әмма бу дөньяның гына зиннәте булган әйберләр кешегә ике дөнья өчен дә файда булып тормаска мөмкин. Хәсән Әл-Басри рахмәтуллаһи галәйһи: «Дөнья тормышы иманлы кеше өчен нинди яхшы урын. Ул аннан кирәкле әйберләр өчен генә тиешле көчен куя, үзенә җитәрлек ризык таба һәм оҗмахка таба бара. Дөнья тормышы һәр явыз һәм икейөзле өчен начар урын. Ул көне-төне җәһәннәмгә барыр өчен эшли»[2], – дип әйткән. Бу дөнья тормышы кешене алдап, үзен ул эзләгән мәңгелек бәхет урыны буларак күренергә тырыша.

Ә соң бу вакытта нишләргә? Безнең бу хәлебезне төзәтеп буламы? Була! Без үзебездән башларга тиеш, чөнки Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

إِنَّ ٱللَّهَ لَا يُغَيِّرُ مَا بِقَوْمٍ حَتَّىٰ يُغَيِّرُوا۟ مَا بِأَنفُسِهِمْ ۗ ... ﴿١١﴾

**«Һичшиксез, алар [кешеләр] үз нәфесләрендә булганны алмаштырмый торып, Аллаһы кешеләрдә булганны алмаштырмый».**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:11

Бу хасталыклардан чыгу юллары берничә:

а) уйлану-фикерләү; эшләребезне контрольдә тоту.

---

[1] Имам Әл-Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Әхмәд бине Хәнбәл, «Китәбүз-Зөхд».

б) белем алу.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَآ أَرْسَلْنَا مِن قَبْلِكَ إِلَّا رِجَالًا نُّوحِىٓ إِلَيْهِمْ ۚ فَسْـَٔلُوٓا۟ أَهْلَ ٱلذِّكْرِ إِن كُنتُمْ
لَا تَعْلَمُونَ ﴿٤٣﴾

**«Без синнән алда да [кешеләргә пәйгамбәр итеп] ирләр җибәргән идек, шуларга вәхи иттек. Әгәр сез белмәсәгез, зикер ияләреннән сорагыз».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:43

в) Коръәни Кәримгә һәм Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтенә ныклап иярү.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا أَطِيعُوا اللَّهَ وَأَطِيعُوا الرَّسُولَ وَأُولِي الْأَمْرِ مِنْكُمْ ۖ فَإِنْ
تَنَازَعْتُمْ فِي شَيْءٍ فَرُدُّوهُ إِلَى اللَّهِ وَالرَّسُولِ إِنْ كُنْتُمْ تُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ
الْآخِرِ ۚ ذَٰلِكَ خَيْرٌ وَأَحْسَنُ تَأْوِيلًا ﴿٥٩﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһыга итагать итегез, Расүлгә һәм үзегездән булган хөкем ияләренә итагать итегез. Әгәр сез Аллаһыга һәм Ахирәт көненә ышансагыз, [дингә кагылышлы] берәр нәрсә турында [үзара] сүз көрәштергән очракта, аны Аллаһыга һәм [үзе яныгызда булса] Расүлгә кайтарыгыз. Бу хәерлерәк, [Ахирәттә булачак] нәтиҗә ягыннан да яхшырак».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:59

д) мөселманнарны дуслаштыру.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

إِنَّمَا ٱلْمُؤْمِنُونَ إِخْوَةٌ فَأَصْلِحُوا۟ بَيْنَ أَخَوَيْكُمْ ۚ وَٱتَّقُوا۟ ٱللَّهَ لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ ﴿١٠﴾

**«Һичшиксез, мөэминнәр – кардәшләр. Шуңа күрә кардәшләрегезне татулаштырыгыз. [Һәр эштә булганы кебек, дин кардәшләрегезнең араларын якынайтуны да җиңелгә алуда] Аллаһыдан куркыгыз, бәлки, рәхмәт ителерсез».**

«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:10

е) бер-беребезгә искә төшерү.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

وَ ذَكِّرْ فَإِنَّ ٱلذِّكْرَىٰ تَنفَعُ ٱلْمُؤْمِنِينَ ﴿٥٥﴾

**«Ләкин үгет бирүне дәвам ит, чөнки вәгазь иман китергән кешеләргә файда бирә».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:55

ж) Ахирәт тормышы өчен яхшы гамәлләрне арттырырга тырышу.

تِلْكَ ٱلدَّارُ ٱلْءَاخِرَةُ نَجْعَلُهَا لِلَّذِينَ لَا يُرِيدُونَ عُلُوًّا فِى ٱلْأَرْضِ وَلَا فَسَادًا ۚ وَٱلْعَٰقِبَةُ لِلْمُتَّقِينَ ﴿٨٣﴾

**«Ул – [сиңа макталган] соңгы йорт. Без аны җирдә тәкәбберләнмәгән һәм бозыклык теләмәгәннәрнеке итәчәкбез. Ул [күркәм] нәтиҗә [әмерләрен тотып, тыюларыннан тыелып, Аллаһы Тәгаләнең газабыннан сакланган] тәкъвалык ияләренеке [булачак]».**

«Әл-Касас / Кыйсса», 28:83

з) сабыр булу.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

يَٰٓأَيُّهَا ٱلَّذِينَ ءَامَنُوا۟ ٱسْتَعِينُوا۟ بِٱلصَّبْرِ وَٱلصَّلَوٰةِ ۚ إِنَّ ٱللَّهَ مَعَ ٱلصَّٰبِرِينَ ﴿١٥٣﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Сабырлык һәм намаз аша [Аллаһы Тәгаләдән] ярдәм сорагыз. Һичшиксез, Аллаһы сабыр итүчеләр белән».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:153

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсем килә: без, мөселманнар, – Ислам диненең көзгесе икәнебезне онытмасак иде. Без үзебезне мөселманнар арасында да, мөселман булмаганнар арасында да ничек тотуыбызга карап, кешеләр Ислам дине турында сөйләшәчәкләр, фикер йөртәчәкләр.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Раушан хәзрәт Хөснетдинов,*

*Актаныш авылы 2 мәхәллә имам-хатыйбы*

*19 нчы ноябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 14 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Биш нәрсәнең кадере

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн. Әлхәмдү лилләәһи раббил гааләмиин. Галәмнәрнең бердәнбер Раббысы булган, аннан башка илаһ булмаган Затка, барлык мәхлүкъларның Яратучысына, җирләрнең һәм күкләрнең Хуҗасына хәмед-сәналәребез булсын.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Икенче биш нәрсә белән очрашканчы биш нәрсәне куллан: картлыгың килгәнче – яшьлегеңне, авыру килгәнче – сәламәтлегеңне, мохтаҗлык килгәнче – байлыгыңны, мәшгуль вакыт җиткәнче – буш вакытыңны, үлемең килгәнче – яшәвеңне».

Туганнар! Биш нәрсәнең кадерен белергә кирәк. Адәм баласы мәңге яшәрлек итеп яратылган. Мәңгелеккә күчмәгән һичбер нәрсә аңа хозур һәм бәхет бирә алмый. Дөньяви гомер кешегә бирелгән кыйммәтле сәрмая (капитал, байлык). Бу гомерне бәхетле итә торган сәламәтлек, тазалык, яшьлек, байлык һәм вакыт кебек күп кенә чыганаклардан уңышлы файдалана белергә тиеш, чөнки бу чыганаклар кешеләргә үрчү, ботаклар җибәреп киңәю, тармаклануны тәэмин итү максатында бирелгән. Адәм баласы сәләтенчә бу чыганаклардан файдаланса, аның тормышы якты бизәкләр белән төрләнәчәк һәм җимеш бирәчәк. Кешеләрдән шуннан да артыгы таләп ителми. Ана карынында башланган юл дөнья, кабер, Кыямәт, бизмән, Сират күперенә кадәр дәвам итә. Мәңгелек юлында кеше үзенә дөньялыкта бирелгән кыйммәтләрне үстергән кадәр файда

һәм рәхәт күрер.

Бар нәрсәне кулда тоту яки югалтмау... Менә мәсьәләнең асылы шунда. Кулда тотып та югалтканнар бу чыганаклардан чамалап аласы урынга аларны комсыз исраф итүчеләр исәбендә булырлар, чөнки исәнлек, бәхет һәм байлыктан бирәү дә баш тартмый. Бар гомерен бушка уздырырга теләүчеләр дә булмас. Ләкин һәркем бу кыйммәтләрне лаеклы куллана белми. Кеше, гадәттә, сәламәтлеген дә, байлыгын да саксыз исраф итә. Дөрес юлдан гына бармый, гомер буе буш хыяллар артыннан куа. Кеше үзенә бирелгән, бүләк ителгән биш нәрсәне исраф итүчән. Аеруча буш вакытыбыз бар икән, кадерен белмибез. Буш вакыт дигәч тә, бу кул кушырып утыру дигән сүз түгел. Вакытны тәртип белән файдалану – вакытны исраф итмәү дигән сүз. Буш вакыттан Аллаһыга якынаю максатын да файдаланырга кирәк.

Гомер һәм сәламәтлек – кешенең хәзинәсе. Озын гомер кичерү генә түгел, аны тулы тормыш белән яшәү мөһим. Максатка ярашлы тулы тормыш белән яшәмәүче кеше гомерен бушка уздыра. Ул Коръән аятендә әйтелгән сүзләргә юлыгачак. Коръәни Кәримдә:

قَالَ رَبِّ ارْجِعُونِ﴿٩٩﴾ لَعَلِّي أَعْمَلُ صَالِحًا فِيمَا تَرَكْتُ... ﴿١٠٠﴾

**«Ий Раббым! Мине [тормышка] кире кайтар! Бәлки, мин калдырып киткәнемдә [намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек кылырга тиешле булган] изге гамәл кылырмын»,** – дип әйтелгән.

«Әл-Мүэминүн / Мөэминнәр», 23:99-100

Бу табигый теләк, ләкин киредән бу дөньяга әйләнеп кайту юк. Үкенергә һәм дөньяда ук тәүбәгә килергә кирәк, Ахирәткә барганнан соң түгел.

Кеше гомере өчен кыйммәтле мәсьәләне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм гади генә итеп, шул ук вакытта мөэминнәрнең йөрәгендә тирән эз калдырырлык сүзләр белән болай аңлаткан: «Икенче

биш нәрсә белән очрашканчы биш нәрсәне куллан: картлыгың килгәнче – яшьлегеңне, авыру килгәнче – сәламәтлегеңне, мохтаҗлык килгәнче – байлыгыңны, мәшгуль вакыт җиткәнче – буш вакытыңны, үлемең килгәнче – яшәвеңне».

Туганнар! Кешенең вөҗданы аны яхшылыклар, игелекләр кылырга, әдәпле һәм намуслы булырга чакыра. Кеше вөҗданы кушканча гына яшәсә, бик әйбәт булыр иде. Ләкин, ни кызганыч, адәм баласы еш кына вөҗдан авазына колак салмый шул. Шуңа күрә җан тынычлыгын югалта. Вөҗдан кушкан юлдан тайпылу гөнаһ баткагына илтә. Гөнаһ кылу – Аллаһыга каршы бару дигән сүз.

Туганнар! Тормышны төзәтеп, җәбер-золымны бетерү өчен Аллаһы Тәгалә адәм балаларына дин иңдергән. Дин – Аллаһы Тәгалә кануны. Коръән иңгәннән соң ярлыларның хәле җиңеләя. Дин елаганнарның яшен сөртә, кайгылыларның кайгысын бетерә. Ул хәләлне, харамны, яхшыны, начарны аерырга өйрәтә. Аллаһы Тәгалә кешене мәңгелек тормышка әзерләү өчен яраткан. Аны аңлаган кеше бәхетле. «Үлдең – беттең» дип уйлаган кеше – бәхетсез. Шуның өчен халык дин тәрбиясенә бигрәк тә мохтаҗ. Тормышыбыз җиңел, күңелле, бәрәкәтле, имин булсын дисәк, диннән аерылмыйк. Мәчетләргә йөрик, намаз укып, догалар кылыйк. Гомер кыска. Җан, әлбәттә, мәңгелек. Кешенең дөньяда алтмыш, җитмеш, сиксән ел яшәве гомернең бик кыска гына өлеше, мәңгелек өлеш Ахирәттә. Раббыбыз иманнарыбызны куәтле, ризыгыбызны киң, тәннәребезне сәламәт, көннәребезне тыныч, илебезне имин, гомеребезне бәхетле кылса иде. Аллаһү Әгъләм.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Әдип хәзрәт Шакиров,*

*Алексеевск районы, Югары Татар Майнасы авылы имам-хатыйбы*

*26 нчы ноябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 21 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Оятың булмаса – ни теләсәң, шуны эшлә

Барлык мактаулар – һәрнәрсәнең хуҗасы булган Аллаһы Тәгаләгә! Күңел түрләребездән чыккан салават шәрифләребез, сәламнәребез Раббыбызның сөекле расүле, ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә һәм алардан хак динебезне кабул итеп алып, гомерләрен жәлләмичә безгә кадәр ирештергән барлык галимнәребезгә, остазларыбызга ирешсен! Аллаһы Тәгалә ошбу җомга көнебезне бәрәкәтле кылып, Үзенең ризалыгына ирештерсә иде!

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйтә: «Оялу һәм иман бер-берсенә бәйләнгән, боларның берсе булмаса, икенчесе дә булмый.» Ягъни тормышыбыздагы иң мөһим нәрсәбез – иманыбызны саклый торган иң кирәкле сыйфатларның берсе – ул оялу булып тора. Бу хис, әлбәттә, Раббыбыз тарафыннан тумыштан йөрәкләребезгә салына һәм тәрбиягә карап, йә ныгый яисә һәлак була. Нинди дә булса ярамаган гамәлебезне башкаларның белүеннән, күрүеннән кыенсыну тойгысы гөнаһлардан саклый торган иң нык калканнарның берсе. Юкка гына Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Оялмасаң, нәрсә телисең шуны эшлә», – дип әйтмәгән! Кызганычка, җәннәтләргә алып бара торган әлеге сыйфат бүгенге көндә ниндидер кимчелек буларак кабул ителә. Шуның нәтиҗәсе буларак, динебез тыйган бар төр гамәлләр ачыктан-ачык кылына башлады. Шуңа күрә әби-бабаларыбыз балаларын тәрбияләгәндә оялу мәсьәләсенә бик каты игътибар иткән. Моңа мисал

буларак татар телебездә начарлык эшләүчегә, ярамаган нәрсәләргә «оятсыз», «оят җир», «оят сүз», «оят гамәл», дигән сүзләр кулланыла. Әлбәттә, беренче чиратта, кеше Аллаһыдан оялырга тиеш, шул вакытта гына начар гамәлләрдән тыелып була. Башкалар күрмәгәндә, үзебез генә калганда гөнаһлардан безне нәрсә тыя ала, бары тик Аллаһыдан курку һәм оялу. Ә моның өчен безнең Раббыбызга инануыбыз, ышануыбыз бик көчле булырга тиеш. Без динебезнең төп өлешеннән булган ихсан дәрәҗәсенә омтылырга тиеш. Ә нәрсә ул ихсан? Ихсан – Аллаһыга Аны күргән кебек гыйбадәт кылу, без Аны күрмәсәк тә, Ул безне күреп торганын аңлау, тою ул. Йөрәкләребезне пакьләү, изге гамәлләр кылу юлында Раббыбыз ярдәмнәрен һәрбарчабызга насыйп итеп, безне бу юнәлештә галим булган остазлардан, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең варисларыннан аермаса иде!

Балаларыбыз оятсызлык юлыннан китмәсен дисәк, җәмәгать, беренче чиратта үзебездән башларга кирәк. Аллаһы Раббыбыз күңелләребездә нәрсә барлыгын белә, шуңа күрә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хәтта яман уйлар уйлаудан да оялыгыз», – дип әйткән. Әгәр без үзебез сөйләшкәндә сүгенү сүзләре кулланабыз икән, гаурәт җирләребезне капламыйбыз икән, тәрбия мәсьәләсен телевизор һәм смартфонга калдырабыз икән – гаеп үзебездә. Балаларыбыз безнең янәшәбездә булмаганда битебезне кызартырлык гамәл кылуларыннан нәрсә саклый, әлбәттә, оялу хисе! Ә гаурәт мәсьәләсе, җәмәгать, күңел сәламәтлегенә зур тәэсир ясый. Гаурәт ачылудан кеше оялмый башласа, башка нәрсәләрдән дә оялу бетә башлый. Игътибар итсәк: кешене хайваннан аера торган билгеләрнең берсе – ул кием кию. Үзебезнең дәүләтебездә яшәүче халыкларның милли киемнәренә игътибар итсәк, барысы да гаурәтне каплый торган. Адәм атабыз белән Хавва анабыз ярамаган агачтан ашагач, гаурәт җирләре ачылып, алар җәннәт яфраклары белән үзләрен капларга тотындылар. Коръәндә китерелгән бу вакыйгадан нәрсә аңларга була? Беренчедән,

ярамаган гамәл белән гаурәт ачылу арасында ныклы бәйләнеш бар. Икенчедән, оялу хисе иң беренче кешеләрдән үк килгән, тумыштан салынган, кешене кеше иткән бик кыйммәтле сыйфат.

Ихласлык киму, оялчанлык бету аркасында шытып чыга торган, бүгенге көндә яшьләр арасында таралган тагын бер начар гадәт – ул сүгенү. Фикерләсәк, күп очракта оят сүзләр шул ук гаурәт, тәннең оят җирләре белән бәйле. Бүгенге көндә, бигрәк тә социаль челтәрләрдә бу күренешләр киң таралды. Төрле бозык җырлар, биюләр «мода», «тренд» дигән матур сүзләр астында яшьләр күңеленә сеңдерелә. Берсүзсез балаларыбыз, оныкларыбыз, энеләребез, сеңелләребез артыннан 24 сәгать буе күзәтеп, тикшереп тора алмыйбыз, әмма Аллаһы Тәгалә барыбызны да һәрвакыт күреп, ишетеп, белеп торганын күңелләренә сала алсак, тәрбия мәсьәләсендә бик зур адым ясаган булабыз.

Раббыбыз Аллаһы ошбу сынау дөньясын матур итеп үтәргә насыйп итсә иде, Ахирәттә оятка калудан сакласа иде, йөрәкләребезгә Сәййидел мөрсәлин Расүли Әкрам Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм, гаиләсе, сәхабәләре һәм аларга иярүчеләргә карата сөю хисе салса иде, алар дәрәҗәсенә беркайчан да җитә алмасак та, Кыямәт көнендә алар янәшәсендә булып мәңгелек бәхеткә ирешергә һәммәбезгә дә насыйп әйләсә иде! Әмин!

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып

яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рәмис хәзрәт Фәсахов,*

*Алексеевск районы, Урта Тигәнәле авылы имам-хатыйбы*

*3 нче декабрь вәгазе,*
*рабигыль-ахыр аеның 28 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Аяк кузгалмас көн

Барча галәмнәрне Яратучы, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булсын! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, ныклы сәламәтлек насыйп итсә иде!

Татар халкында бер тирән мәгънәле әйтем бар: «өч көнлек дөнья». Бу сүзләр нигезсез барлыкка килмәгән. Исламдагы борынгы галимнәребез дә шул ук сүзләрне әйтеп калдырганнар. Хәсән Әл-Басри рахмәтуллаһи галәйһи исемле табигыйн: «Бу дөнья 3 көннән тора: кичә, бүген, иртәгә. Кичәге көн инде барлык әйберләре белән үтеп китте. Иртәгә синең өчен килеп тә җитмәскә мөмкин. Синең көнең – ул бүген. Шуңа да аны кыйммәтлә һәм иң яхшы рәвештә куллан», – дип әйтеп калдырган. Шул сәбәпле, без бу дөньядагы һәр көнне кадерләп, кылган гамәлләребезне уйлап яшәргә тиешлебездер. Ә ни өчен? Вәгазебезнең темасына якынрак килеп әйтсәк, чөнки аяк кузгалмас көндә бу гамәлләрнең барысы өчен дә җавап бирәсе булачак бит.

Кыямәт көненә, үлгәннән соң терелүгә ышану – иман баганаларының берсе булып тора. Мөэмин-мөселман моңа ышана, иман китерә һәм, анда аны Аллаһы Тәгаләнең хисабы көтәчәген яхшы белә.

Бу көннең кайчан җитәсен, анда нәрсәләр буласын Аллаһы Тәгалә генә белә. Әмма без Аллаһы Тәгалә Үзе һәм Аның пәйгамбәре Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтеп калдырганнардан чыгып, гел бу көнне искә алырга, анда булачак вакыйгалар – хисап тоту, гамәлләрнең үлчәнүе, Сират һәм башкалар турында уйланырга тиешлебездер.

Бәрзах тормышы тәмамланганнан соң, Кыямәт көне җитәр. Исрафил галәйһиссәлам сурга өреп, җаннар кабаттан үз тәннәренә кайтырлар. Һәм хәтта бу көнне инкяр иткән кешеләр дә аның хаклыгын аңларлар.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَنُفِخَ فِى ٱلصُّورِ فَإِذَا هُم مِّنَ ٱلْأَجْدَاثِ إِلَىٰ رَبِّهِمْ يَنسِلُونَ ﴿٥١﴾ قَالُوا۟ يَٰوَيْلَنَا
مَنۢ بَعَثَنَا مِن مَّرْقَدِنَا ۜ هَٰذَا مَا وَعَدَ ٱلرَّحْمَٰنُ وَصَدَقَ ٱلْمُرْسَلُونَ ﴿٥٢﴾

**«[Икенче мәртәбә] Сурга өреләчәк. Һәм менә алар [яткан] каберләреннән [торып] ашыга-ашыга, Раббыларына ашыгырлар. Алар [мәхшәр дәһшәтенә нисбәтле кабер газабын йокы дип санаучылар]: «Ни үкенеч безгә! Безне йоклаган җиребездән кем торгызды?» – дип әйтерләр. [Шулвакыт фәрештәләр]: «Бу – Рахман [булган Аллаһы] вәгъдә иткән нәрсә. Җибәрелгәннәр [терелтелеп, хисапка тартылачагыгызны белдергән чакта] дөресен сөйләгән булганнар» [дип әйтерләр]».**

«Йәсин», 36:51-52

Каберләреннән кубарылып, кешеләр мәхшәр мәйданына җыела башларлар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кешеләрнең бу мәйданга җыелу рәвеше дә төрле була дип әйтте. Изге гамәл кылучыларга фәрештәләр киемнәр кидертерләр, алларында һәм артларында нур булган кешеләр дә булыр. Аларның кайберләре җәяү, кайберләре атланып киләчәкләр. Әмма җирдән аяклары белән атлап түгел, йөзләре белән өстерәлеп килүчеләр дә булачак. Аллаһы сакласын!

Кыямәт көненең икенче исеме Хисап көне. Бу, чыннан да, бөек, гаделхисап көне булачак. Кемнәрнедер, әлбәттә, Аллаһы Тәгалә хисапсыз җәннәтле итәчәк, тик кемнәргәдер бу хисапны тотарга туры киләчәк. Хисап та һәр кеше өчен төрле булачак: кемгәдер аны үтү авыр булачак, кемгәдер – җиңел.

Хисап турында күпме генә әйтсәк тә, без аны күз алдына да китерә алмыйбыз. Әмма Аллаһы Тәгалә безгә шул хисапка әзерләнер өчен бу тормышны бирде. Һәм безгә Ахирәтебезне кайгыртып, бу тормышта аңа ныклы итеп әзерләнергә кирәктер, чөнки Гали бине Әби Талиб радыяллаһу ганһе болай дип әйтеп калдырды: «Бүген – хисапсыз гамәл көне, иртәгә – гамәлсез хисап көне».

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә болай дип әйткән: «Кыямәт көнендә дүрт төрле әйбер турында соралмый торып, кеше аягын да атлый алмаячак. Тормышы турында: аны ничек итеп үткәрде. Гыйлеме турында: ул аны нәрсәгә кулланды. Малы турында: ничек итеп кәсеп кылды һәм нәрсәгә сарыф итте. Тәне турында: аны ничек итеп кулланды».

Дөньяга туган һәр кешегә бирелә торган әйбер – гомер. Озынмы ул, кыскамы, бәхетле гомерме ул, юкмы, әмма һәр кешенең аңа бүленеп бирелгән гомере бар. Икенче төрле тормыш дип тә әйтергә буладыр. Һәм, әлбәттә, кеше Кыямәт көнендә тормышы хакында соралачак. Бирелгән гомерен гыйбадәттә, изгелектә, Аллаһы Тәгалә кушкан юлда булып үткәрдеме? Әллә киресенчәме? Кемдер чирек гасыр яшәп тә, Ахирәте өчен багаж тупларга тырышып калган була, ә кемдер бер гасыр яшәп тә, вакытын бушка уздырудан кала еракка китмәгән була. Әмма онытмыйк, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

وَمَا خَلَقْتُ ٱلْجِنَّ وَٱلْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Икенче соралачак нәрсә – гыйлем: безнең җирлекне алып карасак, баланы инде балалар бакчасында укырга-язарга өйрәтә башлыйлар, аннан соң ул 11 ел мәктәптә гыйлем ала. Аны тәмамлагач, югары уку йортында тагын биш ел укый, аннан соң магистратурада – ике ел, аннан аспирантурада 3 ел укый. Шулай итеп, 20 елдан артык вакыт бертуктаусыз гыйлем алуга гына кайтып кала. Ә хәзер үзегезгә үзегез сорау бирегез: тормышыбызның никадәр вакытын без дини гыйлем алуга юнәлтәбез? Дөреслектә, кеше бар гомерен гыйлем алуга юнәлтергә тиеш, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бишектән алып ләхеткә кадәр гыйлем алыгыз», – дип әйтеп калдырган. Ә Кыямәт көнендә кеше үзенең гыйлемен ни рәвешле алганын, ул гыйлемне нинди юлда кулланганы өчен җавап тотачак.

Өченче соралачак нәрсә – мал. Кеше малны ничек тапканы, аны кайларга сарыф иткәне турында соралачак. Гөнаһ һәм изгелекнең тузан бөртеге кадәрлесе дә билгеле булган кебек, монда да, һәрбер тоткан тиенебез өчен дә җавап көтә.

Шулай ук, кешедән тәне турында да сораячаклар. Барыбыз да тәнебезнең безнең өчен әманәт икәнен яхшы беләбез. Шуңа да, тәнебезгә карата нинди мөнәсәбәттә идек: авыру килсә, аны сәламәтләндерергә тырыштыкмы, аны хәләл ризык белән тукландырдыкмы – болар барысы да соралачак. Кулларыбыз белән нәрсә тоттык, ни эшләдек, аякларыбыз белән нинди җирләргә бардык: харам кылына торган җирләргәме, әллә инде Аллаһыны искә ала торган урыннаргамы?

Кыямәт көнендә кешегә бу һәм башка сораулар бирелер. Изге гамәлләре вә гөнаһлары күрсәтелер. Беркая да качып булмас! Дәшмичә генә калырга уйласак та, ул безгә һич булыша алмас. Аллаһы Тәгалә

Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

ٱلْيَوْمَ نَخْتِمُ عَلَىٰٓ أَفْوَٰهِهِمْ وَتُكَلِّمُنَآ أَيْدِيهِمْ وَتَشْهَدُ أَرْجُلُهُم بِمَا كَانُوا۟ يَكْسِبُونَ ﴿٦٥﴾

**«Ул көнне [кылган гөнаһларны инкяр итәр өчен кискен бер сүз көрәштерүгә керешкән чакларында] аларның авызларын мөһерләрбез һәм [дөньяда] аларның ни кылганнарын куллары сөйләр, аяклары шаһитлык итәр».**

«Йәсин», 36:65

Әмма гөнаһ кылып, Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәмичә, тыйганнарыннан тыелмыйча йөргән кешеләргә дә татар халкының тагын бер әйтеме бар: унбиш көннең «бәйрәме» бер була! Бәйрәм дигәндә, әлбәттә, киная ятканын аңлагансыздыр. Син әле яшь, син әле көчле, син әле бай кебек сүзләргә алданып яшәмик! Бүген акча җыям, иртәгә садака бирермен дип алданмыйк, иртәгә үк фәкыйрьлек килергә мөмкин. Яшь вакытта эшләп калыйм, картайгач мәчеткә йөрермен димик, картлык белән гәүдәгә зәгыйфьлек килеп, селкенергә дә кыен көннәр җитәргә мөмкин. Ә иң мөһиме, шуларга алданып, шушы «унбиш» көн үтәчәк. Һәм инде Аллаһы Тәгалә каршына баскач, бары тик җавап бирү генә кала. Бернинди гамәл кылып булмас: намаз укып, садака биреп, сөйләшмәгән туганнарыбыз белән яхшы мөгамәлә корып та. Бары тик хисап тоту гына булачак.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының

саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы, Хәсәншәех авылы имам-хатыйбы*

*10 нчы декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Киң ризыклы булыйм дисәң...

Барча мактау-данлау Аллаһы Тәгаләгә! Без Аңа шөкрана кылабыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аның ярлыкавын үтенәбез! Үзебезнең начарлыгыбыздан, бозык гамәлләребездән Аллаһы Тәгаләдә сыену эзлибез! Аллаһы Тәгалә туры юлга күндерсә, берсе дә аларны адаштырмас, адаштырганнарны исә берсе дә туры юлга кертмәс. Аллаһыдан башка гыйбадәткә лаеклы зат һич юк, Ул берүзе, тиңдәшсез һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аның колы һәм илчесе!

Байлыкка, киң ризыкка омтылу – адәм балаларының табигый сыйфаты. Бу сыйфатны Аллаһы Тәгалә безнең күңелебезгә салган. Динебез дә кешенең бу табигый сыйфатына каршы килми, хәтта, киресенчә, ризыкка омтылырга, хәләл юллар белән кәсеп итәргә, башкаларга мохтаҗ булмаска өнди.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

فَإِذَا قُضِيَتِ ٱلصَّلَوٰةُ فَٱنتَشِرُواْ فِى ٱلْأَرْضِ وَٱبْتَغُواْ مِن فَضْلِ ٱللَّهِ وَٱذْكُرُواْ ٱللَّهَ كَثِيرًا لَّعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ﴿١٠﴾

**«Намаз беткәч, җирдә таралыгыз, Аллаһының фазылыннан [файдагызны] эзләгез һәм Аллаһыны [бөтен хәлләрегездә дә] зикер кылыгыз. Бәлки, сез [ике җиһанда да] уңышка [һәм котылуга] ирешә алырсыз».**

«Җомга», 62:10

«Әл-Мүльк» сүрәсендә дә Аллаһы Тәгалә хәләл ризыкларга омтылырга өндәп болай дип әйтә:

هُوَ ٱلَّذِى جَعَلَ لَكُمُ ٱلْأَرْضَ ذَلُولًا فَٱمْشُوا۟ فِى مَنَاكِبِهَا وَكُلُوا۟ مِن رِّزْقِهِۦ ۖ
وَإِلَيْهِ ٱلنُّشُورُ ﴿١٥﴾

**«Ул җирне сезгә буйсындырды. Аның җилкәсендә [тауларында һәм тигезлекләрендә] йөрегез һәм Аның ризыгыннан ашагыз. Терелүегез [һәм кайтуыгыз] Аңа гына бит. [Менә шулвакыт сездән бу нигъмәтләр өчен шөкердә булу-булмавыгыз сораначак]».**

«Әл-Мүльк / Хөкемдарлык», 67:15

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә байлык турында мондый сүзләр әйткән: «Хәерле кешенең кулындагы хәерле байлык никадәр күркәм!»[1]

Иң күп байлыкка ия булган сәхабәләрнең берсе Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе болай дип әйтә торган булган: «Мал-мөлкәт ни күркәм әйбер! Аның аркылы мин үз намусымны саклыйм һәм Раббыма якынаям».

Күргәнебезчә, динебез байлыкка, киң ризыклы булуга каршы килми. Хәләл юл белән ризык, байлык табу һәм аны дөрес итеп куллану Аллаһы Тәгалә каршында мактаулы гамәл. Алай гына да түгел, динебез безгә Аллаһы Тәгаләдән килә торган ризыкны арттыра торган, булган малга бәрәкәт бирә торган сәбәпләрне өйрәтә. Киң ризыклы, мул тормышлы булыйм дисәң, Аллаһы Тәгалә биргән шул сәбәпләрне кулланырга кирәк. Аларның кайберләрен искә алып китик:

1. Малың бәрәкәтле булуның бер сәбәбе – ризыгыңны бары тик хәләл юл белән генә табу.

Гамра бинте Әл-Харис радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шушы сүзләрен китергән: «Бу дөнья татлы һәм сусыл һәм кем бу дөньядан хәләлне кәсеп итеп алса, аңа шул алганында

[1] Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

бәрәкәт булыр. Ләкин күпме кешеләр хәләлнең чигеннән чыгып, Кыямәт көнендә җәһәннәм утына дучар булырлар?!»[1]

Әбү Өмәмә радыяллаһу ганһе риваять иткән хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дөреслектә, Җәбраил фәрештә минем күңелемә шулай дип вәхи салды: әҗәл вакыты килеп җитмичә һәм үзенә тиешле ризыкны алып бетермичә бер кеше дә үлмәс. Шулай булгач, Аллаһыдан куркыгыз һәм хәерле, хәләл юллар белән генә ризыкка омтылыгыз. Һәм дә ризыгым соңга кала дип харам юллар аркылы ул ризыкны алырга тырышмагыз, чөнки Аллаһыда булган әйберне Аңа буйсынып кына алып була!»[2]

2. Тагын бер сәбәп – тәкъвалык, ягъни Аллаһы Тәгаләнең җәзасыннан куркып, кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә тырышу.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَن يَتَّقِ ٱللَّهَ يَجْعَل لَّهُۥ مَخْرَجًا ﴿٢﴾ وَيَرْزُقْهُ مِنْ حَيْثُ لَا يَحْتَسِبُ ۚ
وَمَن يَتَوَكَّلْ عَلَى ٱللَّهِ فَهُوَ حَسْبُهُۥٓ ۚ إِنَّ ٱللَّهَ بَٰلِغُ أَمْرِهِۦ ۚ قَدْ جَعَلَ ٱللَّهُ لِكُلِّ
شَىْءٍ قَدْرًا ﴿٣﴾

> **«Кем дә кем Аллаһыдан курыкса, Ул аңа [үлем куркынычлыгыннан, Кыямәт көненең кыенлыкларыннан] бер чыгыш [юлы] насыйп итә. Һич көтмәгән ягыннан аны ризыкландыра. Кем дә кем Аллаһыга тәвәккәл кыла, аңа Ул җитә. Һичшиксез, Аллаһы һәрнәрсә өчен [ул әле бар булганчы] бер үлчәм куйган».**

«Әт-Талак», 65:2-3

3. Бу дөньяны гына кайгыртмыйча, Ахирәт тормышына омтылу. Ахирәт өчен тырышу шулай ук ризыкны киңәйтә, малны арттыра.

---

1 Имам Әт-Табәрани, «Әл-Кәбир» 24/340.

2 Әбү Нүгәйм, «Әл-Хильйә» 10/27.

Зәед бине Сәбит радыяллаһу ганһе риваять иткән хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кемнең төп омтылышы бу фани дөнья булса, Аллаһы Тәгалә аның эшләрен таратып атыр һәм аның күз алдында һәрвакыт фәкыйрьлек булыр. Ә кемнең төп омтылышы Ахирәт тормышы булса, Аллаһы Тәгалә аның эшләрен җыяр, тәртипкә салыр, аңа күңел байлыгы бирер һәм бу дөнья үзе шул кеше каршына килеп басар»[1].

Имам Әс-Синди болай дип әйткән: «Бәндәгә язылган ризык аңа ирешмичә калмас. Ләкин, Ахирәт тормышын кайгыртучы кешегә ризыгы артык борчу-мәшәкать күрмичә килер, ә бу дөньяны гына кайгыртучыга ризыгы борчу-мәшәкать аркылы килер. Ахирәткә омтылучы кеше өчен бу дөнья да, Ахирәт тә җыелыр».

4. Малны арттыра торган сәбәпләрдән – Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу, намаз уку. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кодси хәдистә Аллаһы Тәгаләнең сүзләрен китерә: «Әй, Адәм баласы, Миңа гыйбадәт кылыр өчен вакыт тап, Мин синең күңелеңә байлык салырмын һәм сине мохтаҗлыктан арындырырмын. Әгәр алай эшләмәсәң, синең күңелеңне борчу белән тутырырмын һәм мохтаҗлыктан арындырмам»[2].

«Та Һә» сүрәсендә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَأْمُرْ أَهْلَكَ بِٱلصَّلَوٰةِ وَٱصْطَبِرْ عَلَيْهَا ۖ لَا نَسْـَٔلُكَ رِزْقًا ۖ نَّحْنُ نَرْزُقُكَ ۗ وَٱلْعَـٰقِبَةُ لِلتَّقْوَىٰ ﴿١٣٢﴾

**«Гаиләңә [һәм өммәтеңә] намазны әмер ит. Үзең дә сабырлык белән аны үтә. Без синнән ризык сорамыйбыз. Сине Без ризыкландырабыз. [Куанычлы] Ахыр – тәкъвалык [ияләре] өчен».**

«Та Һа», 20:132

1 Имам Әхмәд 5/183, имам Ибне Мәҗе 4105, имам Ибне Хиббән 72.

2 Имам Әхмәд 2/358, имам Ибне Мәҗе 4107, имам Әт-Тирмизи 2466.

Тәфсир галиме имам Ибне Кәсир болай дип әйткән: «Әгәр дә син намазларыңны тиешенчә үтәп барсаң, ризыгың сиңа көтмәгән җирләрдән дә килер».

5. Аллаһы ризалыгы өчен бирелгән садака да байлыкка китерә торган сәбәп.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

قُلْ إِنَّ رَبِّى يَبْسُطُ ٱلرِّزْقَ لِمَن يَشَآءُ مِنْ عِبَادِهِۦ وَيَقْدِرُ لَهُۥ ۚ وَمَآ أَنفَقْتُم مِّن شَىْءٍ فَهُوَ يُخْلِفُهُۥ ۖ وَهُوَ خَيْرُ ٱلرَّٰزِقِينَ ﴿٣٩﴾

**«[Расүлем!] Әйт: «Һичшиксез, минем Раббым [теләгән чагында] колларыннан теләгәненә ризыкны киңәйтә, [теләгән чагында] аңа тарайта. Әмма [изге юлда] нәрсә дә булса сарыф итсәгез, Ул аның урынына [кат-кат арттырып] алмашын бирер. Ул – [бөтен ризыкларны бар иткән Аллаһы булганлыктан] ризык бирүчеләрнең иң хәерлесе».**

«Сәбә», 34:39

Аллаһы Тәгалә юмарт һәм Ул юмартлыкны ярата. Башкаларга карата юмарт булучыга Аллаһы да юмартлык кыла.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дип әйткән: «Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә әйтә: «Әй, адәм баласы, садака бир, Мин дә сиңа бирермен»[1].

6. Малны арттыра торган сәбәпләрдән күп итеп истигъфар кылу, ягъни, Аллаһы Тәгаләдән гөнаһларыбызны кичерүен сорау.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

[1] Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан, 4684; имам Әл-Мөслимнең хәдисләр җыентыгыннан, 993.

فَقُلْتُ ٱسْتَغْفِرُوا۟ رَبَّكُمْ إِنَّهُۥ كَانَ غَفَّارًا ﴿١٠﴾ يُرْسِلِ ٱلسَّمَآءَ عَلَيْكُم مِّدْرَارًا
﴿١١﴾ وَيُمْدِدْكُم بِأَمْوَٰلٍ وَبَنِينَ وَيَجْعَل لَّكُمْ جَنَّٰتٍ وَيَجْعَل لَّكُمْ أَنْهَٰرًا ﴿١٢﴾

**«Мин әйттем: «Раббыгыздан ярлыкау сорагыз. Һичшиксез, Ул – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче. [Истигъфар кылыгыз, җитмеш ел дәвам иткән корылык һәм кытлыктан соң Раббыгыз] Күкне өстегезгә [чиләктән койган кебек] мул яуган бер хәлдә җибәрер. Маллар һәм ир балалар белән сезгә ярдәм итәр [һәм киң мөмкинлекләр бирер], сезнең [файдалануыгыз] өчен бакчалар үстерер һәм сезнең өчен [ургылып аккан] елгалар булдырыр».**

«Нух», 71:10-12

Имам Ибне Кәсир болай дип әйткән: «Кем шушы сыйфатка ия була, ягъни тәүбә-истигъфар кыла, Аллаһы Тәгалә аңа ризык килү юлларын, аның эшләрен җиңеләйтер һәм ризык табуда ару-талудан саклар»[1].

7. Шулай ук туганнар белән араны ныгыту, туганлык җепләрен саклау да киң ризыклы итә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Алдында шушы дөнья ризыгы ачылып китүен һәм гомере озынаюын теләгән кеше туганлык җепләрен ныгытсын»[2].

Башка бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Туганнарыгыз белән араны саклар өчен үз нәсел шәҗәрәләрегезне өйрәнегез, чөнки туганлык җепләрен саклау туганнар арасына мәхәббәт сала, байлыкны арттыра һәм гомерне озынайта»[3].

1 «Тәфсир Ибне Кәсир» 4/329.

2 Имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

3 Имамнар Әхмәд, Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

8. Байлыкка, мал-мөлкәткә омтылучы кеше кулланырга тиешле тагын бер сәбәп – дога кылып, Аллаһыдан ризыкны арттыруны сорау.

Кодси хәдистә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә: «Әй бәндәләрем! Мин ризыкландырган кешеләрдән кала сез барыгыз да ачсыз. Шулай булгач, Миннән ризык сорагыз, Мин сезне ризыкландырырмын. Әй, бәндәләрем! Мин киендергәннәрдән кала сез барыгыз да ялангач. Миннән кием сорагыз, Мин сезне киендерермен»[1].

Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вә сәлләм нинди генә хаҗәтең туса да беренче чиратта аны хәл итү өчен Аллаһыга мөрәҗәгать итәргә кушкан: «Кем берәр мохтаҗлыгыннан арыныр өчен кешеләргә мөрәҗәгать итсә, кешеләр аны ул мохтаҗлыктан арындырмаслар. Ә кем мохтаҗлыгы белән Аллаһыга мөрәҗәгать итсә, Аллаһы Тәгалә иртәме соңмы, һичшиксез, аңа ризыгын җибәрер»[2].

Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вә сәлләмнең һәрдаим кылган иртәнге догаларыннан шушы дога да бар: «Йә, Аллаһым, Синнән файдалы гыйлем, хәерле ризык һәм кабул була торган гамәлләр сорыймын».

Мөхтәрәм җәмәгать! Без ризыкны арттырырга ярдәм иткән сәбәпләрнең кайберләрен санап уздык. Әгәр дә шушы сәбәпләрне кулланса к, һичшиксез, Аллаһы Тәгалә нәтиҗәсез калдырмаячак. Әгәр дә Аллаһыдан башка да ризыклы була алабыз дип уйласак, киресенчә, хәсрәткә төшүебез бар. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

أَمَّنْ هَٰذَا ٱلَّذِى يَرْزُقُكُمْ إِنْ أَمْسَكَ رِزْقَهُۥ ۚ ... ﴿٢١﴾

**«Сезгә Ул [корылык бер сәбәп белән] ризыгын туктатса, кем сезне ризыкландыра алсын».**

«Әл-Мүльк / Хөкемдарлык», 67:21

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан, 2577.

2 Имам Әхмәд, имам Әт-Тирмизи, имам Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан.

Аллаһы Тәгалә һәммәбезгә дә хәерле киң ризыклар, мул тормышлар насыйп итсен, булган малларыбызга бәрәкәт биреп, бу дөньяда да, Ахирәттә дә бәхетле булырга насыйп итсен! Әәмин.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат хәзрәт Сәйфетдинов,*

*Теләче районы Сауш авылының «Хәлил» мәчете имам-хатыйбы*

*17 нче декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# «Әдәпле надан тәрбиясез галимнән хәерлерәк»

Барча галәмнәрне юктан бар кылучы, барлык мәхлүкатларны тәрбия кылучы, Кыямәт көненең Хуҗасы булган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмед-сәналәребез, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз ирешсә иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең хәбибе, хак расүле Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә йөрәкләребез түреннән чыккан салаватларыбыз һәм сәламнәребез булса иде. Хөрмәтле дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Ислам динендә күркәм әхлаклы шәхес тәрбияләү – төп максатларның берсе булып тора. Шәригать кануннары Коръәндә әхлакый кагыйдәләр, кешенең үз-үзен тотышы, эчке дөньясы, фикерләве белән тыгыз бәйләнештә бирелгән. Коръәндә тугрылык, ихласлылык, юмартлык, сүз һәм гамәл берлеге, шәфкатьлелек, ата-ананы хөрмәт итү, сабырлык һәм башка шундый күркәм әхлакый сыйфатлар мактала, аларның тискәреләре, киресенчә, төрлечә хөкем ителә.

Ислам дине тынычлык, халыклар арасында дуслык булдыру, үзара ярдәмләшүне алга сөрә, кешеләрне бозыклык эшләүдән тыя.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَإِنَّكَ لَعَلَىٰ خُلُقٍ عَظِيمٍ ﴿٤﴾

**«Һәм син, һичшиксез, югары әхлак иясе. [Олуг пәйгамбәрләр кебек, син дә чыдый алмаслык михнәтләрне кичерәсең]».**

«Әл-Каләм», 68:4

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе дә бер хәдисендә болай дип әйткән: «Мин күркәм әдәпне вә әхлакны югары рәвешкә җиткерер өчен җибәрелдем».

Ислам тормышның барлык өлкәләрендә дә әдәпле, тыйнак, сабыр, гүзәл әхлаклы булырга чакыра. Әдәпле булу өчен гыйлем кирәкме? Әйе, әйе! Акны карадан, яхшыны яманнан аера белү өчен азмы-күпме гыйлем кирәк булыр. Әмма ул гыйлем генә кешене галим дип санарга җитмәс, шуның өчен без аларны әлегә әдәпле надан исеме белән йөртик. Әдәплелек социаль киеренкелекне киметә һәм җәмгыятьтәге элемтәләрне ныгыту чарасы да булып тора. Әхлаклылык – милләт көченең нигезе, ә әхлаксызлык милләтнең таркалуына, түбәнгә тәгәрәвенә сәбәпче була.

Әдәпле надан кешеләргә игътибарлы, инсафлы була. Ул кеше һәрвакыт үзенең якыннары, дуслары турында кайгыртып яши, аларга гел ярдәм итәргә әзер тора. Әдәпле наданның кулыннан һәм теленнән һичкем зыян яки зарар, җәбер-золым, кимсетүләр күрмәс, кеше малына кул сузмас, ислам дине кысаларына сыймаган сүзләр әйтмәс. Ул әдәпле инсан, надан булса да, ул барлык нәрсәләргә рәхмәт күзлеге аша карый. Ул үзенең Раббысына гөнаһ кылудан курка, ул тәкъва зат һәм шуңа да тәкъва кешеләр белән бергә булырга тырыша.

وَمَآ أَرۡسَلۡنَٰكَ إِلَّا رَحۡمَةٗ لِّلۡعَٰلَمِينَ ﴿١٠٧﴾

**«[Расүлем!] Без сине [җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп] бөтен галәмнәр өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107

Әдәпле надан шушы аятькә дә муафыйк рәвештә яшәргә тырыша дигән сүз. Бәлкем әле ул бу аятьнең барлыгын да белмидер.

Тәрбиясез вә әхлаксыз галимнәр хакында Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Кешеләрнең иң әхлаксызлары, явызлары – явыз галимнәрдер».

Ни өчен соң пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай дигән? Хакыйкатьтә, әхлаксыз вә тәрбиясез галимнәр белә торып гөнаһ кылалар. Белә торып гөнаһ кылу белмичә кылганга караганда күпкә начаррак, җәзасы да катырактыр. Аллаһы сакласын.

Хәдисләрдән аңлашылганча, тәрбиясез галимнәр әнә шундыйлардан. Аларның кайбер сыйфатларын санап үтик:

1) алган гыйлемнәре белән гамәл кылмыйлар;

2) гыйлемнәрен дөньяви максат өчен генә кулланалар;

3) халык алдында мактаналар, наданнар белән тарткалашалар; мәҗлесләрдә түрдә утырып, игътибарны үзенә генә юнәлдерергә, җәлеп итәргә тырышалар;

4) үзләрендә монафикълык чире, гамәлләре – риядыр;

5) кара көнчелек белән авырыйлар;

6) имамнарга буйсынмаслар, дин кагыйдәләренә җиңел карыйлар;

7) башкаларны түбәнсетәләр;

8) «Мин – галим» дип, масаеп йөрерләр;

9) дингә төрле яңалык, бидгать кертергә тырышалар;

10) тәкъва булып күренергә тырышып, кешеләр хакында начар уйлап сүз йөртәләр, гайбәт тарагалар.

Аңлашылганча, тәрбиясез галим әле ул әхлаксыз да була, чөнки тәрбиясез генә, галимме ул яки наданмы ул, шундый гамәлләр кыла ала.

Әгәр дә галимнәр һәр эшне Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең Китабы – Коръәни Кәримне дөрес рәвештә аңлатып, тугры булсалар, мөселманнарның хакларын саклаган һәм дә дәрәҗәләрен төшермәгән

булырлар. Киресенчә булса, алар явыз, әхлаксыз вә тәрбиясез галимнәр җөмләсеннән булырлар. Әдәпле наданның гамәлләре күпкә хәерлерәк, шәригать кысаларына сыярлык һәм кешелеклелек сыйфатлары ярылып ята. Тәрбиясез вә әхлаксыз галимнең эшләре исә хәерсез гамәлләр исәбеннән. Мондый гамәлләр кешеләрнең таркалуына, араларының кискенләшүенә, туганлык җепләренең өзелүенә, дошманлыкның артуына, ислам диненә мәхәббәтнең суынуына китерергә мөмкин. Аллаһы сакласын.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنْ أَحْسَنتُمْ أَحْسَنتُمْ لِأَنفُسِكُمْ ۖ وَإِنْ أَسَأْتُمْ فَلَهَا ۚ ... ﴿٧﴾

**«Игелекле гамәл кылсагыз, үзегезгә игелек кылган булырсыз. Начар гамәл кылсагыз – янә үзегезгә генә [чөнки начарлыклар өчен үзегезгә җавап тотарга туры киләчәк]».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:7

Без – кешеләр, бу дөньяда гамәлләр кылуда ирекле. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә разый булырдай яхшы гамәлләр дә, шулай ук Аның ачуына, җәзасына лаек булырдай начар гамәлләр дә кыла алабыз.

Бу аятьтән аңлашылганча: әдәпле надан үзенең гамәле белән үзенә игелек кыла, аның ахыргы урыны җәннәттә булыр, иншәАллаһ. Тәрбиясез галим дә үзе өчен гамәл кыла, тик ул кылган гамәлләрнең нәтиҗәсе начар, җәзага лаек.

Йә Раббым! Алган гыйлемнәребез әхлакларыбызны яхшы якка үзгәртергә ярдәм итсә иде. Һәммәбезгә дә әдәпле, тәрбияле, итагатьле бәндәләр булып яшәргә насыйп булсын. Әәмин.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Кәдим хәзрәт Мөбарәкшин,*

*Буа районы Килдураз авылы мәчетенең имам-хатыйбы*

*24 нче декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Җәһәннәм хакында

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһии әҗмәгыйн.

Барча мактауларыбыз, шөкерләребез бер Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә һәм сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватларыбыз һәм сәламнәребез булса иде. Адәм баласы фани дөньядан Ахирәт дөньясына күчкәннән соң, бу дөньяда ни рәвешле яшәвенә карап, йә җәннәт йортына йә, Аллаһым сакласын, җәһәннәм дип аталган куркыныч урынга эләгә. Әмма мөэмин-мөселман кешесе беркайчан да Аллаһының рәхмәтеннән өметен өзәргә тиеш түгел. Шулай да без җәһәннәм хакында белергә һәм анда эләгүгә сәбәпче булып торган гамәлләрдән ерак булырга тиеш. Нәрсә соң ул җәһәннәм? Анда кемнәр эләгәчәк? Әлеге сорауларны, әлбәттә, динебез Ислам җавапсыз калдырмаган. Аллаһы Тәгалә «Әл-Бәкара» сүрәсендә болай дип әйткән:

فَاتَّقُوا النَّارَ الَّتِي وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ ۖ أُعِدَّتْ لِلْكَافِرِينَ ﴿٢٤﴾

**«...кяферләргә әзерләнгән, ягулыгы кешеләр һәм ташлар булган уттан куркыгыз»;**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:24

«Әл-Мүльк» сүрәсендә болай дип әйтелгән:

وَلِلَّذِينَ كَفَرُوا بِرَبِّهِمْ عَذَابُ جَهَنَّمَ ۖ وَبِئْسَ الْمَصِيرُ ﴿٦﴾

**«Раббыларын инкяр итүчеләр өчен җәһәннәм газабы бар. Ул нинди яман бер бару урыны!»**

«Әл-Мүльк / Хөкемдарлык», 67:6

Димәк, җәһәннәм кяферләр, ягъни Аллаһыны танымаган, Аның барлыгын инкяр иткән кешеләр өчен әзерләнгән.

Җәһәннәмнең кайсыдыр бер ягын сыйфатлаган төрле исемнәре бар:

Ән-нәр – ут.

Җәхим – шулай ук ут дип тәрҗемә кылына.

Җәһәннәм – тәмуг (җәһәнннәм бик тирәк, бу исеме тирәнлегенә карап әйтелә).

Ләза – көйдерә торган ут.

Әс-Сәир – ялкын.

Шулай ук башка исемнәре дә бар.

Җәһәннәмнең хаклыгы, Кыямәт көнендә адәм баласының аның куркынычы белән очрашуы хакында Раббыбыз болай дип әйтә:

وَجِيٓءَ يَوۡمَئِذِۭ بِجَهَنَّمَ ﴿٢٣﴾

**«Шул көнне җәһәннәм [һәрбереннән җитмеш мең фәрештә тоткан җитмеш мең тезген белән тартып] китерелер».**

«Әл-Фәҗр / Таң», 89:23

Мөэмин-мөселман кешесе – Аллаһының киң рәхмәтенә лаек булучы ул. Адәм баласы хатадан хали булмаса да, ул исән булганда, әле бакыйлыкка күчкәнче, хата-кимчелекләрен бетерә һәм кылган гөнаһлары өчен Раббысыннан гафу-истигъфар сорый ала. Шуңа да, хөрмәтле мөселман кардәшләребез, исән-сау булганда, җаныбыз Раббыбыз хозурына күчкәнче, үлем фәрештәсе белән очрашканчы булдыра алганча изге гамәлләр кылып, тәүбә-истигъфар һәм шөкер сүзләре белән гомер итик. Бу җир йөзендә яшәүче кеше никадәр генә гөнаһлы булса да, аның әле зур өмете бар. Ул тәүбә итә, төзәлә ала. Әлеге кыйссада исән кешенең мөмкинлекләре барлыгына дәлил бар.

Бер кеше кабер янында дога кылып утырган җирендә йоклап киткән һәм төшендә шул кабердә җирләнгән кардәшен күргән. Кабердә ятучы

кеше аңа: «Мин синнән көнләшәм, синең гамәл кылырга мөмкинлегең бар, әмма Ахирәт турында гыйлемең юк, ә минем, киресенчә, гыйлемем бар, ләкин гамәл кыла алмыйм. Ике рәкәгать укыган намазың, кылган догаң өчен нинди зур әҗерләр бирелүен белсәң, даими тырышлык куяр идең», – дигән.

Адәм баласын бик нык газаплый торган тойгы бар – ул үкенү. Гадәттә үкенгән кеше үз-үзен гаепли. Үкенгәндә артка юл юк, әмма кеше авыр хәлдә калуын танырга мәҗбүр. Бу дөньяны гафләттә үткәреп, Кыямәт көнендә үкенечкә калган кешеләр хакында Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَأَمَّا مَنْ أُوتِيَ كِتَابَهُ بِشِمَالِهِ فَيَقُولُ يَا لَيْتَنِي لَمْ أُوتَ كِتَابِيَهْ ﴿٢٥﴾ وَلَمْ أَدْرِ مَا حِسَابِيَهْ ﴿٢٦﴾ يَا لَيْتَهَا كَانَتِ الْقَاضِيَةَ ﴿٢٧﴾

**«Кемгә исә китабы сул кулына бирелә, ул [дәфтәрендәге начар гамәлләрне күреп] әйтер: «Аһ, миңа китабым бирелмәсә иде! Хисабымның нәрсәлеген белмәсәм иде! Аһ, бу [дөньяда татыган үлемем] соңгы нәрсә булса иде [дә кабат терелтелмәсә идем]».**

«Әл-Хәкка / Котылгысыз», 69:25-27

Әлбәттә, җәһәннәмнең ниндилеген, аның дәһшәтен без тулысынча күз алдыбызга китерә алмыйбыз. Әмма аның һәркем өчен, хәтта анда эләкмәүче кешеләр өчен дә куркыныч булуы хакында беләбез. Берьюлы сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гомәр бине Әл-Хаттабка: «Әгәр син 70 пәйгамбәрнең изге гамәлләрен кылсаң да, утны күргәч барыбер куркачаксың», – дип әйткән.

Җәһәннәмне тасвирлар өчен, Пәйгамбәребез болай дип хәбәр иткән: «Җәһәннәм утын мең ел буе ак төскә кергәнче, аннан тагын мең ел дәвамында кызыл төскә кергәнче, аннары тагын мең ел кара төскә

кергәнче кыздырдылар».

Җәһәннәм уты кара төн кебек. Әбү Һөрайрадан килгән хәдистә Пәйгамбәребезнең болай дип әйткәне хәбәр ителә: Җәһәннәм уты үзенең Раббысына: «Раббым, минем бер өлешем икенче өлешемне ашады», – дип зарланган. Һәм Аллаһы Тәгалә аңа ике тапкыр сулышын чыгарырга рөхсәт биргән. Бу – кыш көне һәм җәй көне, сез иң каты кызуны һәм иң каты салкынны сизгән вакытта».

Барыбыз да җәйнең нәкъ уртасында түзеп булмаслык эссе көннәр һәм кыш көннәрендә зәмһәрир салкыннар барлыгын беләбез. Бу көннәрдә адәм баласы чыдый алмаслык кызуда һәм салкыннарда үзенең никадәр зәгыйфь һәм Раббысына мохтаҗ зат икәнлеген таный. Әгәр эсседә күләгәле урынга ышыкланып, салкында җылы җиргә кереп суыктан саклана алмаса, табигатьнең әлеге халәте аның сәламәтлеге өчен куркыныч булып тора. Нәкъ менә шушындый көннәрдә без Расүлебезнең әлеге хәдисен искә төшереп, гыйбрәтләнергә тиеш.

Җәһәннәмгә җәһәннәм дип тирәлегеннән чыгып әйтелә дидек. Бервакыт сәхабәләр очып төшкән әйбергә охшаган тавыш ишеткәннәр. Пәйгамбәребез сәхабәләрдән: «Моның нинди тавыш икәнен беләсезме?» – дип сораган. Алар: «Аллаһы һәм Аның Пәйгамбәре яхшырак белә», – дип җавап биргәннәр. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу җитмеш ел элек утка ташланган таш һәм ул әле дә төпкә хәтле төшеп җитә алмады», – дип җавап биргән. Һәм менә шул түбән урын турында сөйләшкәндә, ул түбән урыннның да әһелләре бар бит. Җәһәннәмнең иң түбән урынында булучылар – алар монафикъләр. Бу – Аллаһыны һәм кешеләрне алдап, үзләрен мөселман дип йөргән кешеләр. Икенче төрле әйткәндә, икейөзлеләр. Алар мөселманнар янына килгәч, мөселман булып кылана, әмма, хакыйкатьтә, Аллаһы Тәгаләне танымый һәм мөселманнарны яратмый. Бу хакта Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ الْمُنَافِقِينَ فِي الدَّرْكِ الْأَسْفَلِ مِنَ النَّارِ وَلَنْ تَجِدَ لَهُمْ نَصِيرًا ﴿١٤٥﴾

**«Һичшиксез, монафикълар – Утның иң түбән урынында. Син дә аларга бернинди ярдәмче таба алмассың».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:145

Әлбәттә, Аллаһы кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәсәк, Раббызның рәхмәте белән җәһәннәм дигән куркыныч урынга эләгүдән имин булырбыз. Әмма шунысын аңларга кирәк: Раббыбызның рәхмәтенә ия булу мөһим. Адәм баласы тау кадәрле изге гамәлләр кылып та, тәкәбберлеге белән, мин изге гамәлләр кылуда беренче, мин җәннәтле, дип әйтсә, бик нык ялгышачак. Раббыбызның рәхмәте, мәрхәмәте белән барыбыз да һидаять юлына күнүебезне һәм Аның рәхмәте белән генә гөнаһлардан арынуыбызны истән чыгармыйк.

Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безнең бу дөньяда камил иманлы булып гомер итүебезне һәм Ахирәткә дә иманлы хәлдә күчүебезне насыйп әйләсә иде. Аллаһының рәхмәте белән җәһәннәм газапларыннан имин булып, күркәм җәннәт бакчалары белән хозурлану бәхетенә ирешә алсак иде. Бу дөньяда бер-берләребезне нәсыйхәтләп, бер-берләребезгә үрнәк булып яшәгән кардәшләребез, кадерле гаиләләребез белән һәм безнең өчен рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән җәннәт түрләрдә бергә булсак иде. Әәмин.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып

яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» редакциясе*

*31 нче декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Гөнаһ кылуның кайтавазы

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн. Барча җанлы һәм җансыз барлыкларны яратучы, безгә Үзенең һәрдаим нигъмәтләрен биреп ризыкландыручы, тәрбияләүче, кылган догаларыбызны кабуллардан кылучы Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләребез булсын.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә дөрес итеп ничек яшәргә, ничек итеп Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә һәм дә ризалыгына ирешергә, Аның вәгъдә кылган җәннәтенә керү юлларын өйрәтеп калдырды. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәрбарчаларыбызның күңел түрләрендә булган салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә «Һәрбер кеше үзенең гөнаһысына чорналган» ди. Кеше белеп һәм белмичә гөнаһ кыла. «Гөнаһ» сүзен без бик яхшы белсәк тә, аның асыл-мәгънәсе турында соралса, күпләр ачык җавап бирә алмый. Аллаһы Тәгалә тыйган нәрсәләрне эшләү яки, киресенчә, фарыз гамәлләрне үтәмәү гөнаһ булып санала.

Ислам галимнәре гөнаһларны зур һәм кечкенә төрләргә бүлә. Кечкенә гөнаһлар кешенең әдәпсезлек, тәрбиясезлек күрсәтүе белән бәйле булса, зур гөнаһлар аерым кеше өчен яки җәмгыять өчен зур зыян чыганагы булып тора.

Олы гөнаһларга түбәндәгеләр керә:

– кеше кыйнау, үтерү, зина кылу;

– исерткеч эчемлекләр эчү, әфьюн куллану;

– харам ризык ашау;

– риба (акчаны процентка бирү яки алу);

– әти-әнине рәнҗетү, туганлык җепләрен өзү;

– гайбәт сөйләү, алдалау;

– сихер һәм күрәзәчелек белән шөгыльләнү;

– тәкәбберләнү һәм башкалар.

Бик күпләр гөнаһ кылуга җиңел карый, аның яман нәтиҗәләре турында уйланмый һәм тәүбә итәргә ашыкмый.

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Һәрбер адәм баласы хаталы (ялгышучан), әмма шуларның иң хәерлесе – тәүбә кылучысы»[1].

Димәк, кеше гөнаһ кылды икән, ул аны танып, үкенеп, тәүбә кылырга тиеш. Дөрес, гарәп җирлегендә яшәве күпкә җиңелрәк. Кызганыч, безнең җирлектә без кая гына карасак та гөнаһ чәчәк ата: тирә-юньдә эчкечелек, кредитка яшәү, зина, бозыклык киң таралган. Бүгенге көндә әлеге бозыклыкта яшәвебез безгә Аллаһы Тәгаләдән бирелгән сынау булып тора. Әгәр без бу бозыклыклардан читләшсәк, безгә савабы да күбрәк булыр, иншәАллаһ.

Һәрберебездә гөнаһ җитәрлек, җәмәгать! Намаз укыган, Коръән белән гамәл кылган кеше гөнаһлардан саклана, зур гөнаһларны кылмый. Кеше гөнаһларны күбрәк кылган саен, ул бер гадәткә керә. Ягъни, бу гөнаһларга ул ияләшә, күнегә башлый. Иң куркынычы, бу гөнаһ гамәлләр кешене бераз гына да чиркандырмый, кешедә оят кача, кешенең йөрәге бу гөнаһ гамәлләрне сизми башлый. Кеше Аллаһы Тәгаләдән ерагая һәм нәтиҗәсе булып кешенең тормышы бозыла: кеше бәла-казага очрый, авырый башлый, кешенең хәтере начарая, белеме кими, тормышында бәрәкәт бетә, ул ризыгының тәмен, яшәүнең ямен тоймый башлый.

[1] Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

وَمَآ أَصَٰبَكُم مِّن مُّصِيبَةٍ فَبِمَا كَسَبَتۡ أَيۡدِيكُمۡ وَيَعۡفُواْ عَن كَثِيرٍ ﴿٣٠﴾

**«Сезгә килгән һәр бәла – кулларыгыз казанган [начар] нәрсәләр сәбәпле. Ул бик күбен гафу итә [һәм аларга җәза бирми, шулай булмаса, җир йөзендә һичбер җан иясен калдырмаган булыр иде]».**

«Әш-Шура / Киңәш», 42:30

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Гөнаһ кылудан туктыйк, кылган гөнаһларга тәүбә итеп, Аллаһы Тәгаләнең биргән нигъмәтләренә шөкер кылып, мөмкин кадәр тормышыбызны изгелектә, игелектә үткәрик.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илназ хәзрәт Хаҗиев,*

*Биектау районы имам-мөхтәсибенең ярдәмчесе*

*7 нче гыйнвар вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 4 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Никах кылу – җитди адым

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн. Барча җанлы һәм җансыз барлыкларны Яратучы, безгә Үзенең һәрдаим нигъмәтләрен биреп ризыкландыручы, тәрбияләүче, кылган догаларыбызны кабуллардан кылучы Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләребез булсын.

Дөньяларны яраткан вакытта Аллаһы Тәгалә бөтен нәрсәне парлы итеп яратты. Аллаһы Тәгаләдән кала бөтен нәрсәнең пары бар, фәкать Аллаһы Тәгалә Үзе генә ялгыздыр. Мисал өчен, барыбыз да беләбез: безнең көн бар, көнне төн алыштырса, якты кояшны ай алыштыра. Шулай ук, ут булган кебек су бар, кешенең дә уң кулы булган кебек сул кулы бар һ.б. Аллаһы Тәгалә Үзенең рәхмәте белән ир белән хатынны да парлы итеп бар кылды.

وَخَلَقْنَٰكُمْ أَزْوَٰجًا ﴿٨﴾

**«Без сезне [ирле-хатынлы] парлар хәлендә яраттык».**

«Ән-Нәбә / Хәбәр», 78:8

Аллаһы Тәгалә адәм балаларына парлы булып яшәүне фарыз дәрәҗәсенә куйган. Ир һәм хатын бер-берсен тапканнан соң, Аллаһы Тәгалә аларга никах укытырга әмер итә. Кешеләрнең дөнья тормышында беренче бурычлары иманлы яшәү һәм иман белән дөньядан үтү булса, икенчесе – гаилә корып, балалар үстереп, яхшы нәсел калдыру.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمِنْ ءَايَٰتِهِۦٓ أَنْ خَلَقَ لَكُم مِّنْ أَنفُسِكُمْ أَزْوَٰجًا لِّتَسْكُنُوٓاْ إِلَيْهَا وَجَعَلَ بَيْنَكُم مَّوَدَّةً وَرَحْمَةً ۚ ... ﴿٢١﴾

**«Бергә яшәвегез өчен үзләрегездән сезнең өчен хатыннар яратуы һәм арагызда сөю [нәтиҗәсендә хасил булган бердәмлек] белән бер шәфкать [чарасы булган бала] бирүе дә – Аның билгеләреннән».**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:21

Димәк, җәмәгать, аятьтән аңлашылганча, Аллаһы Тәгалә хатын-кызларны ирләр өчен, без аларда киңәш, үзебезгә рәхәтлек һәм тынычлык тапсын өчен яраткан. Әгәр дә Аллаһы Тәгаләнең рөхсәте булмаса, хатын-кыз белән ир бер-берсен ярата алмый.

Аллаһы Тәгалә шушы ук аятьнең дәвамында болай дип әйтә:

إِنَّ فِى ذَٰلِكَ لَءَايَٰتٍ لِّقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ ﴿٢١﴾

**«Һичшиксез, монда уйлаганнар өчен [аңлатылып бетерә алмаслык дәрәҗәдә зур] билгеләр бар».**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:21

Ягъни, хатын-кыз белән ир бер-берсен ярата алсын өчен, Аллаһы Тәгалә аларның икесенең дә күңелләренә мәхәббәт хисе сала.

Никах – ул Аллаһы Тәгалә каршында ир белән хатын-кызның бер-берсенә вәгъдә бирүе, килешү төзү. Ислам динендә никах изге гамәлләрнең берсе булып санала. Никах мәхәббәт, мәрхәмәт нигезендә төзелергә тиеш.

Аллаһы Тәгалә безгә йөкләгән һәр эшнең шарты булган кебек, никахның да шартлары бар. Беренче шарт булып, ир белән хатын-кызның мөселман булуы тора. Никахның икенче шарты – шаһитләр. Ким дигәндә,

балигълык яшенә җиткән акыллы ике ир кеше яки бер ир кеше һәм ике хатын-кыз булуы кирәк. Өченчесе шарт – мәһәр. Ир кешенең хатын-кызга бүләге булырга тиеш.

Никах – ул бер-берсен ошаткан җаннарның үз хисләрен җәмгыятькә белдерүләре. Әгәр алар тормышларын Аллаһы кушканча көйли алсалар, бу никахның нәтиҗәсе игелекле бала булачак.

Бүгенге көндә яшьләр никахка җиңел карый. Күп вакытта әти-әни ризалыгын да сорамыйча никах укыталар, никахсыз торучыларның да саны көннән көн арта. Ахырда гаиләләрнең яртысыннан артыграгы таркала. Статистика мәгълүматларына күз салсак, 2020-2021 елларда аерылган гаиләләр саны дүрт мәртәбә арткан. Кызганычка, бу бик аяныч күренеш. Аерылушының төп сәбәпләре: бер-береңне аңларга теләмәү, эгоизм, акча җитмәү, күпкә кызыгу, кредитка яшәү, тормыш гыйлемен белмәү һ.б. Никахка салкын карау, никахсыз яшәү – ул киләчәк буын алдында җинаятькә тиң, дип әйтәләр бит. Бүгенге көндә ирекле мәхәббәт турында сүз алып баручы, гаиләнең һәм никахның әһәмиятен киметергә тырышучы кеше – ул балта белән милләтнең киләчәгенә чабучы.

Никах кылу – җитди адым, аңа әзер булырга кирәк. Яшьләребезне тормышта сабыр булып, булганына шөкер итеп, матур гаиләләр корып, иманлы балалар үстереп яшәргә өндик!

Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга хәерле гомерләр биреп, никахлы җәмәгатьләребез белән тигезлектә, татулыкта, саулык-сәламәтлек, өлфәт мәхәббәт белән, бер-беребезгә терәк-таяныч булып, кайгы-хәсрәт күрмичә гомер итәргә насыйп кылсын. Әәмин.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илназ хәзрәт Хаҗиев,*

*Биектау районы имам-мөхтәсибенең ярдәмчесе*

# Үрнәк затлар

# Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе

Гайшә радыяллаһу ганһә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять иткән: «Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Мин җәннәткә кердем һәм анда берәүнең Коръән укыганын ишеттем. Бу Коръән укучының кем булуын сорагач, миңа җавап итеп: «Коръәнне укучы Харисә бине Ногъман! Тәкъва булучыларның халәте әнә шундый!» – дип әйттеләр».

## Ислам динен кабул итүе

Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе үзенең әнисен бик хөрмәт иткән. Бервакыт аңа Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәләмнең дәгъваты турында хәбәр ирешкән. Ул бу хакта күбрәк белергә теләгән. Аңа Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәдинәдә Мосгаб бине Гомәер исемле йомышчысы барлыгы һәм аның башкаларны Коръән укырга өйрәтүе һәм имам булып алар белән намаз гыйбадәтен үтәве хакында әйткәннәр. Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе Мосгаб бине Гомәер янына барган. Мосгаб бине Гомәер кыскача аңа Ислам дине хакында сөйләгән. Шуннан соң Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе Ислам динен кабул итүе хакында хәбәр иткән.

Ислам динен кабул иткәч, Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе потка табынучы әнисе хакында бик борчылган. Аллаһы Тәгалә аның да йөрәгенә дөрес юлны күрсәтсен, дип Раббысына догалар кылган. Өенә кайткач, әнисенә Ислам динен кабул итүе хакында хәбәр иткән һәм әнисе дә: «Мин дә үземнең Ислам динен кабул итүем хакында игълан итәм», – дип әйткән.

Мәдинә шәһәрендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәләмнең һиҗрәте хакында хәбәр таралгач, мөселманнар моңа бик шатланган-

нар. Бу хәбәргә бигрәк тә Харисә бине Ногъман шатланган. Көн саен мөэминнәр шәһәр капкасы янына чыгып, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне көткәннәр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләрен каршы алучылар арасында иң беренчеләрдән Харисә бине Ногъман булган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм шәһәргә дөягә утырып кергән. Һәркем Аллаһының Расүле нәкъ менә аның йорты тирәсендә туктавын теләп, дөянең тезгененнән тарткан. Дөя исә Әбү Әюб Әл-Әнсари йорты янында туктаган. Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе моңа бик шатланган, чөнки үзе дә, Әбү Әюб Әл-Әнсари кебек, нәҗҗар кавеменнән булган һәм аның белән күрше булып яшәгән.

## Пәйгамбәребезнең күршесе

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гаиләсе һәм туганнары Мәккәдән Мәдинәгә күченгәч, Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе аларны үз өендә кунак иткән. Барлык кирәк нәрсәләр белән тәэмин итәргә тырышкан һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ярдәм итә алуына нык шатланган. Ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне ихластан яраткан, хөрмәт иткән һәм аның өчен һәрнәрсәне дә эшләргә әзер торган.

Сәхабәләр Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһене Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күршесе дип атаганнар, чөнки аның йорты Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәчетенә якын булган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә йорт кирәк булганда, Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе ике дә уйламый аңа үзе яшәгән йортны тәкъдим иткән, ә үзе өчен яңа йорт төзегән.

Һиҗрәтнең икенче елында Гали бине Әби Талиб радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Фатыйма исемле кызына өйләнгән. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу яшь

гаиләнең үзенең янәшәсендә генә, күршеләр булып яшәүләрен теләгән. Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе бу хакта хәбәрне ишеткәч үк Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына барып: «Йә Аллаһының Расүле, мин Бәни Нәҗҗар кавеменең иң ышанычлы йортын, ягъни үз йортымны аларның карамагына тапшырам. Минем барлык малым Аллаһы Тәгаләнеке һәм Аның Расүленеке. Аллаһы белән ант итәм, йә Аллаһының Расүле, миңа бирүеңә караганда, миннән алуың минем өчен хәерлерәк», – дип әйткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһенең ихласлыгына ышанган һәм аның тәкъдимен кабул иткән. Гали бине Әби Талиб радыяллаһу ганһе һәм хәзрәти Фатыйма үзләренә йорт төзегәнче Харисә бине Ногъман йортында яшәгәннәр.

## Күркәм сыйфатлары

Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһенең Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә тугрылыгы, хөрмәте моның белән генә чикләнмәгән. Башка мөселманнар белән бергә ул да күп сугышларда катнашкан, кыюлык күрсәткән. Һәрвакытта да Аллаһының Расүле янәшәсендә булырга тырышкан, аны саклаган. Ислам дине өчен бар булганын фида кылган. Кылган һәрбер гамәлен Коръәни Кәримнең түбәндәге сүрәсенә таянып башкарган:

**«Әйт: «Әгәр сезнең аталарыгыз, улларыгыз, кардәшләрегез, хатыннарыгыз, гаиләләрегез, кәсеп иткән малларыгыз, торгынлыкка төшүеннән курыккан сәүдәгез һәм күңелегезгә якын торакларыгыз сезгә Аллаһыдан, Аның Расүленнән [һиҗрәт] һәм Аның юлында җиһад кылудан сөеклерәк икән, Аллаһы [дөньяда да, Ахирәттә дә сезнең белән бәйле газап] әмерен китергәнне көтегез. Аллаһы [дошманнары белән дус булып, әмереннән чыккан] фасикълар кавемен [ике җиһанда да морадларына ирештерми һәм**

**туры юлны табарга] һидаять итми».**

«Әт-Тәүбә», 9:24

Харисә бине Ногъман өчен бу гадәти сүзләр генә булмаган. Ул һәрвакыт шушы сүзләрне исендә тотып, һәр гамәлен Аллаһы ризалыгы өчен башкарган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң да, Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе динебез юлында тырышлыкларын киметмәгән. Башкалардан юмартлыгы, батырлыгы белән аерылып торган. Аның кебекләр хакында Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Моңа кадәр [Мәдинә дигән] йортта яшәгән һәм күңелләренә иманны салган кешеләр үзләренә [Мәккәдән] һиҗрәт кылган кешеләрне [җаннары-тәннәре белән] сөяләр, аларга [мөһаҗирләргә] бирелгән [ганимәт малы кебек] нәрсәләрдән бернинди көнләшү хис итмиләр. Үзләрендә ихтыяҗ булса да, [ашамыйча-ашатып, киенмичә-киендереп] аларны үзләреннән өстен күрәләр. Кем дә кем нәфесенең комсызлыгыннан саклана [һәм Аллаһы юлында сарыф итә], шулар – уңышка [һәм котылуга] ирешүчеләр».**

«Әл-Хәшр / Җыен», 59:9

## Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһенең вафаты

Гомеренең азагына Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе сукыр калган. Бу халәтенә разый булып, соңгы көннәренә кадәр намазларын мәчеткә йөреп башкарган.

Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһе 51 нче һиҗри елда вафат булган.

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

# Июль

## Татарстанның 100 мәчетендә татар теле курслары тәмамланды

Татарстанның 100 мәчете каршында оештырылган татар теле курслары тәмамланды. Аларда 1500 тыңлаучы укыды һәм телне башлангыч дәрәҗәдә үзләштерү хакында сертификатларга лаек булды. Татар теле курслары Татарстанның 45 мөхтәсибәтен колачлады, шул исәптән, Казанның 45 мәчетен. Иң зур төркемнәр Рәсәй ислам институтында (86 кеше), Нурлаттагы Әхмәтзәки Сафиуллин исемендәге тәгълим үзәгендә (53 кеше), Түбән Камадагы Җәмигъ мәчетендә (37 кеше) җыелды. Курслар ТАССР оешуның 100-еллыгы һәм Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында үткәрелде.

## Нәзарәтнең «Хозур» нәшрияты китаплары Рәсәйнең иң зур интернет-кибетләрендә сатыла башлады

Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты китапларын хәзер илнең иң зур сәүдә онлайн-мәйданчыкларында сатып алырга мөмкин. Шул рәвешле, «Хозур» китапларын хәзер Wildberries, OZON, KazanExpress.ru, шулай ук «Читай-город», «ЛитРес» интернет-кибетләрендә табып була. Маркетплейсларның популярлыгы шуннан гыйбарәт ки, аларда китапларны сайлау мөмкинлеге зур, үзеңә кирәкле китапны эзләү уңайлы итеп оештырылган, теләсә кайсы шәһәргә тиз арада китереп тә бирәләр, шунда ук фикер алышу мөмкинлеге дә булдырылган.

## Рәсәйдә беренче тапкыр Коръән-хафизларның һөнәри ассоциациясе төзелде

Рәсәйдә беренче тапкыр Коръән укучылар ассоциациясе оештырылды. Әлеге оешма РФ Ислам мәгарифе советы башлангычы белән булдырылды. Ассоциациягә Рәсәйнең 12 төбәгеннән хафизлар керде. Алар Татарстан, Чечня, Дагыстан, Саратов, Иваново, Мордовия, Пенза, Пермь, Кемерово, Чуашстан, Карачай-Черкесия, Кырымнан. Төбәкләр Коръән-хафизларны әзерләү буенча алып барылган эшчәнлеккә карап сайлап алынган. Шулай итеп, Рәсәй Коръән укучылары ассоциациясенә әгъза итеп мөфтиятләрдә Коръән эшләре буенча җаваплы белгечләр, Коръән-хафизлары үзәкләре вәкилләре кабул ителде.

## Болгар ислам академиясендә магистрларга дипломнар тапшырылды

Зөлкагъдә аеның 27 нче көнендә (7 нче июльдә) Болгар ислам академиясендә магистрларга дипломнар тапшырылды. Быел БИА магистры димломына 24 кеше ия булды. Алар арасында «Рахмәтулла» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм Ясәвиев (Казан шәһәре), Казан ислам университетының өлкән укытучысы Илмир Хисамов, КИУның Коръән хафизларны әзерләү үзәге укытучысы Ибраһим Сабиров, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Хәләл стандарты комитеты белгече Илгиз Баһаветдинов, «Тәүбә» мәчете имамы Артур хәзрәт Абдиев (Яр Чаллы шәһәре) һ. б. бар. Алар магистрлык диссертацияләре өчен ислам хокукы, Коръән фәннәре, ислам тарихы, хәдис белеме, илебездәге дини мирас өлкәсенә караган көнүзәк темаларны сайлады.

## Чүпрәледә унөченче тапкыр «Мунчәли укулары» узды

Зөлкагъдә аеның 30 нчы көнендә (10 нчы июльдә), Чүпрәледә унөченче тапкыр «Мунчәли укулары» фәнни-гамәли-дини конференциясе узды. Быелгы «Мунчәли укулары» «Яшь буынны дини тәрбияләүдә татар милли гореф-гадәтләрен куллану» темасына багышланды. Укуларга бөек татар драматургы Туфан ага Миңнуллин башлангыч биргән иде.

## Татарстанда мөселман яшьләренең җәйге форумнары узды

Казанда һәм Болгарда кызлар һәм егетләр өчен аерым XII Мөселман яшьләре форумы узды. Җыен Рәсәйнең төрле почмакларыннан һәм якын чит илләрдән 18-30 яшьләрдәге 200 мөселманны җыйды. Форумда катнашучылар җиде көн дәвамында остазларның кызыклы лекцияләрен тыңлады, мастер-классларда, интеллектуаль уеннарда, тренингларда, семинарларда катнашты, хәзерге заман мөгаммәләтен һәм ислам финансларын үзләштерде. Мөселман яшьләре форумы – ТР мөселманнары Диния нәзарәте яшьләр өчен тормышка ашыра торган мөһим проектларның берсе. Ул дини-агарту, социаль-мәдәни һәм фикер алышу мәйданчыгы яшьләргә аралашу, берләшү, белем эстәү һәм үзләренең социаль идеяләрен тормышка ашыру мөмкинлеге бирә торган мәйданчык буларак эшли.

## Биектауда «Бердәмлек» ислам үзәге ачылды

Зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көнендә (19 нчы июльдә) Биектау районы Биектау авылында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, күпләгән кунаклар, район җитәкчелеге, иганәчеләр, мәчет имамнары катнашында «Бердәмлек» ислам үзәге ачылды. «Бердәмлек» ислам үзәге төзелеше 2015 елда башлан-

ды. Анда мәчет каршындагы курслар оештыру, имамнарның белемнәрен күтәрү, татар теле дәресләре үткәрү, Коръән ятлау дәресләре оештыру, балаларның ялын – рухи-сәламәтләндерү үзәге эшен оештыру, мөселман һәм татар халык бәйрәмнәрен үткәрү ниятләнә. Моның өчен үзәктә 500 кеше сыйдырышлы намаз уку бүлмәсе (ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен), ашханә, тәһарәтханә, китапханә һәм китап уку заллары, уку сыйныфлары һәм конференц-зал урын алган.

## Казанда Гает алдыннан «Рәхмәтулла» мәчете ачылды

Зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көнендә (19 нчы июльдә), изге Корбан бәйрәме алдыннан Казанда рәсми рәвештә «Рахмәтулла» мәчете үз ишекләрен ачты. Әлеге сөенечле тантанага Нәзарәт вәкилләре, район һәм шәһәр җитәкчелеге, иганәчеләр, мәхәллә халкы, җәмәгать эшлеклеләре, журналистлар килде. Шулай ук биредә мәчет янәшәсендә «Бәрәкәт» чишмәсе ачылды. «Рахмәтулла» мәчете – Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары мөхтәсибәтендә төзелгән 8 нче мәчет. Рухи-мәгърифәт һәм социаль тормыш үзәге булып хезмәт итәчәк гыйбадәтханә Симонов урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан.

## Татарстанда Корбан бәйрәме узды

Татарстанда зурлап һәм оешкан төстә Корбан бәйрәме чаралары узды. Югары дәрәҗәге әзерлек нәтиҗәсендә, олуг бәйрәм мөселманнарга гына түгел, республиканың барлык күпмилләтле халкына да чын шатлык бүләк итте. Шәкертләр һәм өлкәннәр, инвалидлар һәм йортсызлар, ятимнәр һәм ялгыз аналар, күпбалалы һәм аз керемле гаиләләр – аларга, Корбан бәйрәмен түземсезлек белән көтеп алучыларга, милләтенә һәм диненә карамастан, корбан ите тапшырылды.

2021 елда республикабызда ТР мөселманнары Диния нәзарәте мөхтәсибәтләре карамагында корбан чалу гамәлен башкару өчен 51 мәйданчык, шул исәптән, Казанда 16 мәйданчык оештырылды. Аларда барлыгы 13 417 мал чалынды. Казанның үзендә 16 корбан чалу урынында 5883 баш хайван корбанга чалынды.

Татарстан районнары һәм шәһәрләре арасында лидер булып һәрвакыттагыча Әлмәт мөхтәсибәте тора: биредә 1550 сарыкны корбанга чалдылар. Аннан соң Чаллы (1520 баш), Питрәч (750 баш), шулай ук Яшел Үзән (550 баш) мөхтәсибәтләре килә. Казанда иң күп мал чалган урыннар булып «Казан нуры» (2000 сарык), «Мәрҗани» (600 сарык) һәм «Сөләйман» (550 сарык) мәчетләре тора.

Болардан тыш, Диния нәзарәтенең «Зәкәт» хәйрия фонды махсус «Мохтаҗларны ашат» акциясе кысаларында иганәчеләр ярдәмендә халыкның мохтаҗ катламнарына тарату өчен өстәп тагын 1826 сарык чала. Шул рәвешле, Татарстанның 2542 азкеремле гаиләсе һәм социаль хезмәтләр күрсәтүче 13 оешмасы 27,4 тонна корбан ите белән тәэмин ителде.

## Балтачта XIV мөселман балалар Сабантуе узды

Зөлхиҗҗә аеның 15 нче көнендә (25 нче июльдә), Балтач районы Бөрбаш авылында Рәсәйкүләм мөселман балалар Сабан туе узды. Бирегә килгән күпләгән кунаклар арасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, җәмәгать эшлеклеләре, җитәкчеләр, дин әһелләре, күренекле шәхесләр булды. Әлеге күркәм чара быел ундүртенче тапкыр Балтач районы имам-мөхтәсибе, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевның тырышлыгы белән оештырылды. Сабантуйда шулай ук чит төбәкләрдән дә мөселман дини оешма вәкилләре: Ульян, Самара, Оренбург, Киров өлкәсе, Мари Эль, Башкортстан, Чувашия республикалары мөселманнары да кунак булып килде. Быелгы мөселман балалар Сабан

туе Татарстанда игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында үтте, әлеге чараны оештыруның төп максаты булып балаларда халык традицияләренә мәхәббәт тәрбияләү тора. Сабантуй балаларның Коръән һәм догалар укулары, мөнәҗәт әйтүләр, шигырьләр белән үрелеп барды. Шулай ук ел да үткәрелеп килә торган Коръәннән аятьләр һәм догалар уку бәйгесе дә булды.

## Танылган җәмәгать эшлеклесе Әлмирә ханым Әдиятуллина вафат булды

Зөлхиҗҗә аеның 17 нче көнендә (27 нче июльдә), татар халкы үзенең мәшһүр вәкиле, горурлыгы һәм йөз аклыгы – күренекле шәхес, танылган җәмәгать эшлеклесе, «Мөслимә» оешмасы җитәкчесе, атаклы журналист, редактор, илебез мөселманнарының хокукларын яклаган һәм милли яңарышның чишмә башында торган Әлмирә ханым Әдиятуллина белән хушлашты. Әлмирә ханым 83 яшендә вафат булды. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Әлмирә апа Әдиятуллина вафаты сәбәпле кайгы уртаклашты. Җеназа намазы Казанның Самосырово бистәсендәге мөселман зиратында үтте. Аны Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов алып барды. Әлмирә апаны соңгы юлга озатырга туганнары, якыннары, коллегалары, дин әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре һәм аның киткәненә ихластан кайгырган гади мөселманнар килде.

## Казанда XII «Рәсәй – Ислам дөньясы: KazanSummit-2021» халыкара икътисад саммиты узды

28-30 нчы июльдә Казанда XII «Рәсәй – Ислам дөньясы: KazanSummit-2021» халыкара икътисад саммиты узды. Татарстан мөфтияте Саммит кысаларында берничә мәйданчык оештырды. Мисал өчен, җыенның

мөхтәрәм кунаклары Russia Halal Expo хәләл-индустрия күргәзмәсе белән танышты, Рәсәй Федерациясендә һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасы (ОИС) илләрендә хәләл сертификацияләү буенча органнарны аккредитацияләү мәсьәләләренә багышланган сессиясендә катнашты. Саммит кысаларында Татарстан мөфтие чит илләрдән килгән рәсми затлар белән эшлекле очрашулар да үткәрде. Камил хәзрәт хәләл стандарты буенча аккредитация ясаучы Төркия дәүләт оешмасы җитәкчесе Җәфар Сойлу белән очрашты, Иран Республикасының Рәсәй Федерациясендәге гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Казем Җәләли, Ислам сәүдәсәнәгать һәм авыл хуҗалыгы палатасы Генераль сәркатибе (ICCIA) Юсеф Хәсән Хәләви, Согуд Гарәбстаны Корольлегенең Рәсәй Федерациясендәге Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илчесе Габдрахман бине Сөләйман Әл-Әхмәд, Катар дәүләтенең Рәсәйдәге гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе шәех Әхмәд бине Насыйр бине Җәсим Әл-Тани җитәкчелегендәге делегацияләрне кабул итте.

# Август

## Эльбруска Татарстаннан республика мөфтие җитәкчелегендә динара экспедиция кылынды

Татарстан Республикасыннан бер төркем мөселман һәм православ эшлеклеләре Аурупаның иң югары ноктасына – Эльбрус тавына күтәрелде. Экспедиция составына 10 кеше керде – Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, мөфтинең халыкара мәсьәләләр буенча киңәшчесе, Түбән Кама имам-мөхтәсибе Салих хәзрәт Ибраһимов, ТР джиу-джитсу Федерациясе президенты, Әбү-Дабидагы дөнья чемпионаты призеры Айрат Кәлимуллин, танылган эшмәкәр Айдар Булатов, кинорежиссер Ренат Хәбибуллин, иеромонахлар Амвросий (Горновский) һәм Варсонофий

(Обозов) һ.б. Эльбрусның иң югары ноктасын – диңгез өсте тигезлегеннән 5642 метрны – штурмлау 2021 елның 7 нче августыннан 8 нче августына каршы төндә була һәм Халыкара альпинизм көне (8 нче августта) һәм мөселман календаре буенча 1443 ел җитүе белән туры килә. Шул рәвешле, Эльбруска беренче тапкыр Татарстаннан уңышлы динара экспедиция ясалды.

## РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе башлангычы белән мохтаҗ имамнарга финанс ярдәме күрсәтелә башлады

Татарстанда РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе башлангычы белән «Гаилә дәресләре» дигән әһәмиятле яңа социаль проект башланды. Ассоциациянең хәйрия фонды мәчетләрдә имамнарның мөгаллимлек хезмәтен атна саен түләп бара, ә бу, үз чиратында, авыл җирлегендә һәм республика шәһәрләрендә халыкның дини гыйлемен арттырырга мөмкинлек бирә. «Гаилә дәресләре» проекты тулы куәтенә агымдагы елның октябрь аенда эшли башлый. Октябрь башына кадәр оештыручылар әлеге проект белән бөтен республиканы колачларга ниятли. Дәресләр барлык теләүчеләр өчен дә бушлай уза. РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясенең хәйрия фонды барлык теләүчеләрне «Гаилә дәресләре» проектына кушылырга, халык арасында ислам турындагы белемнәрне таратуга һәм ныгытуга өлеш кертергә чакыра. Белешмәләр өчен телефон: +7986 902 0606 (Рөстәм Вәлиев).

## Ярты ел эчендә онлайн-мәдрәсәдә белем алучыларның саны 43 меңнән артып киткән

Август аенда беренче татар онлайн-мәдрәсәсе эшли башлауга ярты елдан артык вакыт узды. Бу вакыт эчендә онлайн-мәдрәсәдә бе-

лем алучыларның саны 43 меңнән артып китте! Шуларның 400 гә якыны, ислам нигезләре турында тулы курсны тәмамлап, махсус сертификатка ия булды. Онлайн-мәдрәсәдә көн саен 1000 «шәкерт» Ислам дине нигезләрен үзләштерә. Аларның 21% – 25-34 яшьтә, 23% – 35-44 яшьтә, 28% – 55 яшьтән өлкәнрәкләр. Онлайн-мәдрәсә белән, Татарстаннан гына түгел, Рәсәйнең башка төбәкләреннән: Башкортостанда, Мәскәү, Самара һәм Ульяновск өлкәләрендә, Мәскәү шәһәрендә яшәүче шәкертләр (аларның саны 41 меңнән артык) кызыксына. Моннан тыш, заманча белем бирү ресурсында ислам нигезләре буенча белемне Казахстандагы (848 кеше), Үзбәкстандагы (306), Кыргызстандагы (262), Әзербәйҗандагы (70), Таҗикстандагы (26), Төркиядәге (119), Австралиядәге (301), АКШтагы (181), Германиядәге (81), Ирландиядәге (18), Канададагы (43), Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендәге (14), Украинадагы (24), Бөекбританиядәге (15) һәм Франциядәге (21) милләттәшләребез дә ала.

# Сентябрь

## Татарстан мөфтиятендә «Таян Аллага!» әдәби бәйгесенә нәтиҗәләр ясалды

Мөхәррам аеның 30 нчы көнендә (7 нче сентябрьдә), Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтендә «Х Якупов укулары» вакытында «Таян Аллага!» әдәби бәйгесенә нәтиҗәләр ясалды. Мәрхүм Вәлиулла хәзрәт Якупов тарафыннан нигезләнгән конкурс хәзерге вакытта Рәсәй ислам институты һәм «Идел» журналы белән берлектә ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан үткәрелә. Җиңүчеләрне «Махсус бүләк», «Шигърият», «Чәчмә әсәр» һәм «Публицистика» номинацияләрендә бүләкләделәр.

## «Х Якупов укулары» узды

Мөхәррам аеның 30 нчы көнендә (7 нче сентябрьдә), Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтендә «Х Якупов укулары» узды. Унынчы юбилей укулар дин әһеленең туган көненә (4 нче сентябрь) багышланды һәм ул Идел буе Болгар дәүләтендә Исламны кабул итүнең 1100-еллыгы һәм Татарстанда игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында үтте. Ул Татарстан мөфтияте һәм Рәсәй ислам институты тарафыннан оештырылды. Конференция танылган татар мәгърифәтчесе, галим һәм дин эшлеклесе Вәлиулла хәзрәт Якуповның (1963-2012) бай рухи-дини һәм интеллектуаль мирасының асылына төшенү максатыннан үткәрелде. Якупов укуларында зыялылар, галимнәр һәм җәмәгать эшлеклеләре, мәдрәсә җитәкчеләре, Бөтендөнья татар конгрессы вәкилләре, Вәлиулла хәзрәтнең элеккеге хезмәттәшләре катнашты.

## «Гражданская идентичность мусульман России» яңа уку әсбабы тәкъдим ителде

Мөхәррам аеның 30 нчы көнендә (7 нче сентябрь), Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте бинасында «Х Якупов укулары» кысаларында «Гражданская идентичность мусульман России» уку әсбабы тәкъдим ителде. Аның авторлары – фәлсәфә фәннәре докторы, сәясәт фәннәре кандидаты, БИА профессоры Вячеслав Полосин, Ислам белеме буенча совет рәисе, ТР мөфтиенең мәгариф буенча урынбасары, РИИ һәм КИУ ректоры Рафикъ Мөхәммәтшин, педагогика фәннәре кандидаты, Төньяк Кавказ мөселманнары Координация үзәге Башкарма комитеның җаваплы сәркатибе Ибраһим Ибраһимов. Авторлар коллективы, үз хезмәтләрен тәкъдим итеп, дәреслекнең Болгар ислам академиясе заказы буенча 2

ел дәвамында язылуы турында сөйләде. «Гражданлык үзенчәлекләре» дисциплинасы Рәсәй ислам институтында, Казан ислам университетында, Болгар ислам академиясендә һәм Татарстанның 8 мәдрәсәсендә кертелгән инде. Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшин сүзләренә караганда, хәзерге вакытта уку әсбабын сынап карау әлеге ислам уку йортларында узачак. Дәреслекне, РФ Мәгариф министрлыгында сертификацияләп, эшләп бетергәннән соң, ул шулай ук дөньяви югары уку йортлары һәм көллиятләрнең теология факультетларында файдаланылачак.

## Нәзарәт, Татарстан мөхтәсибәтләре һәм мәдрәсәләр «Татарча диктант» акциясенә кушылды

Сафәр аеның 3 нче көнендә (10 нчы сентябрьдә), «Татарча диктант» белем тикшерү акциясе старт алды һәм ул өч көн дәвам итте. Әлеге чарага беренчеләрдән булып Татарстан мөфтияте, аның карамагындагы оешмалар, мөхтәсибәтләр (мәчетләр) һәм мөселман уку йортлары кушылды.

## РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясенең Хәйрия фонды «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә дәреслекләр һәм парталар алып бирде

Сафәр аеның 6 нчы көнендә (13 нче сентябрьдә), Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе һәм әлеге оешманың хәйрия фонды җитәкчелеге шәкертләр белән очрашты. Очрашуда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты. Тарихи мәдрәсәгә кунак булып РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе президенты Айдар Шаһимәрданов, ассоциациянең башкарма директоры Раил Валкаев, РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясенең хәйрия фонды җитәкчесе Рөстәм Вәлиев һәм башкалар килде. Очрашуга җыелуның

төп сәбәбе – РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясенең Хәйрия фонды Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә матди ярдәменә сатып алынган җиһазларны карау һәм шәкертләргә дәреслекләр тапшыру. Алдарак, 20 августта, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин белән рәсми очрашуда РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе Аллаһы ризалыгы өчен «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә 620 000 сум күләмендә садака тапшырган иде. Шушы садака хисабына беренче курста белем алучы 70 шәкерт өчен, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе тарафыннан әзерләнеп, 5 төрле китаптан торган дәреслек комплектлары бастырылды. Әлеге дәреслекләр гарәп телен өйрәнү буенча уку әсбапларыннан гыйбарәт. Комплектта нәһү, сарыф, китәбә (язу), кыйраә (уку), тәгъбир (диалог) предметларыннан дәреслекләр урын алган. Моннан тыш, мәдрәсә өчен 30 парта һәм алар өчен урындыклар сатып алынды. Акчаларны Ассоциациянең Private Club резидентлары җыеп бирде.

## Татарстан имам-мөхтәсибләре ГТОның барлык нормаларын тапшырды

Сафәр аеның 8 нче көнендә (15 нче сентябрьдә), Татарстанның барлык имам-мөхтәсибләре һәм Нәзарәтнең аппарат һәм гамәлгә куелган оешмаларның хезмәткәрләре чираттагы тапкыр ГТО нормаларын тапшырды. Республиканың төрле почмакларында яшәүче дин әһелләре Чистай шәһәренең «Татнефть-Олимп» стадионына җыелды. Үзләренең физик әзерлекләрен республика мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин белән бергә Татарстанның 48 шәһәре һәм районы мөхтәсибе, нәзарәт хезмәткәрләрен дә кертеп – барлыгы 70тән артык мөселман кардәшләребез тикшерде. Хөкемдарлар коллегиясен 10 судья тәшкил итте. Дин әһелләре көч, җитезлек һәм чыдамлылыкны тикшерүгә юнәтелгән тугыз сынау күнегүен тапшырды: алар үз көчләрен җиңел атлетикада, көч таләп итүче күнегүләрдә, йөзүдә, пневматик винтовкадан атуда, граната атуда,

гимнастикада күрсәтте.

## Казанда Коръән-хафизлар үзәгендә Коръән фәннәренең тарихы һәм хәзерге торышы турында фикер алыштылар

Сафәр аеның 8 нче көнендә (15 нче сентябрь), КИУның Коръән-хафизлар әзерләү үзәгендә Мөхәммәдсадыйк Иманколый исемендәге «Коръән фәннәре: тарих һәм хәзерге заман» төбәк фәнни-гамәли конференциясе узды. Мөхәммәдсадыйк хәзрәт Иманколый – XX гасырның күренекле татар кадимчеләреннән саналган дин эшлеклесе, «Тәсһил әл-бәйән фи тәфсир әл-Куръән» («Коръән тәфсирен аңлатуны җиңеләйтү») тәфсире авторы. Төбәк фәнни-гамәли конференциясен ТР мөселманнары Диния нәзарәте, Рәсәй ислам институты, Казан ислам университеты һәм Коръән- хафизлар әзерләү үзәге оештырды.

## Чираттагы Пленум утырышында мөфти мөхтәсибәтләрне «1100-еллык режимына» күчәргә чакырды

Сафәр аеның тугызынчы көнендә (16 нчы сентябрьдә), Чистай районы мөхтәсибәтендә ТР мөселманнары Диния нәзарәте Пленумының күчмә утырышы узды. Пленумның җыелышына төп сәбәп булып 4 сорау торды: Нәзарәтнең Президиум, Голәмәләр шурасы, Казыйлар шурасы, Аксакаллар шурасы составларын сайлау. Әлеге мәсьәләләр буенча Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин чыгыш ясады. Ул агымдагы елның Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителүен һәм Рәсәйдә халык санын алу кампаниясе якынлашып килүен искә алды. Хәзрәт милли-дини үзаңны үстерүдә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү эшендә мәчет-мәдрәсәләр алгы сафларда торуын искәртте. Моннан тыш, мөфти имам-мөхтәсибләргә һәм җитәкчеләргә

киләсе елда Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүнең 1100-еллыгы үткәрелү хакында әйтте һәм бөтен эшчәнлекне шушы зур датага багышлап, «1100-еллык» режимына күчәргә чакырды.

## Татарстанда гошер җыю кампаниясе башланды

Татарстан Республикасында Диния Нәзарәте башлангычы белән гадәттәгечә гошер садакасын җыю һәм халыкның мохтаҗ катламнарын азык-төлек белән тәэмин итү кампаниясе старт алды. Шуңа бәйле рәвештә, мөфтият 2021 елның 25 нче сентябрен Татарстанда Гошер көне дип игълан итте. Гошер көне Татарстанда барлык мөхтәсибәтләрдә үзәкләштерелгән рәвештә 2017 елдан бирле үткәрелә. Һәр елдагыча, мөхтәсибәтләрдәге мәчетләр гошер садакасы итеп җиләк-җимеш һәм яшелчәләр кабул итә.

## Балтач мөхтәсибәтендә тарихи дата уңаеннан 1100 төп агач утыртылачак

Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100-еллыгын каршылап, Балтач мөхтәсибәтенең Бөрбаш авылы мәхәлләсе 1100 төп агач утыртачак. Әлеге тәҗрибә мөхтәсибәтнең башка мәчетләрендә дә таралачак. Бу хакта Татарстанның баш казые, Балтач районы имам-мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыев Диния Нәзарәтенең үткән Пленум утырышында имам-мөхтәсибләргә хәбәр итте һәм барлык районнарда эшләүче хәзрәтләрне дә шушы башлангычка кушылырга чакырды. Әлеге акция якынлашып килүче зур тарихи датаны мәңгеләштерүнең бер үрнәге булачак һәм республикада 1100-еллык исеме астында яңа парклар һәм аллеяларга нигез салу өчен мөмкинлек тудырачак. Җәлил хәзрәт әлеге изге эшне мәктәпләрне һәм укучыларны җәлеп итеп башкарырга киңәш итте. Агач утырту һәм табигатьне яшелләндерү акциясе якын арада башланып, яз айларына кадәр дәвам итәчәк һәм 2022

елның маена кадәр, Ислам динен кабул итүнең 1100-еллыгы төп юбилей тантаналары башлануга тәмамланыр дип көтелә.

## Татарстан мөфтияте «Затлы мәҗлес» проектының чираттагысын башлап җибәрде

Татарстан мөфтияте хатын-кызлар өчен «Затлы мәҗлес» проектының икенчесен башлап җибәрде. Беренче очрашу 16 нчы сентябрьдә Казанда «Азу» кафесында узды. Программада ифтар, танышу, остаздан дәрес алу каралган. Очрашу «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең беренче хатыны Хәдичә» дигән темага багышланды. «Затлы мәҗлес» проектының лозунгы – хатын-кызлар тормышы турында дини сөйләшүләр ул. «Яшь килен» проектыннан аермалы буларак, очрашуларда Исламның матурлыгы, хатын-кызның нәфислеге һәм күңел дөньясы, Коръән, дин, фикһ мәсьәләләре, хатын-кызның тормыштагы роле, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең, сәхабәләрнең хатыннары, татар халкының хатын-кызлар белән бәйле традицияләренә багышланган темаларга сөйләшүләр алып барылачак. Ел ахырына кадәр барлыгы 7 очрашу көтелә.

## Казанда «I'MAN» ир-атлар проекты үзенең өченче сезонын башлады

Сафәр аеның 9 нчы көнендә (16 нчы сентябрьдә), Казанда ир-атлар өчен «I'MAN» проектының яңа сезоны башланды. Өченче сезонның беренче очрашуы Казанның Галиев мәчетендә узды. Күпсанлы сораулар буенча беренче дәресне Нәзарәтнең дәгъват мәсьәләләре бүлеге баш белгече, Казанның «Сәлах» мәчете имам-хатыйбы Тимергали хәзрәт Юлдашев «Мөэминнәрнең сыйфатлары» темасына багышлады. Алга таба очрашуда катнашучыларны иман, әдәп-әхлак, Исламда кардәшлек һ.б.

мәсьәләләренә багышланган дәресләр көтә. Тулырак мәгълүматны Инстаграмда @muslimmol аккаунтыннан алырга мөмкин. Ел дәвамында «I'MAN» проекты кысаларында ир-атлар өчен атна саен очрашулар, спорт күнекмәләре һәм лекцияләр уздырылачак. Очрашулар Казанның Галиев мәчетендә бара. Күренекле хәзрәтләр проектта катнашучыларга көндәлек тормышны җайга сала торган шәригать нормалары, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте турындагы белемнәрне арттыру, чын мөселманга хас әхлакый сыйфатларны үстерү, шулай ук рухи авырулардан котылу ысуллары турында сөйләнәчәк.

## Татарстанда «Ак кәгазьгә яңа тормыш» акциясе үтте

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте «Ак кәгазьгә – яңа тормыш» дип исемләнгән республикакүләм хәйрия акциясен игълан итте. Хәйрия акциясе 20 нче сентябрьдә башланып, 2021 елның 29 нчы сентябренә кадәр дәвам итте. Макулатурадан кергән акчалар Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды карамагындагы авыру балаларның дәвалануы өчен түләүгә тапшырылды. Акция барышында Аллаһы исемнәре, Коръән аятьләре, хәдисләр кергән кәгазьләрне дә җыю оештырылды (мондый китапларны һәм басмаларны аерып куярга һәм «ДИН» дип язарга кирәк иде). Билгеле булганча, андый кәгазьләр үзләренә аерым игътибар һәм сакчыл мөнәсәбәт таләп итә.

# Тарих

# Фин татарларының «Тампере шәһәре Төрекләр җәмгыяте»н төзүе



*«Фин татарлары. «Галиябану» спектакленнән. 1946 елның 19 нчы феврале. Мүәззез Байбулат китабыннан».*

XIX гасыр азагында Бөек Финляндия кенәзлегенең сәнәгать башкаласы булган Тампере шәһәрендә татар җәмәгатьчелеге оеша башлый. Моңа аеруча да 1876 елда Петербург-Тампере тимер юлының ачылуы тәэсир ясый. Элек Петербургта сәүдә иткән асламчы-татарлар, яңа сатып алучылар эзләү нияте белән, тимер юл аша Тампере шәһәренә килә. Сату итә торган төп товарлары тукыма була. Көчле конкуренция булмау сәбәпле, күпләр тиз арада байыйлар.

Нигездә алар: Нижгар губерниясенең Сергач өязендәге Актүк (Актуково) татар авылыннан булган кешеләр була. Шулай ук Мәдәнә (Медяна), Уразавыл (Уразовка), Атяр (Антяровка), Суыксу (Ключищи), Кызымавыл (Кузьминка), Кадымавыл (Кадомка), Чүмбәли (Чембилей), Семоцки (Семёновка), Рбишча (Рыбушкино) исемле күрше авылларыннан да күченеп

килүчеләр булган.

Революциягә кадәр Тампере шәһәренең татар җәмәгатьчелеге үзенә имам һәм укытучы итеп Галәветдин Габбасовны чакырган. 1910 елларда балаларны укыту имам йортында алып барылган, анда шулай ук җомга һәм бәйрәм намазлары укытылган. Галәветдин Габбасов туган җире Казанга кайтып китәргә мәҗбүр булганнан соң, мулла һәм укытучы итеп, Гыйбадулла Мортазин (1895-1968) чакырылган. Тамперега ул 1923 елны Алман иленнән килгән һәм 20 елдан артык гомерен җирле татар җәмәгатьчелегендә мәгариф эшчәнлеге алып баруга багышлаган.

Берлинда Гаяз Исхакый тарафыннан нәшер ителгән «Яңа милли юл» татар иммигрантлары журналының бер санында (1931 ел, №2) Гыйбадулла Мортазин Тампере татар җәмәгатьчелегенең кызыгырлык булмаган киләчәге турында хәбәр итә. Ул җирле җәмәгатьчелекнең, бигрәк тә яшь буын вәкилләре булучыларның, мәдәният һәм динне саклап калуда мөмкинлекләре аз булуы хакында яза. Әгәр хәлләр үзгәрмәсә, аларга тулысынча ассимиляцияләшү янаганы турында әйтә. Гыйбадулла Мортазин татарларга үз көчләренә ышанырга һәм мәдәниятне, динне, телне саклау белән шөгыльләнә торган социаль җәмәгатьчелекне барлыкка китерүнең кирәклегенә басым ясый.

Баштан бу эшләрне җәмәгатьчелекнең хатын-кызлары башлап җибәрә. 1934 елда Мәһрүсә Вафина (Mehrusa Wafin) тырышлыгы белән «Яшь ханымнар оешмасы» барлыкка килә. 1935 елның 6 нчы гыйнварында, Рамазан бәйрәме вакытында, бу оешма тарафыннан зур чара оештырыла. Мәһрүсә Вафина милли үзаңны, мәдәниятны, чит мәдәният әйләнәсендә телне саклауның кирәклеге турында сөйли. Бу оешма рәсми рәвештә теркәлгән булмаса да, нәкъ менә ул «Тампере шәһәре Төрекләр җәмгыяте» барлыкка килүгә сәбәпче була.

«Тампере Ислам мәхәлләсе»нең рәсми теркәлүенә кадәр «Тампере шәһәре Төрекләр җәмгыяте» җирле җәмәгатьчелекнең тормышында

әһәмиятле роль уйный. Ул һәрвакытта да Тампере мөселманнарына дини һәм милли бәйрәмнәр оештыра. Алар шулхәтле популяр булып китә ки, хәтта бу чараларга Финляндиянең барлык татарлары килә.



*Балалар хоры. Шагыйрь Габдулла Тукайга багышланган кичә, Hospiz Emmaus банкет залы, 1967 ел. Мүәззез Байбулат китабыннан.*

«Тампере шәһәре Төрекләр җәмгыяте» («Tampere Türkler Birligi») 1935 елда Финляндия дәүләт органнары тарафыннан барлыкка китерелә һәм рәсми рәвештә теркәлә. Җәмәгатьчелекне барлыкка китерүнең төп максаты: үзеңнең тарихың белән танышу һәм милли мәдәниятне саклау. Җәмәгатьчелектә зур рольне Гыйбадулла Мортазин башкара, нәкъ менә ул һәрвакытта диярлек үз өстенә оештыручы һәм мәдәни программаларны алып бару вазифаларын ала. Нигез салынганнан бирле һәм 1954 елга кадәр ул җәмәгатьчелекнең алыштыргысыз рәисе була. Әгәр дә беренче

елларда җәмәгатьчелекнең рәсми әгъзалары булып чама белән 50 кеше торса, 1961 елда аларның саны 119 га җитә. Күп еллар дәвамында «Тампере шәһәре Төрекләр җәмгыяте» җирле татар җәмәгатьчелегенең мөһим элементы булып тора.

*Мөхсин Нурулла язмасы,*
*islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә*

# Швециядә төпләнүче беренче мөселман

## Швециягә күченеп килүче беренче мөселман кешесенең татар булуы дөресме?

Соңгы вакытта Швециядә Ислам diненә кызыксыну арта. Бу барыннан да бигрәк илдә мөселманнар җәмгыяте арту белән бәйле. Моның белән беррәттән, Швеция галимнәре илдә беренче мөселманнарның барлыкка килү тарихын ачыкларга тырыша. Аларның тикшерүләреннән күренгәнчә, Швециядә иң беренчеләрдән булып төпләнүче мөселман Ибраһим Үмәркәев (1877–1954) исемле кеше булган. Швециянең рәсми документларында аның исеме Ebrahim Umerkajeff (Эбраһим Үмәркәефф) дип язылган. Аның Пенза губерниясенең Синорово (Татар Шукшасы) авылыннан (Пенза өлкәсенең Лунинск районы) булуы билгеле. 1897 елда Ибраһим Үмәркәев Рәсәй делегацияләре составында Юргорден утравында үтә торган сәнгать-сәнәгать күргәзмәсенә Швециягә килә.

Кызганычка, аның тормыш юлы турында бик аз мәгълүмат сакланып калган. Әмма моңа карамастан, Швеция тикшерүчесе Симон Соргенфрей матбугаттагы төрле реклама игъланнарына, хәбәрләргә таянып, Ибраһим Үмәркәевнең тормыш юлына кагылышлы кайбер мәгълүматларны таба алган.

Аңлавыбызча, Ибраһим Үмәркәев Юргорденга күргәзмәгә машина йөртүче буларак килгән. Әмма аннары туган ягына кайтмаска, ә Швециядә төпләнеп калырга уйлаган. Биредә ул Мария Элизабет Халт (1876–1955) белән гаилә корган. Аларның уллары Хөсәен Үмәркәев (1901–1989) туган. Швеция газеталарыннан билгеле булганча, Хөсәен спортчы булган. Мәсәлән, 1916 елның 11 нче октябрендә ул 12.3 секундта 100 метр араны йөгереп узган, ә 1930-1940 елларда яхшы итеп боулингта уйнавы белән осталык күрсәткән.



*Ибраһим Үмәркәев.Тору өчен рөхсәт алу гаризасындагы фотосурәт. Фото «Швеция Милли Архивы һәм Стокгольм Шәһәр Архивын»нан алынды.*



*Хөсәен Үмәркәев. Тору өчен рөхсәт алу гаризасындагы фотосурәт. Фото «Швеция Милли Архивы һәм Стокгольм Шәһәр Архивын»нан алынды.*

Ибраһим Үмәркәев эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнә башлый. 1906 елның 16 февралендә ул Стокгольмда сәүдә эшләрен алып баруга рөхсәт бирүләрен сорап, Швециянең финанслар Министрлыгына мөрәҗәгать итә. Реклама игъланнарыннан ук билгеле: аның 1907 елда Гревтурегатан 77 адресы буенча урнашкан «Тире эшләнмәләре кибете» булган. Соңрак кибет Риддаргатан 4 буенча урнашкан адреска күченгән. Ә аннары 1914 елда Беренче бөтендөнья сугышы башланган вакытта кибет Хумлегардсгатан 7 адресы буенча урнашкан булган.

1919 елда Ибраһим Үмәркәевнең сәүдәсе яхшы барганы билгеле. Ул гаиләсе белән Скеппарегатан урамы, 39 нчы йортта урнашкан, аерым аш бүлмәсе булган биш бүлмәле зур фатирда яшәгән. Аның шулай ук бакчасы һәм Виггбюхольмда яхтасы булган.

1918 елда Ибраһим Үмәркәев тору өчен рөхсәт бирүләрен сорап, гаиләсе белән Швеция хакимиятенә мөрәҗәгать итә. 1919 елда аның Швеция гражданлыгын алуы билгеле. Ә менә 1920 елда аның өчен авыр сы-

нау елы була. Башта хатыны Элизабет Халт белән аерылышалар, ә аннары җирле хакимият аның тире кибетен банкрот дип игълан итә.

Әмма газета игъланнарыннан билгеле булганча, Ибраһим Үмәркәев төшенкелеккә бирелми. Уңышлы реклама компаниясе ярдәме белән ул 1930 елда яңадан тире кибетен ачып җибәрә. Кибет Биргер Ярлсгатан урамы, 38 йорт адресы буенча урнашкан була. Бу юлы кибеттә товарлар ассортименты арта: тире эшләнмәләренә өстәп, көнчыгыш келәмнәре дә сатыла башлый.



*Мария Элизабет Халт*
*Фото «Швеция Милли Архивы һәм Стокгольм Шәһәр Архивын»нан алынды.*

1930 елда Ибраһим Үмәркәевнең тормышында тагын бер вакыйга була. Улы Хөсәен Үмәркәев Сигрит (Пирет) Тиллман (1907–1982) белән гаилә кора. Бер елдан соң аларның кызы Надья (1931-1990) туа. Шул ук елны Стокгольмда Төркия шәһәреннән булган Кайсери Акиф Архан (1905–1981) үзенең келәм кибетен ача. Ул бу вакыйгага хәтле берничә ел алдан Швециядә нигезләнгән була. Шуңа күрә Акиф Арханның Хөсәен Үмәркәевтән соң Швециядәге икенче мөселман кешесе булганын аңлыйбыз.

# Швециядә беренче татарлар: мөселман татар җәмәгатьчелегенең барлыкка килүе

**Бу мәкалә 1940-1950 елларда Швециягә күченеп килеп, Швециядә рәсми мөселман җәмәгатьчелегенә нигез салган татарларга багышлана.**

Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында һәм аннан соң качакларның килеп урнашулары өчен Швеция иң кулай илләрнең берсе була. Биредә күченеп килүче иммигрантлар өчен чит ил кешеләре эшләре буенча Дәүләт комиссиясе (Statens utlänningskommission) барлыкка китерелә.

Җирле тәртип саклау органы даими рәвештә күченеп килүчеләр белән әңгәмәләр корган, сораштырулар үткәргән, аларның килеп чыгышы, гаилә хәле, үткән тормышлары, белем дәрәҗәсе, ни белән дә булса мәшгуль булу-булмаулары һәм башкалар хакында мәгълүмат туплаган.

1950-1960 елларда күченеп килүче татарларның барлык документлары, гражданлык алганчы, Швеция милли архивында тупланган була.

Ибраһим Үмәркәев 1940 елларда Швециягә күченеп килүче татарларга ярдәм итүдә зур роль уйнаган. Кайберләрен Виггбюхольмда булган, җәй көннәрен үткәрә торган шәхси йортында урнаштырган.

Ул аларга үз йортында яки кибетендә эш биргән. Сугыш вакытында Балтыйк буеннан булган күпчелек татарлар Финляндиягә качып килгән. Советлар Союзына көчләп җибәрелүдән куркып, сугыштан соң аларның бер өлеше Швециягә күченеп килгән.

Швециягә беренчеләрдән булып, яңа туган кызлары Дидар белән Гали һәм Зәйнәп Закировлар күченеп килә. Тумышлары белән алар Таллиннан була. Эстониядә Закировлар Рәсәй империясе вакытында нигезләнә. Алар Эстония татарлары арасында иң бай гаиләләрнең берсе була. Гали Закиров баштан Финляндиягә күченеп килә, чөнки Совет хөкүмәте Тал-

линда аның гаиләсенең бар мал-мөлкәтен конфискацияләгән була, гаилә башлыгы бернәрсәсез кала. Кызлары Дидар Финляндиядә туа. Әмма Советлар Союзына җибәрелүдән куркып, алар Швециягә качып китәргә карар кылалар. Финлы-Швецияле чикләренең төньяк өлеше начар сакланган була һәм контрабандистка акча түләп, алар чикләрне үтүгә, шул рәвешле Швециягә элгүгә ирешә.

Швециядә аларны солдатлар каршы алып, качаклар өчен Умео шәһәрендә урнашкан лагерьга озата. Финляндиядән һәм Балтыйк илләреннән булган күпчелек татарлар кебек, Гали Закиров тире эшләнмәләре буенча белгеч була. Ул Ибраһим Үмәркәевне белгән, әмма аның җитәкчелегендә эшләмәскә булган. Закировның Таллинда берничә яһүди дусты була. Алар ярдәме белән ул беренче эшен Стокгольмадагы күн эшләнмәләре белән шөгыльләнүче яһүди кешесендә таба. Ни генә булса да нәкъ менә Үмәркәев Закировларга Виггбюхольмда вакытлыча яшәп торуда ярдәм итә.




*Гали Закировның Эстония паспорты.*
*Гали Закировның паспорты geni.com нәселләр һәм шәҗәрәләр сайтыннан алынды.*

Берничә ел дәверендә башка татар качкыннары да, Финлядиянең төньягы чикләрен үтеп, Швециягә килеп элгә. Күпмедер вакытларын алар качкыннар лагерында үткәреп, кыска вакытка эш табып, Үмәркәев ярдәме белән, гадәттә, Виггбюхольмда кала, ә аннары Стокгольм шәһәренә күченеп китә торган була.

1944 елда Швециягә Вәлиулла Фәтхуллин күченеп килә. Аның гаиләсе Эстониянең Нарва шәһәре татарлары була. Тагын бер күченеп килүче кешенең исеме – Ибраһим Зарип, ул да Эстония татары. Вәлиулла Фәтхуллин баштан Евле шәһәрендәге һәм Окельбо торак пунктындагы лагерьларда эшли, ә аннары Стокгольмга тире эшләнмәләрен җитештерүче булып урнаша. Ибраһим Зарип Эскильстуна шәһәре тирәсендәге фермага килеп урнаша, ә аннары шулай ук Стокгольмга күченеп китә.

1945 елда Швециягә Хәйрулла Сәмлихан исемле татар кешесе күченеп килә. Чит ил кешеләре эшләре буенча Дәүләт комиссиясендә ул үзен Финляндиянең Терийоки шәһәрендә (хәзер Рәсәйнең Зеленогорск шәһәре) туган дип әйтә. Икенче кеше Рафат Саләх исемле була. Ул да үзен Терийоки шәһәрендә туган, әмма Ленинградта үскән дип әйтә. Биредә 1934 елны аның әтисен төрмәгә утыртканн булалар. Ә аннары гаилә Финляндиягә качып киткән. Аларның икесе дә Катринехольм шәһәрендә Aktiebolaget Pälsförädling тире эшләнмәләре компаниясендә эшли.

1947 елда Швециягә Нарвадан тагын бер татар кешесе – Әхмәд Хәердинов, ә 1948 елда Мансур Насретдин күченеп килә. Ул Лаппеенранта шәһәреннән фин татары була.

*Дәвамы бар*

*Дамир Гайнетдинов язмасы,*
*islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә*

# Мирас

# «Татарларда – Ислам һәм каллиграфия сәнгате»

Җир шарында яшәүче халыкларның 7%ы гарәпчә яза, гарәп язуы 22 дәүләттә рәсми рәвештә кабул ителгән. Гарәп телендә сөйләшүче халыклардан тыш, әлеге язма Әфганстан, Һиндстан, Иран һәм Пакыстан халыкларында кулланыла. Ә бездә – татарларда гарәп язуы сәнгатьнең бер төре дә – каллиграфия (хаттатлык) булып тора (ул татарларда хөсне хат дип атала (ред.).

Татарларда каллиграфия нинди дә булса мәгънә һәм мәгълүмат җиткерү чарасы гына түгел, ә төрки, шәркый мәдәниятнең тирән бер катламы. «Язу матурлыгы күңел матурлыгын, яктылыгын тудыра», – дип язган төрекнең мәшһүр хаттаты Солтан-Гали Мәшһәд.

Каллиграфия – үзенчәлекле сәнгать. Латин теленнән ул «матур язу» дип тәрҗемә ителә. Каллиграфия – сынлы сәнгать сүзенең һәм форманың синтезы ул. Бу очракта сүз беренче планга чыга, ул билгеле бер формада бизәлә.

Гарәп каллиграфиясендә иң күп язылган сүзләр: «Коръән» һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләре сүзләре. Беренче каллиграфик язулар Аллаһы Тәгалә исемнәре, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм пәйгамбәр һәм аның көрәштәшләрен зурлап язылган сүзләр, Коръәннән өзекләр белән бәйле. Тора-бара танылган шагыйрьләрнең, язучыларның фәлсәфи шигъри юллары да бизәкләп языла башлый.

Татар халкы гарәп шрифтын X гасыр уртасыннан куллана башлый һәм 700 елдан артык кулланган. Ислам дине үскән, камилләшкән саен, каллиграфия дә үсә. Болгар ханлыгы чорында ук (X гасыр башында) Коръәнне күчереп яза башлыйлар.

XVI гасырда яшәгән китап күчереп язучылар арасында танылган каллиграф (хаттат) Казан ханлыгының Мәскәүдәге илчесе Әднәш-хафиз

бине Мөхәммәдәднәш тә булган. 1554 елның маенда кулга алынгач, Әхмәт Ясәвинең һәм Сөләйман Бакырганиның шигырьләрен, «Сиражел-колүб» әсәрләрен күчереп яза. Бүгенге көндә әлеге китаплар – Мәскәүдә Борынгы актлар саклана торган дәүләт архивында.

XVI гасырга караган тагын бер кыйммәтле каллиграфия үрнәге – гарәпчә-татарча сүзлек. 1581 елда Хаҗи Бәйрәм бине Хаҗи Булат тарафыннан эшләнә. Бүгенге көндә әлеге сүзлек Казан (Идел буе) федераль университетының фәнни китапханәсендә саклана.

XVII-XIX гасырларда Казан татарлары арасында Габдрахман бине Туймөхәммәт, Гыйлми бине Үтәмеш, Сәйфелмөлек бине Зәйнетдин, Габдрәшит бине Мортаза, Җәгъфар бине Якуб кебек хаттатларның исемнәре танылган булган. Данлыклы хаттат арасында Габдрәхим Утыз Имәни, Рәхмәтулла Әмирхани, Шиһабетдин Мәрҗани дә булган.

Хаттатларның күбесе гомерләрен китап күчереп язуга багышлаганнар. Габденнасыйр бине Сабит, мәсәлән, 20 яшеннән 95 яшенә кадәр китап күчереп язу белән шөгыльләнгән, 223 китап язган. Хөсәен бине Әлмөхәммәт Коръәнне берничә йөз данәдә күчереп язган.

Китап күчереп язу бик күп вакыт һәм хезмәт таләп иткәнгә күрә, югары бәяләнгән. Мәсәлән, 1841 елда Бөгелмә өязенең Әлки авылында каллиграфик ысул белән күчереп язылган Коръәннең бер данәсен 200 сумга сатып алганнар. 200 сумның кыйммәтен аңлау өчен: ул вакытта ат 20 сум торган.

Китапларны кулдан күчереп язу гадәте XIX гасырга кадәр дәвам итә.

Казанда, аерым алганда, Татар әдәбияты тарихы музее һәм Шәриф Камал мемориаль фатирында Кол Галинең кулдан күчереп язылган «Кыйссаи Йосыф» әсәре саклана. Шунда ук Мөхәммәдъярның 1542 елда язылган «Нуры содур» әсәрен күрергә була. Музейда саклана торган кульязма XIX гасырга карый. Хисаметдин Мөслиминең XIX гасырның икенче яртысында күчереп язылган «Идел Болгары тарихы» дип исемләнгән җыентыгын

Татарстан Республикасы Милли музее фондында саклана. Татарларда хаттатлык (каллиграфия) сәнгате турында күбрәк белергә теләүчеләр музейларга мөрәҗәгать итә ала.

*Гөлназ Рәшит кызы Җиһангирова*

*Татар әдәбияты тарихы музее һәм Ш.Камал мемориаль фатирының өлкән фәнни хезмәткәре*

# Фән

# Галимнәребезне тану һәм аларны хөрмәт итү әһәмиятлелеге турында

Һәр мөселман кешесенең гомерендә бер тапкыр булса да **«... коллары арасында Аллаһыдан [иң каты] куркучылар – галимнәр»,** – дигән аятьне ишеткәне бардыр. Ләкин кайсыбызның бу аятьнең мәгънәсенә төшенгәне бар? Аллаһы Тәгалә ни өчен шулай дип әйтә микән дип, кайсыбызның уйлап караганы булды? Әлеге сорауга беркадәр җавапны аятьнең үзеннән дә табабыз. Аятьтә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«[Расүлем!] Аллаһының күктән суны иңдергәнен күрмәдеңме? Аның белән Без төрле төсле төрле җимешләр чыгардык. Таулар арасында да төсләре төрле – аклы, кызыллы һәм кап-каралары – бар. Кешеләрдән, [җир йөзендә] хәрәкәт иткән җанлылардан һәм терлекләрдән дә төсләре төрле-төрле булганнары бар. Коллары арасында Аллаһыдан [иң каты] куркучылар – галимнәр. Һичшиксез, Аллаһы – Бөек [Җиңелмәс], [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче».**

«Фатыйр / Бар кылучы», 35:27-28

Күргәнебезчә, әлеге аятьтә Аллаһы Тәгалә төсләрнең һәм килеш-килбәтләрнең күптөрлелегендә, карашлар һәм фикерләрнең төрлелегендә олы хикмәт яшеренгәнлегенә ишарә итә, һәм моның хикмәтенә төшенә алуның бердәнбер юлы итеп – мондый күптөрлелеккә бербөтен итеп карый белүне атый. Чөнки аятьнең башында да бөтен бу күптөрлелекне барлыкка китерүче бердәнбер чыганак итеп – күктән иңгән су күрсәтелә. Без – мөселманнар өчен күктән иңгән иң мөһим чыганак – Коръән булганлыктан, бу мәкаләдә антропологлар, минералоглар яки биологлар хакында сүз бармас, гәрчә алар да илаһи билгеләр белән эш итүче галимнәр булсалар да, ләкин монда үз гомерләрен Коръәнне өйрәнүгә багышлаган галимнәр турында сүз барачак.

Күптән түгел генә «Хозур» нәшрияты тарафыннан күренекле шәфигый галиме Мөхәммәд Касыйм Габдух Әл-Харисинең «Әбү Хәнифәнең мөхәддисләр арасында тоткан урыны» исемле хезмәте рус теленә тәрҗемә итеп бастырылды. Әлеге хезмәт авторның докторлык диссертациясе булып тора. Бу хезмәтендә автор хәнәфи фикһы мәктәбенә нигез салучы имам Әбү Хәнифә рахимәһуллаһига карата абруйлы урта гасыр галимнәренең әйткән тәнкыйди фикерләрен бергә туплап, җентекле анализ ясап, объектив бәя бирә. Шул рәвешле, автор Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи турында урта гасыр чыганакларындагы күп кенә мәгълүматларның ачыктан-ачык ялган һәм яла булуын исбатлый, андый фикер һәм караш ияләрен, атаклы галимнәр булуларына карамастан, көнчелектә, тар карашлылыкта һәм объектив булмауда гаепли. Мөхәммәд бине Әл-Хариси билгеләп үткәнчә, Әбү Хәнифә, имам Мәлик, Әхмәд бине Хәнбәл һәм имам Шәфигый рахимәһумуллаһи кебек күренекле ислам галимнәренә карата әйтелгән тәнкыйть сүзләренең нигезендә наданлык, көнчелек һәм тар карашлылык ята. Тарих кабатлана, һәм бүген дә Коръән һәм хәдисләрнең асыл мәгънәсенә төшенмичә, өстән генә фикер йөртеп, башкаларның фикерләре белән санлашмау исламда тәкфир һәм сәләфилек хәрәкәтен китереп чыгарды. Анда һәркем үз-үзенә галим, мөфти, имам. Хәлбуки, Аллаһы Тәгалә безгә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Барыгыз бергә Аллаһының арканына [Китабына һәм диненә] ныклап ябышыгыз һәм [әһле китап кебек ихтилафка төшеп хакыйкатьтән һәм бер-берләрегездән] аерылмагыз. Аллаһының сезгә биргән [игелек һәм] нигъмәтен истә тотыгыз. Сез [җәһилият чорында бик озак еллар буена бер-берсе белән сугышкан] дошманнар булган чакта, Ул [сезне Ислам дине белән шәрәфләндереп] күңелләрегез арасында [татулык һәм бер-берегезгә карата җылылык яратып] өлфәт бердәмлек барлыкка китерде, һәм сез Аның [бу] нигъмәте**

**белән [бер-берләрен бик якын күргән] кардәшләр булдыгыз. Янә сез [кяферлегегез сәбәпле] Ут упкыны ярында чакта, [Мөхәммәдне [салләллаһу галәйһи вә сәлләм] җибәреп] Ул сезне аннан коткарды. Аллаһы аятьләрен сезгә шулай бәян итә, бәлки, сез һидаять табарсыз. Арагызда [дини һәм дөньяви] хәергә [файдалы эшләргә] чакыра, яхшы гамәлләрне [кылуны] әмер итә, начар гамәлләрдән тыя торган җәмәгать булсын. Менә шулар – уңышка ирешүчеләр».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:103-104

Шуны да белергә кирәк ки, чын галимнәр бер-берсен беркайчан да оппонент итеп күрмәгән, чөнки гыйлемне алар барысы да бер чыганактан – Коръәннән алганнар. Максатлары да бер иде – Аллаһының ризалыгы өчен халыкка хезмәт итү. Мәсьәләләрне хәл итү юллары төрле булса да, чара һәм кораллары бер – Коръән һәм сөннәт иде.

Әбү Хәнифә рахимәһуллаһиның фикһ мәктәбе һәм методологиясе турында күп әйтелеп, күп язылганга күрә, бу мәкаләдә әлеге галим турында хәдис белгече буларак кына берничә сүз әйтеп китәсе килә. Мөхәммәд Әл-Харисинең «Әбү Хәнифәнең мөхәддисләр арасында тоткан урыны» исемле китабында моның турында шулай диелгән: «Мөхәддисләр арасында хәдис тапшыручының компетентлылыгы аның хәдис тапшыручылар арасында тоткан абруе белән билгеләнә. Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи дан хәдис ишетеп, бүтәннәргә җиткерүчеләр – замананың иң күренекле мөхәддисләре иделәр. Алар ышанычлы булулары белән генә түгел, ә хәдис тапшыруда гадәттән тыш төгәллекләре белән дә аерылып торганнар. Хәдисне берәрсеннән кабул иткәнче, ул хәдиснең тапшырылу чылбырын (иснәдне) җентекләп тикшергәннәр. Әгәр хәдис тапшыручылар арасында ышанычлы булмаган берәү ачыкланса, шунда ук аны фаш иткәннәр. Ибне Мәһди һәм Ибне Әл-Мәдәнидән алып, Ән-Нәсаи һәм Әбү Давыд белән тәмамлап, Әхмәд бине Хәнбәл, Ибне Мәгыйн һәм Исхак бине Раһәвәеһ кебек хәдис өлкәсендәге урта гасыр тәнкыйтьчеләренең күбесе заманын-

да үзләре дә Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи шәкертләреннән хәдис алганнар. Бу исә – олы остазның югары әхлак һәм камил зиһен иясе булганлыгына һичшиксез бер дәлил булып тора».

Әмма Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи Коръән-хафиз һәм хәдис белгече булып кына калмаган, хәтерендә саклanган гыйлемнәрнең көндәлек тормышта дөрес кулланылышын эзләп таба алуда ул аеруча сәләткә ия иде. Аллаһы Тәгалә аны аек акыл һәм гадәттән тыш хәтер белән бүләкләгән. Ул Коръән аятьләреннән һәм хәдисләрдән моңа кадәр табылмаган җавапларны таба ала торган булган һәм шул сәләте белән гади халык һәм галимнәр арасында югары абруй казанды. Хәтта замананың иң бөек мөхәддисләрнең берсе – Сөләйман Әл-Гәмәш Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи турында болай дип әйтә торган булган: «Дөреслектә, сез факыйһлар – табиблар, ә без мөхәддисләр – бары тик даруханәчеләр генә!»

Үз гомерендә Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи төрле мәсьәләләргә караган биш йөз меңгә якын фәтва чыгарган. Шулардан бары тик йөз егермесе генә урта гасыр галимнәрендә кайбер сораулар тудырган. Мөхәммәд Әл-Хариси үз хезмәтендә бу очракларның һәрберсен җентекләп тикшерә, һәм имам Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи чыгарган бу фәтваларның Коръән һәм сөннәткә каршы килмәвен дәлилли.

Әлбәттә, Әбү Хәнифә рахимәһуллаһиның мондый гадәттән тыш тырышлыгы һәм эшчәнлеге югары даирә вәкилләренең игътибарын җәлеп итми калмаган. Әле өммәвиләрдән Ибне Хөбәйра идарә иткән дәвердә имам Әбү Хәнифә раһимәһуллаһига Куфа шәһәренең югары казые булырга тәкъдим ителгән иде. Ләкин галимне гаделсез идарәчегә хезмәт итү кызыктырмый, һәм ул түрә тәкъдимен кабул итмәгәне өчен ирегеннән мәхрүм ителә. Үлем җәзасыннан Әбү Хәнифә раһимәһуллаһины бары тик зирәклеге генә коткара, һәм ул Мәккәгә качып котыла. Туган Куфасына Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи өммәвиләр бәреп төшерелеп, габбасиләр хәлифәсе Әбү Җәгъфар Әл-Мансур идарә итә башлагач кенә әйләнеп

кайта. Бу еллар дәверендә Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи сәхабәләр һәм табигыйннәр белән аралашып гыйлем туплый. Үз янында да күп кенә тыңлаучылар җыя. Шулар арасында мәлики мәзһәбенең коручысы – Мәлик бине Әнәс рахимәһуллаһи да (имам Мәлик) була. Моның турында имам Мәлик рахимәһуллаһи соңыннан үзе болай дип әйтә торган иде: «Мин шундый кеше янәшәсендә утырганым булды ки, каршыдагы баганаңы алтын дип әйтсә, моны һичшиксез исбатлый алыр иде!»

Куфага әйләнеп кайткач, имам Әбү Хәнифә рахимәһуллаһиның атаклы галим буларак абруе һәм дәрәҗәсе тагын да арта. Озакламый аны габбасиләр хәлифәсе Әбү Җәгъфар Әл-Мансур да югары казыйлыкка чакыра. Ләкин Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи бу юлы да әлеге тәкъдимнән баш тарта һәм шул сәбәпле янәдән ирегеннән мәхрүм ителә. Тоткынлыкта ул төрле җәзаларга дучар ителә, ләкин Әбү Җәгъфар Әл-Мансур галимне барыбер үз ягына аудара алмый. Нәтиҗәдә Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи 67 яшендә Багдад төрмәсендә үлә.

Шулай итеп, имам Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи мисалында без **«... Коллары арасында Аллаһыдан [иң каты] куркучылар – галимнәр»** аятенең чын мәгънәсен аңлыйбыз. Ул – гомеренең соңгы көннәренә хәтле Коръән һәм сөннәттән өйрәнгән принципларга тугры булып калган чын мәгънәсендәге галим кеше.

Имам Әбү Хәнифәнең тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйле әлеге һәм күп кенә башка мәгълүматларны сез Мөхәммәд Касыйм Габдух Әл-Харисинең «Әбү Хәнифәнең мөхәддисләр арасында тоткан урыны» исемле китабыннан укып белә аласыз.

*Альберт Кадыйров,*

*Казан шәһәре Дәрвишләр бистәсе мәчете мәхаллә әгъзасы, тәрҗемәче*

# Мәүлид

# Мәүлид бәйрәме

Мәүлид бәйрәмен (Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган көненә багышланган мәҗлес) беренче тапкыр XII–XIII гасырларда Ирбил шәһәрендә үткәрә башлаганнар. Шул шәһәрнең ихласлы хакиме Мәлик Мөзәффәр Әбү Сәгыйд Күкбүре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне бик сөйгән һәм аның шәфәгатен өмет итеп, касыйдәләрне (Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышында булган әһәмиятле вакыйгалар турындагы поэмаларны) укыр өчен диндар галимнәрне үзе янына җыйган. Шулай итеп, Мәүлидкә нигез салган.

Касыйдәләрне гарәп һәм үз телләрендә укыйлар. Мәүлид бәйрәмендә төрле ризыклар әзерләнә, мохтаҗларга, ятимнәргә садакалар, киемнәр бирелә. Бу изге гамәлләрне кылган мөселманнар савапка ирешер, иншәАллаһ. Кызганычка, кайбер кешеләр, Коръәнне һәм хәдисләрне дөрес аңламыйча, Мәүлидне уздыру куркыныч бидгать, дип әйтәләр. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләре заманында Мәүлид бәйрәме бер дә үткәрелмәгән, диләр. Моңа дәлил итеп, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен китерәләр: «Насаралар Гайсәне олылаган кебек, мине алай олыламагыз», – ягъни илаһилаштырмагыз. Бу хәдискә таянып, Мәүлидне Раштуа яисә тагын да начаррак гамәл – потка табыну белән чагыштыралар. Әлеге фикер дөреслеккә туры килми. Беренчедән, сәхабәләр заманында билгеләнгән көнне җыелырга һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы турында сөйләргә, ишетергә ихтыяҗ булмаган, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тарафдарлары аны һәркөнне күргәннәр һәм һәрвакыт аның янында булганнар. Бер тапкыр Аллаһы Тәгаләнең Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһедән: «Син Аллаһыдан соң кемне күбрәк яратасың?» – дип сораган. Сәхабә: «Алдан үземне, анна-

ры сине, йә, Расүлуллаһ», – дип җавап биргән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йә, Гомәр, синең ихласлыгың зәгыйфь», – дигән. Шуннан соң Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһе: «Алай булгач, Аллаһыдан соң, дөньядагы бөтен нәрсәдән күбрәк, сине яратам!» – дигән. «Менә хәзер инде синең ихласлыгың көчле», – дип әйткән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм.

Ибне Һишам Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы турындагы китабында: «Сәхабәләр Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмне шулкадәр нык яратканнар ки, хәтта азанда «Мөхәммәд Расүлуллаһ» дигән сүзләр яңгырагач, аларның күңелләре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата мәхәббәт белән тула һәм алар елый башлыйлар иде», – дип язган. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң, һәрвакыт мөселманнарны намазга чакыручы Билал радыяллаһу ганһе исемле сәхабә нәкъ менә шушы сәбәп аркасында азан әйтүен дәвам итә алмаган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм гади кеше булмаган, ул – бөтен мәхлүкълар өчен Аллаһы Тәгаләнең сайланган Расүле иде. Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ ۚ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا ﴿٥٦﴾

**«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. [Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә аңа рәхмәтләр һәм бәрәкәтләр яудыра, фәрештәләр исә аңа югары теләге белән дога кылып, шәрәф казана һәм аның зикере белән бәрәкәтләнәләр]. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Мөхтәрәм җәмәгать, шуны онытмыйк! Әгәр без сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтенә иярсәк, аның тормышыннан үрнәк алып яшәсәк, иншәАллаһ, Раббыбызның рәхмәтенә һәм ризалыгына ирешербез. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

قُلْ إِن كُنتُمْ تُحِبُّونَ اللَّهَ فَاتَّبِعُونِي يُحْبِبْكُمُ اللَّهُ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ ﴿٣١﴾

**«[Расүлем!] Әйт: «Әгәр сез Аллаһыны сөясез икән, миңа иярегез, шулвакыт Аллаһы да сезне сөячәк һәм гөнаһларыгызны гафу итәчәк».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:31

Икенчедән, Мәүлидне Гайсә галәйһиссәламне олылау, «илаһилаштыру» белән чагыштыру, бер сүз белән әйткәндә, наданлык булыр иде. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган көненә багышланган нинди дә булса чараларны үткәрү – потка табыну белән бер, дигән сүзләр Ислам динен мәсхәрә итү була. Мондый сүзләрне фәкать белемсез, надан кешеләр яисә Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дошманнары гына әйтә ала.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе дә туган көнендә, ягъни дүшәмбе көнне ураза тота торган булган. Аннан: «Йә Расүлуллаһ, ни өчен син дүшәмбе көнне ураза тотасың», – дип сораганнар. Пәйгамбәребез: «Мин бу көнне тудым һәм бу көнне миңа вәхи иңдерелде»[1], – дигән. Белгәнебезчә, ураза тоту – ул Ислам терәкләренең берсе. Моннан күренә ки, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең туган көнен гыйбадәттә үткәргән.

Хөрмәтле мөселманнар! Фәнни әдәбиятта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм турындагы беренче шигъри әсәрләрне (мәүлиденнәби) төрки шагыйрьләр иҗат иткән дип санала. Рәсәй мөселманнары

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

арасында төрек шагыйре Сөләйман Чәләбинең Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә багышланган «Вәсиләтүн-нәҗәт» исемле поэмасы (1409 ел) халык арасында киң таралган булган. Әлеге поэма 1917 елга кадәр Казанда алты тапкыр нәшер ителгән (1849 елда, ике тапкыр 1873 елда һәм 1886, 1895 елларда). Татар телендә дә мәүлидләр язылган. Бу әсәрләрне шагыйрьләр генә түгел, ә мәдрәсәдәге остаз һәм шәкертләр дә иҗат иткән. Мәсәлән, Казанда 1861 елда «Мәүлиден-нәби» («Хәзрәти Расүлнең дөньяга килгәнен һәм дөньядан күчкәнен бәян иткән мөбарәк китаптыр») дип исемләнгән шигъри әсәр бастырылган. Бу әсәрләрне бик матур итеп көйләп укыганнар.

Бүгенге көндә Мәүлидне бәйрәм итү гадәтләре кайтарыла башлады. Авылларда гына түгел, шәһәрләрдә дә Мәүлидләрне уздыралар. Күпчелек галимнәрнең фикеренчә, Мәүлид яхшы бидгать (бидга хәсәнә) булып санала. Бу турыда: «Мәүлид уку – Исламның бик яхшы һәм файдалы гадәте. Ул мөэминнәр арасындагы аралашу, аларның иманы өчен ышандыргыч дәрес, кешеләр йөрәгендә Аллаһыга һәм Аның соңгы расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата мәхәббәт уяту», – дигәннәр.

XX гасыр башында татар телендә иҗат ителгән мәүлид касыйдәсендә шундый юллар бар:

*Укылырса Мәүлиддә махсус касыйдә һәр заман,*
*Ул Расүлнең рухы хуш-нуд булачактыр бел, фәлән.*

Мәүлид бәйрәмендә укылган дога, аять, хәдисләр, мөнәҗәтләребез өчен генә түгел, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен кылынган барлык изге гамәлләребез өчен, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең рух-шәрифләре шат булса иде.

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*«Саләх» мәчетенең имам-хатыйбы*

# Салават

Гарәп телендә «салават» (صَلَوَات) сүзе «салят» (صَلَاة) сүзенең күплек сан төре. Ул «намаз», «дога» мәгънәсендә килә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават – мөселманнарның аңа карата яратуларын, рәхмәт һәм хөрмәт хисләрен, Расүлебезнең Кыямәт көнендә шәфәгатенә өметләнүен белдерүе ул.

Пәйгамбәребезгә салават әйтү – аның исемен әйткәннән соң «Салләллаһү галәйһи вә сәллам» дип өстәү ул.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ ۚ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا ﴿٥٦﴾

**«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. [Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә аңа рәхмәтләр һәм бәрәкәтләр яудыра, фәрештәләр исә аңа югары теләге белән дога кылып, шәрәф казана һәм аның зикере белән бәрәкәтләнәләр]. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Биредә Аллаһы Тәгаләнең салават әйтүе – аны фәрештәләр алдында мактавын белдерә, фәрештәләрнең салават әйтүе – аның өчен дога кылуларын аңлата.

Суфьян Әс-Сәуридән китерелә: «Аллаһының салаваты – рәхмәт, фәрештәләрнең салаваты – истигъфар»[1].

---

[1] Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

Мөэминнәрнең Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтүләре аңа дога булып бара һәм аны олылауларын белдерә.

## Нәрсә ул салават?

Әбү Галия исемле хәзрәт әйтүенчә, салават – Аллаһы Тәгаләнең Пәйгамбәре Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне, Раббыбызның хәбибен мактауны аңлатыр. Фәрештәләрнең Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватлары – аларның истигъфарларыдыр. Кешеләрнең салаваты – хәер-дога әйтү, игелек теләүдер. Аллаһы Тәгалә Үзенең хәбибен яраткач, якын күргәч, аңа салават әйтү Аллаһы Тәгаләдән үзенә хәер-дога алу белән бер. Хәзрәти Габдулла бине Гамер әйтүенчә, кем булса да Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бер салават әйтсә, әйтүче Аллаһы Тәгаләдән һәм Аның фәрештәләреннән 70 салаватка ирешер. Пәйгамбәребез үзе дә: «Кем булса да миңа бер салават әйтсә, Аллаһы Тәгалә аңа ун салават булдырыр, кем 10 салават әйтсә – Аллаһы Тәгаладән 100 гә ирешер. Кем миңа 100 салават әйтсә – Аллаһы Тәгалә аңа икейөзлелектән котылуны һәм уттан котылуны насыйп итәр һәм Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә аны шәһитләр белән бергә булдырыр», – дигән. Хәтта, күп риваятьләргә күрә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кабере янында, Аллаһы Тәгалә тарафыннан вәкил итеп куелган фәрештә торадыр. Ул фәрештә, Пәйгамбәребез әйтүенчә, аның исемен искә алганнар белән салават әйткәннәрнең авазларын ишетеп торыр. Салават әйтелү белән, ул фәрештә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә: «Сиңа фәлән углы яки кызы фәлән салават әйтте», – дип җиткерер. Шундый әҗерле, бәрәкәтле, саваплы, хөрмәтле салават ничек яңгырарга тиеш соң? Заманында Пәйгамбәребез бу сорауны якын сәхабәләреннән дә ишеткән була.

Фазыйләтле салаватның берсе – «Әллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галә әәли Мүхәммәдин вә сәллим» дип әйтү. Тик әйтүче кеше бу са-

лаватларны әйткәндә, «салли» сүзендә басымны «а» авазына куярга тиеш, чөнки «салли» дигәндә басымны «и» авазына куйса, бик олы көферлек кылуы бар!

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтергә кушып, Аллаһы Тәгалә безгә җиңеллек, өстенлек булдыра. Ишеткән кеше ишетмәгәнгә җиткерсә – изге бурычын үтәр, тагын да әҗерлерәк булыр.

Аллаһы Тәгалә шулай безгә хәлебездән килгәнчә салават әйтүне, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исеме искә алынганда аңа хәер-догада булуны насыйп әйләсен! Дәһшәтле Кыямәт көнендә иман әһелләренә вәгъдә ителгән Пәйгамбәребез шәфәгатенә ирешүләрне җиңеллек белән насыйп итсен!

Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез Мөхәммәд Әл-Мостафа хәзрәтләренең хәмед байрагы астында туплануыбызны насыйп итсә иде!

## Салават әйтү фазыйләтләре

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип әйткәне китерелә:

«Кем (бер тапкыр) салават әйтсә, Аллаһы аңа моның өчен ун кат рәхмәтен бирер»[1].

«Кем миңа бер салават әйтсә, Аллаһы Тәгалә аңа ун салават әйтер, ун хатасын сөртер һәм аны ун дәрәҗәгә күтәрер»[2].

«(Бүтәннәрдән) ешрак салават әйткән кешеләр Ахирәт көнендә миңа башкалардан якынрак булыр»[3].

«Хакыйкатьтә, җомга көне – иң хәерле көннәрегезнең берседер, шулай булгач, бу көндә миңа ешрак салават китерегез, чөнки салаватларыгыз миңа китерелеп күрсәтелер». Кешеләр: «Әй, Аллаһының Расүле, син

[1] Имам Мөслим, «Саләт» 70; имам Әт-Тирмизи, «Витр», 21.

[2] Имам Ән-Нәсаи хәдисләр җыентыгыннан.

[3] Имам Әт-Тирмизи, «Витр», 21

инде туфракка әйләнгәч, ничек итеп без кылган салаватлар үзеңә китереп күрсәтелер», – дип сорадылар. Шуннан соң Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Хактыр ки, иң кодрәтле һәм бөек булган Аллаһы пәйгамбәрләрнең җәсәден җир өчен харам кылды»[1]. «Аның янында мине искә алган чагында салават китермәгән кешене түбәнсетелү көтсен!»[2]

## Салават әйтү файдалары

Салават әйтү – догаларыбыз кабул булуына сәбәп ул.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дога кылыр алдыннан, иң баштан Аллаһыга мактаулар әйтегез, аннары миңа салават һәм сәлам сүзләрен ирештерегез. Болардан соң үзегез теләгәнчә дога кылыгыз»[3], – дип әйткән.

Салават сүзләре: «Аллаһуммә салли галәә сәййидинәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәд».

Мәгънәсе: «Йә, Аллаһым, сәййидебез Мөхәммәдкә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) һәм аның гаиләсенә сәламеңне һәм рәхмәтеңне ирештер».

## Салават әйтүнең файдаларын карап узыйк

1. Аллаһының әмерен үтәү.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا

**«Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:56

1 Имам Әт-Тирмизи, «Витр», 21

2 Имам Әт-Тирмизи, «Дәгъват», 101

3 Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

2. Салават әйтү, Аллаһының рәхмәте белән, безнең гөнаһларыбызның кичерелүенә китерә.

Пәйгамбәребез: «Миңа бер салават әйтүче кешегә Аллаһы 10 салават әйтер, 10 гөнаһын ярлыкар һәм 10 дәрәҗәгә күтәрер», – дигән.

3. Кыямәт көнендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенә салаватлар әйткән кеше белән бергә булыр.

Ул: «Кыямәт көнендә кешеләр арасында миңа иң якыннары булып, миңа иң күп салаватлар һәм сәламнәр әйтүче булыр», – дигән.

4. Пәйгамбәребез әйтелгән сәламнәргә җавап кайтара.

Ул: «Әгәр кем дә булса миңа сәлам бирсә, мин ул кешенең сәламен кабул итә алсын өчен, Аллаһы Тәгалә миңа җанымны кайтарыр»[1], – дигән.

5. Шулай ук Расүлебезгә салаватлар әйтүче кешенең холкы күркәмләнә, ул начар гадәтләрдән арына, Аллаһының ризалыгына ирешә, ике дөнья бәхетенә лаек була һәм тормышына бәрәкәт иңә.

## Салават шәрифәләр

Бөтен мөселманнар салават шәрифәне бик күп итеп укырга тиеш. Салават шәрифәне күп укыган кеше бәла һәм афәтләрдән, кайгы-хәсрәттән һәм фәкыйрьлектән имин булыр, хәерле максатларга ирешер. Бигрәк тә җомга көннәрендә күп итеп уку яхшы.

Раббыбыз Коръәни Кәримдә иман вә ислам әһеленә Үзенең һәм фәрештәләренең Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйткәнне тантаналы хәлдә ачыклый, белгертә. Моның хакында югарыдагы аятьтә искә алынды.

Димәк, киресенчә эшләү Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аллаһы Тәгалә каршында булган дәрәҗәсенә әһәмият бирмәү белән бердер. Кем ул Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм? Күрше абыймы? Туганыбызмы? Танышыбызмы? Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә

[1] Имам Әбү Давыд, имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

сәлләм – барча галәмгә, кеше, җен кавеменә дөньялык мәшәкатьләреннән котылу юлын, шәйтан сукмакларына басмас өчен чараларын күрсәтеп калдыручы Пәйгамбәр кеше исемедер.

Кыямәт көнендә өммәтенең халкына шәфәгать кылып, башын сәҗдәдән күтәрмичә торучы Аллаһы колы исемедер. Белмибез дисәк, дөрес булмас. Ишетмәдек, дисәк тә, хак булмас. Бу сөйләү-язуларга, вәгазьләргә чукрак та игътибар бирәдер. Тик, күңелләрдә усаллык, явызлык хисләре булу сәбәпле, күрер күзләр күрмәсләр, ишетә торган колаклар ишетмәсләр. Күзләр күргуен күрерләр – тик күрсәләр дә, нәрсә икәнен аңламаслар. Ишетә торган колаклар ишетсәләр дә, ишеткәнгә игътибар бирмәгәч, ишетмәгән белән бер булырлар.

Газаплы, авыр, җәфа чиктерә торган нәрсә турында сүз бармый бит! Сүз ихлас күңел белән Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм өчен хәер-догада булу, аңа салават-сәлам әйтү турында бара. «Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәд» дип әйтүнең бер авырлыгы да юк. Тик күпләр, күңелләре кырыс булганга күрә, бу сүзләрне әйтә алмаслар. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе: «Мине искә алганда, үземә салават әйтмәс кешенең күңеле кырыстыр», – дип әйткән. Бүгенге көнне Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исеме китапларда, язмаларда язылганда бик күп очракларда янында «салләллаһу галәйһи вә сәлләм» дип язу урынына, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дәрәҗәсенә игътибар итмичә, «г.», «г-м», «с.г.в.с.», «с.л.г.м.» кыяфәтле кыскартмалар очрый. Кыямәт көнендә шәфәгатен өмет итеп, азаннар әйтелгән саен «вәрзүкъна шәфәгатәһү Йәүмәл-Кыйәмәһ» («вә Кыямәт көнендә безгә аның шәфәгатен насыйп әйлә!») дигәндә, Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм исеме янында «салләллаһу галәйһи вә сәлләм» җөмләсен язудан нәрсә өчен үз-үзебезне тыябыз соң? Кәгазь саклыйбызмы? Әллә буяунымы? Бәлки бу нәрсә ялкаулыктан килеп чыгадыр? «Белмәдем, белмәдек» диючеләр булса, киләчәктә болай эшләүдән сак булсагыз иде.

## Расүлебезгә салават әйтүнең мөһимлеге

Раббыбыз әманәткә биргән нәрсәләрне ияләренә кайтаруны, әманәт үтәүне таләп итә, әманәткә хыянәт кылудан катгый хәлдә кисәтә. Шул әманәт дигән нәрсәләрнең берсе – дөньяларга Аллаһы Тәгаләнең Үз рәхмәтеннән күндерелгән Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә салават әйтү булыр.

Салават әйтүнең фазыйләтләре турында күп сөйләнә. Тик без әманәт үтәүдә күбесенчә гафил булып калабыз. Шул мәсьәләгә янә кайтып, гакыл ияләренең игътибарын җәлеп итәргә булдык. Аллаһы Тәгалә бу эштә безгә иң олы ярдәмче, иң олы киңәшче булса иде! Рувәйфәгъ бине Сәбит Әл-Әнсаридән риваять ителгәнчә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем дә кем «Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә әнзилһүл-мәкъгадәл-мүкаррабә гыйндәкә йәүмәл-кыйәмәһ» (мәгънәсе: Йә Аллаһым! Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватың булса иде! Һәм Син аны Кыямәт көнендә Үзеңә якынайтылган хөрмәтле дәрәҗәгә ирештерсәң иде!) дип әйтсә, аңа – минем шәфәгатем тиеш булыр», – дигән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгаләнең каршында олы дәрәҗәгә, Мәками мәхмүдкә ирешсә иде, дип без һәр азан әйтелгән саен дога кылабыз. Безнең дога кылуларыбыз, иншәАллаһ, бушка китмәс.

«Кыямәт көнендә миңа иң якыныгыз – үземә күпләп салават әйтүчегез булыр!» – дигән Расүли Әгъзам. Хәзрәти Гали радыяллаһу ганһенең риваятендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исемен ишетеп тә, аңа салават-сәлам әйтмәүче саранның сараны булыр, дигән мәгънәдә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләрен тапшырып калдырылган.

Хәзрәти Әбү Һөрайра риваяте буенча бу кисәтү: «Хур булсын шул кеше, кем дә кем мине искә алу белән үземә салават әйтмәсә», – дип яңгырый.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм исемен «Мөхәммәд» дип кенә, ягъни «Пәйгамбәребез Мөхәммәд», «Расүлебез Мөхәммәд» дип әйтмичә сөйләшү, Расүлебезнең дәрәҗәсенә карата илаһи әмерне үтәмәү була.

Шәех яки ишан-хәзрәт Габдулла Сираҗеддин «Пәйгамбәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтү» дигән китабында салават әйтә торган вакытлардан иң хәерлеләренең егермесен санап күрсәтә. Ул 20 төрле вакытлар түбәндәгеләрдер:

1. Азан әйтеп бетергәч, азан догасыннан соң.

2. Дога кылганда салаватны доганың башында, уртасында һәм ахырында әйтү.

3. Мәчеткә кергәндә.

4. Бер мөселман икенче берәү белән очрашканда.

5. Берәр мәҗлескә җыелганда.

6. Берәр язуда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм исемен язудан соң.

7. Һәр хәерле сүз, фикер әйткәндә.

8. Вәгазь сөйләгәндә, дәрес укыганда.

9. Көннең башында һәм ахырында.

10. Йокы килгән вакытта.

11. Төнлә йокыдан торып, төнге намазларга басканда.

12. Колаклар тонган вакытта.

13. Хәдис-шәриф онытылганда.

14. Салаватлар әйтүдән соң.

15. Коръәнне хәтем итүдән соң.

16. Гамь, хәсрәт вакытында.

17. Берәр теләк-хаҗәт булып дога кылганда.

18. Никах хотбәсен укыганда.

19. Җомга көнендә һәм кичәсендә.

20. Хаҗ гамәлләрен үтәгәндә.

Әлбәттә, салават бу 20 вакытта гына әйтелер дә, башка чакта әйтелмәс дигән сүз түгел. Бу 20 урын салават әйтүгә бик хөрмәтле булган вакытлар гына.

## Җомга көн салаватлары

Җомга хотбәсенең икенче өлеше (хотбә-и сәния) укылганда, имам: «Йә әййүһәл-ләҙинә әмәнүү саллүү гәләйһи вә сәллимүү тәслимән» дип әмер итә. «Ий, сез, иман китереп инанучылар! Шушы җомгада хазир булучылар! Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтегез һәм сәламнәр белән сәламләгез, аның өчен дога кылыгыз!» – дигәч, әлбәттә, җомгада катнашучы бәндә күңеленнән салават әйтергә тиеш. Әгәр үзеңне иман әһеле дип исәплисең икән, Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтә! Тик бер әмерне үтәп, икенчесен онытма! Күршеңә «сөйләгәнне тыңла» дип әйтсәң дә, өеңә җомгасыз яки җомга савабына ирешмичә яки аны югалтып кайтып китүең бар. Шуңа күрә бу очракта салават күңелдән әйтелергә тиеш.

Салават әйтүнең дәрәҗәсе менә шул аятьтә күренеп тора.

Әш-Шибли радыяллаһу ганһедән болай дип риваять ителгән, ул: «Күршеләремнән бер ир үлгәч, мин аны төшемдә күрдем һәм хәле хакында сораштым. Ул миңа: «Ий Шибли! Минем башымнан олы куркулар узды! Миңа сорау бирелде дә, минем телем аннан тетрәнеп бәйләнде, Минем яныма, ике фәрештә килде дә, берсе мине газапларга омтылды. Шулвакыт янымда бер бик матур зат пәйда булды. Минем андый матур йөзле затны беркайчан да күргәнем булмады. Ул фәрештә белән минем арага кереп басты. Мин аннан: «Син кем?»– дип сорадым. Миңа үзенең дәлилен бәян иткәннән соң, ул: «Мин – фәрештә. Аллаһы мине Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтү савабыннан яратты, ә син Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватны күп әйтә идең. Шунлыктан,

Аллаһы рөхсәте белән мин сине барлык кайгылардан һәм җәһәннәм уты газабыннан азат итәрмен. Мин сине җәннәткә кертмичә калдырмам һәм синнән аерылмам», – дип әйтте», – дигән.

Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Муса галәйһиссәләмгә: «Ий Муса! Әгәр телең – сүземә, карашың нуры – күземә, ишетүем – колагыңа якынрак булуын теләсәң, дустым Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватны күп әйт!» – дип вәхи кыла.

*«Догалык» китабыннан*

# Хәдис

# Кояш һәм ай тотылу бүлеге

كتابُ الكُسُوف

312

عَنْ أَبِي بَكْرَةَ: إِنَّ الشَّمْسَ وَالقَمَرَ لَا يَنْكَسِفَانِ لِمَوْتِ أَحَدٍ، فَإِذَا رَأَيْتُمُوهُمَا، فَصَلُّوا، وَادْعُوا حَتَّى يُكْشَفَ مَا بِكُمْ. إِنَّ اللَّهَ تَعَالَى يُخَوِّفُ بِهِمَا عِبَادَهُ

Әбү Бәкра радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Көннәрдән бер көнне без Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында булганда кояш тотыла башлады. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тиз генә үз урыныннан торды һәм, өстендәге чапанын өстерәп, мәчеткә кереп китте. Без дә мәчеткә кердек. Кояш яңадан күренгәнче, ул безнең белән ике рәкәгать намаз укыды. Укып бетергәч: «Кояш яки ай тотылуы кемнең дә булса үлүе сәбәпле булмый. Әгәр дә сез шундый хәлне күрсәгез, намаз укып, сезнең белән нәрсә булганы аңлашылганчы дога кылыгыз», – диде.

313

عَنِ المغِيرَةِ بْنِ شُعْبَةَ: إِنَّ الشَّمْسَ وَالقَمَرَ لَا يَنْكَسِفَانِ لِمَوْتِ أَحَدٍ وَلَا لِحَيَاتِهِ، فَإِذَا رَأَيْتُمْ فَصَلُّوا، وَادْعُوا اللَّهَ

Могыйра бине Шөгъбә радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең улы Ибраһим үлгән көнне кояш тотыла. Кешеләр: «Бу Ибраһимның үлеме сәбәпле булды», – дип сөйли башладылар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөреслектә, кояш яки ай тотылуы кемнеңдер үлеме яки дөньяга килүе белән бәйле түгел. Әгәр кояш яки айның тотылуын күрсәгез, намаз укып, Аллаһыга дога кылыгыз», – диде.

314

عَنْ عَائِشَةَ: إِنَّ الشَّمْسَ وَالقَمَرَ آيَتَانِ مِنْ آيَاتِ اللَّهِ، لَا يَخْسِفَانِ لِمَوْتِ أَحَدٍ وَلَا لِحَيَاتِهِ، فَإِذَا رَأَيْتُمْ ذَلِكَ، فَادْعُوا اللَّهَ، وَكَبِّرُوا وَصَلُّوا وَتَصَدَّقُوا. ثُمَّ قَالَ: يَا أُمَّةَ مُحَمَّدٍ وَاللَّهِ مَا مِنْ أَحَدٍ أَغْيَرُ مِنَ اللَّهِ أَنْ يَزْنِيَ عَبْدُهُ أَوْ تَزْنِيَ أَمَتُهُ، يَا أُمَّةَ مُحَمَّدٍ وَاللَّهِ لَوْ تَعْلَمُونَ مَا أَعْلَمُ لَضَحِكْتُمْ قَلِيلًا وَلَبَكَيْتُمْ كَثِيرًا

Гайшә радыяллаһу ганһәдән тапшырыла: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм исән чакта кояш тотылды һәм ул башка кешеләр белән бергә намазга керește. Башта ул бик озак итеп басып торды, аннары рөкүгъ кылды һәм рөкүгъта бик озак басып торды, аннан соң күтәрелеп, тагын озак итеп, ләкин беренчесенә (рөкүгъка киткәнче басып торуга) караганда кыскарак итеп басып торды, аннары ике тапкыр сәҗдә кылды һәм шул хәлдә озак итеп торды. Аннары ул беренчесе кебек итеп икенче рәкәгатьне дә үтәде. Ә кояш күренгәч, ул намаз укудан туктады һәм кешеләргә вәгазь белән мөрәҗәгать итте: «Кояш һәм ай тотылу – Аллаһы могҗизаларының берседер һәм алар кемнеңдер үлеме яки дөньяга килүе сәбәпле булмыйлар. Әгәр дә сез кояш яки ай тотылганын күрсәгез, Аллаһыны искә төшерегез, «Аллаһү әкбәр!» – дип әйтегез, намаз укыгыз һәм садака бирегез!» – диде. Шуннан соң ул: «Йә Мөхәммәднең өммәте! Аллаһы белән ант итәм, колы зина кылганны күреп, Аллаһы кичергән кадәр көнчелекне[1] беркем дә кичерми! Йә Мөхәммәднең өммәте! Әгәр дә сез мин белгәнне белсәгез, азрак көлеп, күбрәк елар идегез!» – дип өстәде.

[1] Аллаһы хакында «көнчелек кичерә» дип әйтүне турыдан-туры аңларга ярамый. Галимнәр аңлатуынча, монда Аллаһының риза булмавы һәм ул гөнаһны кылучыга җәза бирергә теләве хакында сүз бара («Тәнзих» Бине Җәмәгә).

315

عَنْ عَائِشَةَ: هُمَا آيَتَانِ مِنْ آيَاتِ اللَّهِ، لَا يَخْسِفَانِ لِمَوْتِ أَحَدٍ وَلَا لِحَيَاتِهِ، فَإِذَا رَأَيْتُمُوهُمَا فَافْزَعُوا إِلَى الصَّلَاةِ ونُودِيَ إِنَّ الصَّلَاةَ جَامِعَةٌ

Гайшә радыяллаһу ганһәдән тапшырыла: «Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм исән чакта кояш тотылды. Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм мәчеткә кереп китте, кешеләр дә аның артына тезелеп бастылар. Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм тәкбир әйтте һәм бик озак итеп Коръән укыды. Шуннан соң ул кабат тәкбир әйтеп, бик озак итеп рөкүгъ кылды. «Сәмигәллаһу лимән хәмидәһ», – дип тураеп баскач, ул тагын Коръән укыды, ләкин беренчесенә караганда кыскарак тотты. Шуннан соң ул кабат тәкбир әйтеп, тагын озак итеп, ләкин беренчесенә караганда кыскарак итеп, рөкүгъта басып торды. «Сәмигаллаһү лимән хәмидәһ», – дип тураеп баскач, ул: «Раббәнә ләкәл хәмде», – дип сәҗдәгә китте. Икенче рәкәгатьне дә ул нәкъ шулай үтәде. Шул рәвешле ул дүрт сәҗдәле дүрт рәкәгать намаз укыды. Ул намазын укып бетергәнче үк кояш тотылуы тәмамланды. Шуннан соң Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм торып басты һәм, Аллаһыга мактау сүзләре әйтеп, болай диде: «Дөреслектә, кояш һәм ай – Аллаһы Тәгаләнең ике галәмәте. Алар кемнеңдер үлеме яки дөньяга килүе сәбәпле булмыйлар. Шуңа күрә, әгәр дә сез кояш яки ай тотылганын күрсәгез, намаз укырга ашыгыгыз!»

317

عَنْ عَبْدِ اللَّهِ بْنِ عَبَّاسٍ: انْخَسَفَتِ الشَّمْسُ عَلَى عَهْدِ رَسُولِ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ، فَصَلَّى رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ، فَقَامَ قِيَامًا طَوِيلًا نَحْوًا مِنْ قِرَاءَةِ سُورَةِ البَقَرَةِ، ثُمَّ رَكَعَ رُكُوعًا طَوِيلًا، ثُمَّ رَفَعَ، فَقَامَ قِيَامًا طَوِيلًا وَهُوَ دُونَ القِيَامِ الأَوَّلِ، ثُمَّ رَكَعَ رُكُوعًا طَوِيلًا وَهُوَ دُونَ الرُّكُوعِ الأَوَّلِ، ثُمَّ سَجَدَ، ثُمَّ قَامَ قِيَامًا

طَوِيلًا وَهُوَ دُونَ القِيَامِ الأَوَّلِ، ثُمَّ رَكَعَ رُكُوعًا طَوِيلًا وَهُوَ دُونَ الرُّكُوعِ الأَوَّلِ، ثُمَّ رَفَعَ، فَقَامَ قِيَامًا طَوِيلًا وَهُوَ دُونَ القِيَامِ الأَوَّلِ، ثُمَّ رَكَعَ رُكُوعًا طَوِيلًا وَهُوَ دُونَ الرُّكُوعِ الأَوَّلِ، ثُمَّ سَجَدَ، ثُمَّ انْصَرَفَ وَقَدْ تَجَلَّتِ الشَّمْسُ، فَقَالَ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: «إِنَّ الشَّمْسَ وَالقَمَرَ آيَتَانِ مِنْ آيَاتِ اللَّهِ، لَا يَخْسِفَانِ لِمَوْتِ أَحَدٍ وَلَا لِحَيَاتِهِ، فَإِذَا رَأَيْتُمْ ذَلِكَ، فَاذْكُرُوا اللَّهَ. إِنِّي رَأَيْتُ الجَنَّةَ، فَتَنَاوَلْتُ عُنْقُودًا، وَلَوْ أَصَبْتُهُ لَأَكَلْتُمْ مِنْهُ مَا بَقِيَتِ الدُّنْيَا، وَأُرِيتُ النَّارَ، فَلَمْ أَرَ مَنْظَرًا كَالْيَوْمِ قَطُّ أَفْظَعَ، وَرَأَيْتُ أَكْثَرَ أَهْلِهَا النِّسَاءَ». قَالُوا بِمَ يَا رَسُولَ اللَّهِ؟ قَالَ: بِكُفْرِهِنَّ. قِيلَ: يَكْفُرْنَ بِاللَّهِ؟ قَالَ: يَكْفُرْنَ العَشِيرَ، وَيَكْفُرْنَ الإِحْسَانَ، لَوْ أَحْسَنْتَ إِلَى إِحْدَاهُنَّ الدَّهْرَ كُلَّهُ، ثُمَّ رَأَتْ مِنْكَ شَيْئًا قَالَتْ: مَا رَأَيْتُ مِنْكَ خَيْرًا قَطُّ

Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Көннәрдән бер көнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм исән чакта кояш тотылды һәм ул намаз укырга кереште. Башта ул «Әл-Бәкара» сүрәсен укып чыгарлык вакыт бик озак басып торды. Аннары озак итеп рөкүгъ кылды. Аннары басты һәм тагын бик озак итеп, ләкин беренчесенә караганда кимрәк вакыт басып торды. Аннан соң рөкүгъ кылды һәм беренчесенә караганда тизрәк турайды. Аннары сәҗдә кылды, аннары беренчесенә караганда кимрәк вакыт басып торды. Моннан соң ул тагын озак итеп рөкүгъ кылды. Аннары турайды һәм беренчесенә караганда кимрәк вакыт басып торды. Аннары тагын рөкүгъ һәм сәҗдә кылды. Кояш кабат күренә башлагач кына ул намазын укып бетерде. Шуннан соң ул: «Кояш һәм айның тотылуы – Аллаһы Тәгаләнең ике галәмәте. Алар кемнеңдер үлеме яки дөньяга килүе сәбәпле булмый. Әгәр дә сез кояш яки айның тотылуын күрсәгез, Аллаһыны искә алыгыз», – диде. Кешеләр: «Йә Аллаһының Расүле! Без синең нәрсәгәдер үрелгәнеңне һәм аннан соң артка чигенгәнеңне күр-

дек», – диделәр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мин җәннәтне күрдем һәм анда үскән бер тәлгәшне өзеп алырга теләдем. Әгәр мин аны өзеп ала алган булсам, һичшиксез, сез Кыяматкә кадәр шул җимешләр белән туклана алган булыр идегез. Шулай ук миңа җәһәннәм күрсәтелде. Минем моннан да куркыныч нәрсә күргәнем юк иде. Мин җәһәннәмдәге кешеләрнең күбесе хатын-кызлар икәнен күрдем», – дип җавап бирде. Кешеләр: «Ни өчен?» – дип сорадылар. Ул: «Чөнки алар шөкер итүчеләрдән булмадылар», – диде. Кешеләр: «Алар Аллаһыга шөкер итмәгәннәрме?» – дип сорады. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Андый кешеләр якыннарының яхшылыкларының кадерен белмиләр. Аларның берәрсенә гомереңбуе яхшылык эшләсәң һәм ул синнән берәр көнне үзенә ошамаган нәрсә күрсә, ул: «Синнән беркайчан да яхшылык күргәнем булмады!» – дип әйтер», – диде.

318

عَنْ أَبِي مُوسَى: هَذِهِ الآيَاتُ الَّتِي يُرْسِلُ اللَّهُ، لَا تَكُونُ لِمَوْتِ أَحَدٍ وَلَا لِحَيَاتِهِ، وَلَكِنْ يُخَوِّفُ اللَّهُ بِهِ عِبَادَهُ، فَإِذَا رَأَيْتُمْ شَيْئًا مِنْ ذَلِكَ، فَافْزَعُوا إِلَى ذِكْرِهِ وَدُعَائِهِ وَاسْتِغْفَارِهِ

Әбү Муса радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Бер көнне кояш тотылды. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Кыямәт көне җитте дип уйлап, шунда ук сикереп торып басты һәм мәчеткә кереп китте. Шуннан соң ул элек кылмаган рәвештә бик озын кыямлы, бик озын рөкүгъლы һәм бик озын сәҗдәле намаз укыды. Намаздан соң ул: «Болар – Аллаһы Тәгалә җибәргән галәмәтләр. Беркемнең дә үлеме дә, дөньяга килүе дә моңа сәбәп була алмый. Ләкин Аллаһы Тәгалә алар ярдәмендә колларын куркыта. Ул галәмәтләрнең берсен күрсәгез, Аллаһыны искә алырга ашыгыгыз, Аңа дога белән мөрәҗәгать итегез һәм истигъфар сорагыз».

# Намазны кыскарту бүлеге

## كِتَابُ تَقْصِيرِ الصَلاة

319

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: لَا يَحِلُّ لِامْرَأَةٍ تُؤْمِنُ بِاللَّهِ وَاليَوْمِ الآخِرِ أَنْ تُسَافِرَ مَسِيرَةَ يَوْمٍ وَلَيْلَةٍ لَيْسَ مَعَهَا حُرْمَةٌ

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Аллаһыга һәм Кыямәт көненә ышанган хатын-кыз бер көн һәм бер төн дәвам иткән сәфәргә иреннән һәм туганыннан тыш чыгарга тиеш түгел», – дигән».

320

عَنْ عِمْرَانَ بْنِ حُصَيْنٍ: إِنْ صَلَّى قَائِمًا فَهُوَ أَفْضَلُ وَمَنْ صَلَّى قَاعِدًا، فَلَهُ نِصْفُ أَجْرِ القَائِمِ، وَمَنْ صَلَّى نَائِمًا، فَلَهُ نِصْفُ أَجْرِ القَاعِدِ

Гыймран бине Хосайни радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Үз вакытында мин бер авырудан интегә идем, шуңа күрә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән намазын утырып укырга мәҗбүр булган кешенең хәле хакында сорадым. Ул: «Намазны баскан килеш укысаң яхшырак. Утырып укучы басып укучының ярты савабын, ә ятып укучы утырып укучы кешенең ярты савабын алыр», – диде».

# Тәһәҗҗөд китабы[1]

كِتَابُ التَّهَجُّدِ

321

عَنْ ابْن عَبَّاسٍ: اللَّهُمَّ لَكَ الحَمْدُ أَنْتَ قَيِّمُ السَّمَوَاتِ وَالأَرْضِ وَمَنْ فِيهِنَّ، وَلَكَ الحَمْدُ لَكَ مُلْكُ السَّمَوَاتِ وَالأَرْضِ وَمَنْ فِيهِنَّ، وَلَكَ الحَمْدُ أَنْتَ نُورُ السَّمَوَاتِ وَالأَرْضِ وَمَنْ فِيهِنَّ، وَلَكَ الحَمْدُ أَنْتَ مَلِكُ السَّمَوَاتِ وَالأَرْضِ، وَلَكَ الحَمْدُ أَنْتَ الحَقُّ وَوَعْدُكَ الحَقُّ، وَلِقَاؤُكَ حَقٌّ، وَقَوْلُكَ حَقٌّ، وَالجَنَّةُ حَقٌّ، وَالنَّارُ حَقٌّ، وَالنَّبِيُّونَ حَقٌّ، وَمُحَمَّدٌ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ حَقٌّ، وَالسَّاعَةُ حَقٌّ، اللَّهُمَّ لَكَ أَسْلَمْتُ، وَبِكَ آمَنْتُ، وَعَلَيْكَ تَوَكَّلْتُ، وَإِلَيْكَ أَنَبْتُ، وَبِكَ خَاصَمْتُ، وَإِلَيْكَ حَاكَمْتُ، فَاغْفِرْ لِي مَا قَدَّمْتُ وَمَا أَخَّرْتُ، وَمَا أَسْرَرْتُ وَمَا أَعْلَنْتُ، أَنْتَ المُقَدِّمُ، وَأَنْتَ المُؤَخِّرُ، لَا إِلَهَ إِلَّا أَنْتَ – أَوْ: لَا إِلَهَ غَيْرُكَ وَلَا حَوْلَ وَلَا قُوَّةَ إِلَّا بِاللَّهِ

Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм төнлә тәһәҗҗөд намазына торгач: «Аллаһым! Сиңа мактау булсын. Син – күкләр һәм җир, һәм анда булган бөтен нәрсәнең Раббысы һәм Хакиме. Бөтен мактау Сиңадыр. Син күктәгеләрнең һәм җирдәгеләрнең Нурысың. Мактау Сиңадыр. Син – күкләрнең һәм җирнең Патшасы. Сиңа мактау булсын. Син Хаксың, вәгъдәң хактыр, Ахирәттә Сине күрә алуыбыз хактыр. Сүзең хактыр, җәннәт хактыр, җәһәннәм хактыр, Пәйгамбәрләр хактыр вә Мөхәммәд хактыр, Кыямәт хактыр.

[1] Төнлә укыла торган өстәмә нәфел намаз.

Аллаһым! Сиңа тапшырылдым. Сиңа инандым. Сиңа тәвәккәл иттем. Сиңа гына тәүбә итәм. Синең ризалыгың белән генә бәхәсләр алып барам. Сине генә Хаким иттем. Раббым! Кылган һәм кылыначак бөтен гөнаһларымны гафу ит. Яшерен һәм ачык кылган бөтен гөнаһларымны кичер, алга үткәргән дә – Синсең, артка калдырган да – Синсең. Синнән башка илаһ юк, Аллаһым! Синнән башка көч вә куәт иясе беркемдә юк, Раббым!

(Аллааһүммә ләкәл-хәмдү, әнтә кайййимүс-сәмәәвәәти вәл-әръдый вә мән фииһиннә, вә ләкәл-хәмдү ләкә мүлкүс-сәмәәвәәти вәл-әръдый вә мән фииһиннә вә ләкәл-хәмдү әнтә нуурус-сәмәәвәәти вәл-әръдый вә мән фииһиннә вә ләкәл-хәмдү әнтә мәликүс-сәмәвәәти вәл-әръдый, вә ләкәл-хәмдү әнтәл-хәкку вә вәгъдүкәл-хәкку вә ликаа-үкә хәккун вә каулүкә хәккун вәл-җәннәтү хәккун вән-нәәрү хәккун вән-нәбийййүнәә хәккун вә мүхәммәдүн хәккун вәс-сәәгатү хәккун. Аллааһүммә ләкә әсләмтү вә бикә әәмәнтү вә галәйкә тәвәккәлтү вә иләйкә әнәбтү вә бикә хаасамтү вә иләйкә хәәкәмтү фәгъфирлии мәә каддәмтү вә мәә әххартү вә мәә әсрартү вә мәә әгъләнтү әнтәл-мүкаддимү вә әнтәл-мүәххыйру вә ләә иләәһә илләә әнтә әү ләә иләәһә гайрукә, вә ләә хәүлә вә ләә куввәтә илләә билләәһ!)», – дип дога кыла иде.

322

عَنْ ابْن عُمَرَ: نِعْمَ الرَّجُلُ عَبْدُ اللّٰهِ، لَوْ كَانَ يُصَلِّي مِنَ اللَّيْلِ

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм исән чакта берәрсе төш күрсә, аның янына килеп, төшен аңа сөйли иде. Мин дә төш күргән идем һәм аны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сөйләп бирергә өметләндем. Мин әле яшь идем һәм кайчакта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәчетендә йоклый кала идем. Төшемдә мин ике

фәрештәне күрдем, алар мине җәһәннәмгә илттеләр. Җәһәннәмнең ике мөгезе бар иде һәм ул кое диварлары сыман диварлар белән уратып алынган иде. Җәһәннәмдә мин үземә таныш булган кешеләрне очраттым. Шуннан соң мин башка фәрештә белән очраштым, һәм ул миңа: «Син курыкмасаң да була», – диде. Бу төшне мин Хафсага сөйләдем, Хафса аны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сөйләгән. Ул: «Габдулла бине Гомәр – бик яхшы кеше, ләкин аның өчен төнлә намаз укуы хәерле булыр», – дип әйтте.  Шул вакыйгадан соң Ибне Гомәр төнлә бик аз йоклап, тәһәҗҗөд намазын укый торган булды».

323

عَنْ عَلِيّ بْن أَبِي طَالِبٍ: أَلَا تُصَلِّيَانِ؟ {وَكَانَ الإِنْسَانُ أَكْثَرَ شَيْءٍ جَدَلًا} [الكهف: ٥٤]

Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Төннәрнең берсендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безнең өебезгә килеп, мине һәм кызы Фатыйманы йокыбыздан уятып: «Әллә сез тәһәҗҗөд намазы укымыйсызмы?» – дип сорады. Мин: «Йә Расүлүллаһ! Безнең җаннарыбыз Аллаһы кулында, әгәр Ул безне уятырга теләсә, уятыр», – дидем. Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: **«Әмма кеше – [бушка] сүз көрәштерергә иң хирысы»**[1], – аятен укый-укый безнең яннан чыгып китте».

324

عَنْ المغِيرَة: أَفَلَا أَكُونُ عَبْدًا شَكُورًا

Могыйра радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Гадәттә, төнге тәһәҗҗөд намазында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм

1 «Әл-Кәһф / Мәгарә», 18:54.

шулкадәр озак басып тора иде, хәтта табаннары һәм аяклары шешенеп бетә торган булдылар. Аннан бу хакта сорагач, ул: «Әллә миңа Аллаһының шөкер итүче колларыннан булырга кирәк түгелме?» – дип җавап бирә иде.

325

عَنْ عَبْد اللَّهِ بْن عَمْرِو بْنِ العَاصِ: أَحَبُّ الصَّلَاةِ إِلَى اللَّهِ صَلَاةُ دَاوُدَ عَلَيْهِ السَّلَامُ، وَأَحَبُّ الصِّيَامِ إِلَى اللَّهِ صِيَامُ دَاوُدَ، وَكَانَ يَنَامُ نِصْفَ اللَّيْلِ وَيَقُومُ ثُلُثَهُ، وَيَنَامُ سُدُسَهُ، وَيَصُومُ يَوْمًا، وَيُفْطِرُ يَوْمًا

Габдулла бине Гамр бине Әл-Гас радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Нәфел намазлардан Аллаһының иң яраткан намазы Давыд галәйһиссәлам укыган намаз иде, ә иң яраткан нәфел уразасы – Давыд галәйһиссәлам тоткан ураза булды. Ул һәрчак төннең яртысын йоклый иде, аннан өчтән бер өлешен намаз укып үткәрә иде, аннан янә алтыдан бер өлешен тагын йоклап ала иде. Ә уразасын көнаралаш тотты».

326

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: يَعْقِدُ الشَّيْطَانُ عَلَى قَافِيَةِ رَأْسِ أَحَدِكُمْ إِذَا هُوَ نَامَ ثَلَاثَ عُقَدٍ يَضْرِبُ كُلَّ عُقْدَةٍ عَلَيْكَ لَيْلٌ طَوِيلٌ، فَارْقُدْ فَإِنِ اسْتَيْقَظَ فَذَكَرَ اللَّهَ، انْحَلَّتْ عُقْدَةٌ، فَإِنْ تَوَضَّأَ انْحَلَّتْ عُقْدَةٌ، فَإِنْ صَلَّى انْحَلَّتْ عُقْدَةٌ، فَأَصْبَحَ نَشِيطًا طَيِّبَ النَّفْسِ وَإِلَّا أَصْبَحَ خَبِيثَ النَّفْسِ كَسْلَانَ

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Сезнең берәрегез йоклап киткәч, шәйтан аның баш очында өч төен төйни, һәр төененә сугып ала һәм: «Төнең озак дәвам итәчәк, йокла, йокла!» – дип әйтә. Әгәр кеше, уянып китеп, Аллаһыны искә алса, төеннең берсе чишелер. Торып

тәһарәт алса, икенчесе дә чишелер. Тәһәҗҗөд намазын укыса, өченчесе дә чишелер. Һәм кеше иртә белән йокысы туеп, яхшы кәеф белән уяныр. Әгәр шулай эшләмәсә, йокысыннан начар кәефтә, хәлсезләнеп торыр».

327

عَنْ عَبْدِ اللَّهِ: بَالَ الشَّيْطَانُ فِي أُذُنِهِ

Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Көннәрдән бер көнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында бер кеше башка берәүне искә алды һәм: «Ул иртәнге намазга тормыйча, уянганчы йоклады», – дип әйтте. Моңа җавап итеп Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Шәйтан аның колагына хаҗәтен үтәде!» – дип әйтте.

328

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: يَنْزِلُ رَبُّنَا تَبَارَكَ وَتَعَالَى كُلَّ لَيْلَةٍ إِلَى السَّمَاءِ الدُّنْيَا حِينَ يَبْقَى ثُلُثُ اللَّيْلِ الآخِرِ يَقُولُ: مَنْ يَدْعُونِي، فَأَسْتَجِيبَ لَهُ مَنْ يَسْأَلُنِي فَأُعْطِيَهُ، مَنْ يَسْتَغْفِرُنِي فَأَغْفِرَ لَهُ

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Һәр төннең өченче өлеше җиткәч, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә күкнең аскы катына төшә[1]:

[1] Бу «төшү»не туры мәгънәдә өстән аска төшү буларак аңларга ярамый, чөнки Аллаһы Тәгалә физик җисем түгел, ул урын белән чикләнмәгән. Әүвәлге галимнәр бу мәгънәне тәфсир кылудан баш тартканнар. Мондый охшатулар [турыдан туры мәгънәдә аңлаганда] очраган хәдисләр хакында Әл-Әузагый, Мәлик, Суфьян Әс-Саури һәм Ләйс бине Сәгъдтән сораган булганнар. Алар: «Мондый хәдисләрне, Аллаһыны җисемләндермичә, ничек бар шулай кабул итегез», – дип әйткәннәр (Әл-Бәйхакый, «Сөнән әл-кубра», 3/3). Башка галимнәр «төшү» мәгънәсен аңлатырга тырышканнар. ИмамӘн-Нәвәви бу сүзгә ике төрле аңлатма китергән:
1. Мәлик бине Әнәс һәм башкаларның фикеренчә: «Аның рәхмәте, Аның әмерләре һәм Аның фәрештәләре төшә».
2. Дога кылучыларның догалары кабул булу һәм аларга карата булган Аллаһының рәхмәте буларак аңларга кирәк (Имам Мөслимнең «Сахих» җыентыгы шәрхе, 6/54).

«Кем Миңа дога белән мөрәҗәгать итә, җавап бирәм. Кем Миннән нәрсә дә булса сорый, Мин аңа сораганын бирәм. Кем Миннән истигъфар сорый, гөнаһларын кичерәм», – дип әйтә.

329

عَنْ أَبِي سَلَمَةَ بْنِ عَبْدِ الرَّحْمَنِ: أَنَّهُ سَأَلَ عَائِشَةَ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهَا، كَيْفَ كَانَتْ صَلَاةُ رَسُولِ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فِي رَمَضَانَ؟ فَقَالَتْ: «مَا كَانَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ يَزِيدُ فِي رَمَضَانَ وَلَا فِي غَيْرِهِ عَلَى إِحْدَى عَشْرَةَ رَكْعَةً يُصَلِّي أَرْبَعًا، فَلَا تَسَلْ عَنْ حُسْنِهِنَّ وَطُولِهِنَّ، ثُمَّ يُصَلِّي أَرْبَعًا، فَلَا تَسَلْ عَنْ حُسْنِهِنَّ وَطُولِهِنَّ، ثُمَّ يُصَلِّي ثَلَاثًا. قَالَتْ عَائِشَةُ: فَقُلْتُ: يَا رَسُولَ اللَّهِ أَتَنَامُ قَبْلَ أَنْ تُوتِرَ؟ فَقَالَ: يَا عَائِشَةُ، إِنَّ عَيْنَيَّ تَنَامَانِ وَلَا يَنَامُ قَلْبِي

Гайшә радыяллаһу ганһәдән болай дип сораганнары хакында риваять ителә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Рамазан аенда намазын ни рәвешле укый иде?» Ул: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Рамазан аенда да, башка айларда да төнлә унбер рәкәгатьтән күбрәк намаз укымый иде. Башта ул дүрт рәкәгать намаз кыла иде. Аларның никадәр күркәм һәм озак итеп кылынуы хакында миннән сорап та тормагыз. Шуннан соң тагын дүрт рәкәгать намаз укый иде. Аларның да никадәр күркәм һәм озак итеп кылынуы хакында миннән сорап та тормагыз. Шуннан соң ул янә өч рәкәгать намаз кыла иде», – дип җавап биргән. Гайшә радыяллаһу ганһә: «Көннәрдән бер көнне мин: «Йә Расүлуллаһ! Витрны укыр алдыннан син йоклап аласыңмы әллә?» – дип сорадым. Ул: «Гайшә, хакыйкатьтә, минем күзләрем йокласа да, йөрәгем йокламый!» – дип җавап бирде», – дип әйткән.

330

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: يَا بِلَالُ حَدِّثْنِي بِأَرْجَى عَمَلٍ عَمِلْتَهُ فِي الإِسْلَامِ، فَإِنِّي سَمِعْتُ دَفَّ نَعْلَيْكَ بَيْنَ يَدَيَّ فِي الجَنَّةِ. قَالَ: مَا عَمِلْتُ عَمَلًا أَرْجَى عِنْدِي: أَنِّي لَمْ أَتَطَهَّرْ طَهُورًا، فِي سَاعَةِ لَيْلٍ أَوْ نَهَارٍ، إِلَّا صَلَّيْتُ بِذَلِكَ الطُّهُورِ مَا كُتِبَ لِي أَنْ أُصَلِّيَ

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Көннәрдән бер көнне иртәнге намаз вакытында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Билалга: «Әй, Билал, Исламда иң зур өмет баглаган гамәлең хакында сөйлә! Дөреслектә, бүген төнлә мин җәннәттә үземнең алда синең аяк тавышларыңны ишеттем», – дип әйткән булган.

Билал радыяллаһу ганһе: «Таһарәт алган саен, төнлә булсынмы ул, көндезме, мин һәрчак Аллаһы насыйп иткән кадәр нәфел намазлары укыйм», – дип җавап биргән.

331

عَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ: مَا هَذَا الحَبْلُ؟ قَالُوا: هَذَا حَبْلٌ لِزَيْنَبَ فَإِذَا فَتَرَتْ تَعَلَّقَتْ، فَقَالَ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: لَا حُلُّوهُ لِيُصَلِّ أَحَدُكُمْ نَشَاطَهُ، فَإِذَا فَتَرَ فَلْيَقْعُدْ

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Көннәрдән бер көнне мәчеткә кергәч, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ике багана арасына бәйләп куелган бауны күреп алды һәм: «Бу нинди бау?» – дип сорады. Аңа: «Бу – Зәйнәпнең бавы. Намаз укудан тәмам арыгач, ул аңа тотынып тора», – дип җавап биргәннәр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Юк, бу бауны чишеп атыгыз. Һәркем көченнән

килгән кадәр намаз укысын, арый башласа, намаз укудан туктасын!» – дип әйткән.

332

عَنْ عَبْد اللَّهِ بْن عَمْرِو بْنِ العَاصِ: يَا عَبْدَ اللَّهِ، لَا تَكُنْ مِثْلَ فُلَانٍ كَانَ يَقُومُ اللَّيْلَ، فَتَرَكَ قِيَامَ اللَّيْلِ

Габдулла бине Гамр бине Әл-Гас радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм миңа: «Әй, Габдулла, элек төнлә намазлар укып та, соңыннан бу гамәленнән туктаган фәлән кеше кебек булма!» – дип әйтте.

333

عَن عُبَادَة بْنِ الصَّامِتِ: مَنْ تَعَارَّ مِنَ اللَّيْلِ، فَقَالَ: لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ، لَهُ المُلْكُ وَلَهُ الحَمْدُ، وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ، الحَمْدُ لِلَّهِ، وَسُبْحَانَ اللَّهِ، وَلَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ، وَاللَّهُ أَكْبَرُ، وَلَا حَوْلَ وَلَا قُوَّةَ إِلَّا بِاللَّهِ، ثُمَّ قَالَ: اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِي، أَوْ دَعَا، اسْتُجِيبَ لَهُ، فَإِنْ تَوَضَّأَ وَصَلَّى قُبِلَتْ صَلَاتُهُ

Гобәдә бине Әс-Самит радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Кем төнлә уянып: «Аллаһыдан башка илаһ юк, Аның тиңдәше юк, Ул бөтен нәрсәнең Хуҗасы, Аңа мактау булсын, Аның һәрнәрсәгә көче җитә (Ул һәрнәрсәгә кадир). Аллаһыга мактау булсын, Аллаһы һәрнәрсәдән пакь, Аллаһыдан башка илаһ юк! Аллаһы бөек, Аннан башка кодрәт иясе юк», – дип әйтсә, соңыннан: «Аллаһым, мине кичер!» – дисә яки башка бер дога белән мөрәҗәгать итсә, аның догасына җавап бирелер. Әгәр ул тәһарәт алып, намаз укыса, намазы кабул булыр.

(Ләә иләһә илләллааһү вәхдәһу ләә шәриикә ләһ, ләһүль-мүлкү вә ләһүл-хәмдү, вә һувә галәә күлли шәй-ин кадиир, әлхәмдүлилләһ вә сүбхәналлааһ, вә ләә иләһә илләллаһ вәллааһү әкбәр, вә ләә хәулә вә ләә куввәтә илләә билләһ. Аллаһуммәгъ-фирлии)».

334

عَنْ جابِر: إِذَا هَمَّ أَحَدُكُمْ بِالأَمْرِ فَلْيَرْكَعْ رَكْعَتَيْنِ مِنْ غَيْرِ الفَرِيضَةِ، ثُمَّ لِيَقُلْ: اللَّهُمَّ إِنِّي أَسْتَخِيرُكَ بِعِلْمِكَ، وَأَسْتَقْدِرُكَ بِقُدْرَتِكَ، وَأَسْأَلُكَ مِنْ فَضْلِكَ العَظِيمِ، فَإِنَّكَ تَقْدِرُ وَلَا أَقْدِرُ، وَتَعْلَمُ وَلَا أَعْلَمُ، وَأَنْتَ عَلَّامُ الغُيُوبِ، اللَّهُمَّ إِنْ كُنْتَ تَعْلَمُ أَنَّ هَذَا الأَمْرَ خَيْرٌ لِي فِي دِينِي وَمَعَاشِي وَعَاقِبَةِ أَمْرِي — أَوْ قَالَ: عَاجِلِ أَمْرِي وَآجِلِهِ — فَاقْدُرْهُ لِي، وَيَسِّرْهُ لِي، ثُمَّ بَارِكْ لِي فِيهِ، وَإِنْ كُنْتَ تَعْلَمُ أَنَّ هَذَا الأَمْرَ شَرٌّ لِي فِي دِينِي وَمَعَاشِي وَعَاقِبَةِ أَمْرِي — أَوْ قَالَ: فِي عَاجِلِ أَمْرِي وَآجِلِهِ — فَاصْرِفْهُ عَنِّي، وَاصْرِفْنِي عَنْهُ، وَاقْدُرْ لِي الخَيْرَ حَيْثُ كَانَ، ثُمَّ أَرْضِنِي به ، قَالَ: وَيُسَمِّي حَاجَتَهُ

Җәбир бине Габдулла радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә, Коръәннән теге яки бу сүрәне өйрәткән кебек, һәр эштә ничек истихара укырга кирәклеген өйрәтеп калдырды. Ул: «Әгәр берәр нәрсә эшләргә җыенсагыз, ике рәкәгать нәфел намазы укыгыз һәм: «Йә, Раббым, дөреслектә, мин Синнән Үз гыйлемең белән ярдәм итүеңне, кодрәтең белән миңа көч бирүеңне һәм Синең олуг рәхмәтеңне сорыйм. Дөреслектә, Синең кодрәтең бар нәрсәгә җитә, мин үзем генә (Синең кодрәтең булмаса) һичбер нәрсә эшли алмыйм. Син һәрнәрсәне беләсең, ә мин белмим. Дөреслектә, Син һәрбер яшерен нәрсәләрне беләсең. Йә, Аллаһы, әгәр бу эшемне динем, дөньям

һәм Ахирәтем өчен хәерле дип белсәң, аны миңа насыйп ит һәм ул эшне минем өчен мөбарәк кыл. Әгәр дә бу эшемне динем, дөньям һәм Ахирәтем өчен зарарлы һәм яман дип белсәң, ул эшне миннән һәм мине ул эштән азат ит. Кайда булсам да, миңа хәерле эшләрне насыйп ит. Дөреслектә, Синең көчең һәрнәрсәгә җитә.

(Аллааһүммә иннии әстәхыйрүкә бигыйльмикә вә әстәкъдирукә бикудратикә вә әс’әлүкә мин фәдликәл-газыйми фә’иннәкә тәкъдиру вә ләә әкъдиру вә тәгъләмү вә ләә әгъләмү вә әнтә галләәмүл-гуйүүб. Аллааһүммә ин күнтә тәгъләмү әннә һәәҙәәл-әмра хайрун лии фии диинии вә мәгаашии вә гаакыйбәти әмрии фәкдирһү лии вә йәссирһү лии ҫүммә бәәрик лии фииһ. Вә ин күнтә тәгъләмү әннә һәәҙәәл-әмра шәррун лии фии диинии вә мәгаашии вә гаакыйбәти әмрии фәсрифһү ганнии, вәсрифнии ганһү вәкъдир лил-хайра хәйсу кәәнә, суммә аръдыйни биһи)», – дип әйтегез.

Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәм сораган кеше нәрсә сораганын әйтсен», – дип өстәде.

335

عن عَبْدِ اللَّهِ المزَنِيُّ: صَلُّوا قَبْلَ صَلَاةِ المغْرِبِ. فِي الثَّالِثَةِ: لِمَنْ شَاءَ، كَرَاهِيَةَ أَنْ يَتَّخِذَهَا النَّاسُ سُنَّةً

Габдулла Әл-Мүзәни радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ике тапкыр: «Ахшам намазы алдыннан ике рәкәгать нәфел намазы укыгыз!» – дип кабатлады. Шуннан соң, кешеләр моны мәҗбүри үтәлергә тиешле сөннәт дип уйламасыннар өчен: «Кем тели», – дип өстәде.

# Мәккә (Әл-Харам мәчете) һәм Мәдинә (Пәйгамбәребез мәчете) мәчетләрендә намаз укуның өстенлеге хакындагы бүлек

كِتابُ فَضْلِ الصَلاةِ في مَسْجِدِ مَكَّة والمدينة

336

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: لَا تُشَدُّ الرِّحَالُ إِلَّا إِلَى ثَلَاثَةِ مَسَاجِدَ: المَسْجِدِ الحَرَامِ، وَمَسْجِدِ الرَّسُولِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ، وَمَسْجِدِ الأَقْصَى

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Өч мәчеттән кала, башка мәчетләр өчен ерак сәфәргә чыгу ярамый: Мәккәдәге Әл-Харам мәчете, Мәдинәдәге Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәчете һәм Кодыстагы Әл-Әкъса мәчете»[1].

337

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: صَلَاةٌ فِي مَسْجِدِي هَذَا خَيْرٌ مِنْ أَلْفِ صَلَاةٍ فِيمَا سِوَاهُ، إِلَّا المَسْجِدَ الحَرَامَ

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Әл-Харам мәчетендә укылган намаз башка мәчетләрдә укылган мең намаздан өстенрәк».

338

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: مَا بَيْنَ بَيْتِي وَمِنْبَرِي رَوْضَةٌ مِنْ رِيَاضِ الجَنَّةِ، وَمِنْبَرِي عَلَى حَوْضِي

[1] Ягъни, шушы өч мәчеттә кылынган намаз гына башка мәчетләрдә кылынган намазлардан аерым өстенлеккә ия. Шуңа күрә сәфәрнең максаты мәчеттә намаз уку гына булган очракта, шушы өч мәчеттән кала башка мәчетләр өчен ерак сәфәргә чыгу килешми.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Минем йортым белән Мәдинә мәчетендәге минбәрем арасында җәннәт бакчаларының берсе урнашкан, ә минем минбәрем минем чишмәм янында тора».

*«Зөбдәтел-Бохари» хәдисләр җыентыгыннан*

# Тәфсир

# Гозәер галәйһиссәлам кыйссасы

Гозәер бине Җәрва галәйһиссәламне Исраил уллары аеруча якын иткәннәр һәм яратканнар. Кабиләдәшләре халыкта онытылган Тәүратны яттан белгәнгә күрә аңа иман китергәннәр.

Гозәер галәйһиссәлам бер гасырлык гомере дәверендә берничә үлем һәм кабаттан терелү кичергән. Аллаһы Тәгалә аны йөз елга тормыштан мәхрүм иткән, ә соңыннан, кешеләр үлгәннән соң Раббыбызга ничек кайтасыларын күрсеннәр өчен, гаҗәеп рәвештә үз халкына кире кайтарган. Коръәни Кәримдә бу хакта түбәндәгеләр әйтелә:

أَوْ كَالَّذِي مَرَّ عَلَىٰ قَرْيَةٍ وَهِيَ خَاوِيَةٌ عَلَىٰ عُرُوشِهَا قَالَ أَنَّىٰ يُحْيِي هَٰذِهِ
اللَّهُ بَعْدَ مَوْتِهَا ۖ فَأَمَاتَهُ اللَّهُ مِائَةَ عَامٍ ثُمَّ بَعَثَهُ ۖ قَالَ كَمْ لَبِثْتَ ۖ قَالَ لَبِثْتُ
يَوْمًا أَوْ بَعْضَ يَوْمٍ ۖ قَالَ بَلْ لَبِثْتَ مِائَةَ عَامٍ فَانْظُرْ إِلَىٰ طَعَامِكَ وَشَرَابِكَ لَمْ
يَتَسَنَّهْ ۖ وَانْظُرْ إِلَىٰ حِمَارِكَ وَلِنَجْعَلَكَ آيَةً لِلنَّاسِ ۖ وَانْظُرْ إِلَى الْعِظَامِ كَيْفَ
نُنْشِزُهَا ثُمَّ نَكْسُوهَا لَحْمًا ۚ فَلَمَّا تَبَيَّنَ لَهُ قَالَ أَعْلَمُ أَنَّ اللَّهَ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ
قَدِيرٌ ﴿٢٥٩﴾

**«Яки нигезенә кадәр җимерелеп беткән авылдан үткән кеше турында [ишеттеңме?]. Ул: «Үлгәненнән соң Аллаһы моны ничек терелтер икән?» – дигән иде. Аллаһы [шул урында] йөз елга аның җанын алды, шуннан [йөз ел үткәч] терелткән иде. Ул [Аллаһы Тәгалә аңардан]: «[Син монда] Күпме [вакыт] тордың?» – дигәч, ул исә: «Бер көн яки көннең бер өлеше [кадәр аз бер вакыт] тордым», – дигән иде. Ул [Аллаһы Тәгалә]: «Түгел, син [биредә] йөз ел [үле килеш] тордың. Ашамлык һәм эчемлекләреңә кара, [күп вакыт үтүгә карамастан, алар бозы-**

**лып] үзгәрмәгәннәр. Инде [сөякләре черел һәм таралып ят- кан] ишәгеңә кара. [Безнең өстен көчебезне аңласыннар һәм] Сине кешеләр өчен бер билге [һәм гыйбрәт] итәргә дип [кире терелттек үзеңне]. [Хәзер] Сөякләрне ничек җыйганыбызны, шуннан соң аларга ит кундырганыбызны кара», – дигән иде. [Ишәге күз алдында терелгәнне күргәннән соң, Аллаһының кодрәте] Аңа күрсәтелгәч, ул: «Һичшиксез, Аллаһының [җанны алу белән терелтүне дә исәпкә алып] һәрнәрсәгә кодрәтле булганын [хәзер инде күреп тә] беләм», – диде».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:259

«Аллаһы Тәгалә әлеге шәһәрне тулысы белән юк иткәннән соң, аны ничек яңадан торгыза ала икән?» – дигән уйлар белән йөрүче кешене Гозәер галәйһиссәлам дип белерсез. Бу уйланулар һичнинди көферлек тә, динне кире кагу яки иман китерүгә шикләнү гамәле дә түгел, ә бәлки Аллаһының кодрәтен тулы рәвештә аңлау талпынышы булган. Чынлыкта, Гозәер галәйһиссәлам изге, гадел, тугры кеше булган. Бу фикерләре дә башына Нәвухознәсыр җимергән Кодыс хәрабәләре яныннан узган мәлдә килгән.

Нәвухознәсыр – Бабил патшасы. Аны Аллаһы Тәгалә Исраил улларына илаһи боерыклардан баш тарткан, пәйгамбәрнең нәсыйхәтләренә колак салмаган һәм золым кылганнары өчен җәза сыйфатында җибәргән. Чиксез гаскәргә ия булган патша, гаепсез кешеләрне үтереп Шамны һәм Иорданияне яулап алган, шулай ук Кодыс шәһәрен буйсындырган. Нәкъ менә аның тарафдарлары Әл-Әкъса мәчетен җимереп, Кодыс бакчаларын юкка чыгарганнар.

Шушы күренешләрне Гозәер галәйһиссәлам ишәк өстенә утырып күзәтеп барган. Кодыс җирлегенә килеп җиткәч, ул бер ташландык бакча янында туктаган, ишәгенең йөгән бушатып, агачка бәйләп куйган. Күз алдына хәрабәләр булып калган шәһәр, җимерек өйләр, таланган бакчалар

килеп баскан...

Арып һәм ачыгып, Гозәер галәйһиссәлам бераз инҗир һәм йөзем җыйган. Инҗирнең бер өлешен ашап, йөземнең суын сыгып эчеп, ул агач астына утырып, җимерелгән йортларга, начар хәлгә килгән юлларга һәм кеше сөякләренә карап, Аллаһы Тәгалә әлеге таланган һәм үле хәлгә килгән җирне ничек итеп терелтә алачак, дигән уйларга чумган. Әлеге уйлардан ул үзе дә сизмәстән йокыга киткән. Бу йокыдан ул үлем халәтенә күчкән: Аллаһы Тәгалә Гозәер галәйһиссәламне тормыштан мәхрүм иткән, әмма аның гәүдәсен һәм ашамлыкларын таркалудан саклаган, кешеләр һәм хайваннар күзеннән яшергән.

Йөз елдан соң Аллаһы Тәгалә Гозәер галәйһиссәламне янәдән терелткән. Әмма, күзләрен ачкач, билгеле, ул бу кадәр озак вакыт буе үле килеш ятуын аңламаган. Бары иртән генә ул үзенең йокыга киткәнен исенә төшергән, ә уянгач, кояшның әле баемаганын күргән. Шуңа да иртәдән кичкә кадәр йоклаганмын икән, дип нәтиҗә ясаган. Җитмәсә, аның өзеп алган инҗире һәм сыккан йөзем суы да бозылмаган булган.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

قَالَ لَبِثْتُ يَوْمًا أَوْ بَعْضَ يَوْمٍ ۖ قَالَ بَلْ لَبِثْتَ مِائَةَ عَامٍ فَانْظُرْ إِلَىٰ طَعَامِكَ وَشَرَابِكَ لَمْ يَتَسَنَّهْ ۖ وَانْظُرْ إِلَىٰ حِمَارِكَ وَلِنَجْعَلَكَ آيَةً لِلنَّاسِ ۖ وَانْظُرْ إِلَى الْعِظَامِ كَيْفَ نُنْشِزُهَا ثُمَّ نَكْسُوهَا لَحْمًا ۚ

**«[Син монда] Күпме [вакыт] тордың?» – дигәч, ул исә: «Бер көн яки көннең бер өлеше [кадәр аз бер вакыт] тордым», – дигән иде. Ул [Аллаһы Тәгалә]: «Түгел, син [биредә] йөз ел [үле килеш] тордың. Ашамлык һәм эчемлекләреңә кара, [күп вакыт үтүгә карамастан, алар бозылып] үзгәрмәгәннәр. Инде [сөякләре череп һәм таралып яткан] ишәгеңә кара. [Безнең өстен көчебезне аңласыннар һәм] Сине кешеләр өчен бер билге [һәм гыйбрәт]**

**итәргә дип [кире терелттек үзеңне]. [Хәзер] Сөякләрне ничек җыйганыбызны, шуннан соң аларга ит кундырганыбызны кара», – дигән иде».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:259

Ишәктән бары череп беткән сөякләр генә калуга карамастан, Аллаһы Тәгалә аны да терелткән. Бу хәл Гозәер галәйһиссәламнең күз алдында булган. Гаҗәпкә калып, ул болай дип әйткән:

فَلَمَّا تَبَيَّنَ لَهُۥ قَالَ أَعْلَمُ أَنَّ ٱللَّهَ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٖ قَدِيرٞ ﴿٢٥٩﴾

**«Һичшиксез, Аллаһының [җанны алу белән терелтүне дә исәпкә алып] һәрнәрсәгә кодрәтле булганын [хәзер инде күреп тә] беләм».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:259

Аллаһының кодрәтен дәлилләгән әлеге бөек күренешләрне күзәткәннән соң, Гозәер галәйһиссәлам үзенең ишәгенә атланып Кодыс шәһәренә юнәлгән. Шәһәргә керү белән, ул биредә барысы да үзгәреп беткәнен күргән. Каршыга чыккан кешеләр дә, йортлар һәм урамнар да, шәһәр биналары һәм юллар да аңа таныш булмаган. Бу вакытта Нәвухознәсыр үлгән, Фәләстыйн илбасарлардан азат ителгән, ә әсирлеккә төшкән кешеләр иреккә чыккан һәм кире кайткан булганнар. Шулай итеп, шәһәрдә янә тормыш кайный башлаган.

Гозәер галәйһиссәлам үзенең йорты урнашкан якка юнәлгән. Әмма бусагада аны карт, сукыр хатын-кыз каршы алган. Гозәер галәйһиссәлам аннан болай дип сораган:

– Гозәернең йорты кайда?

– Гозәернең йорты шушы була инде, әмма ул үзе моннан йөз ел элек югалды, ә мин – аның колы.

Гозәер галәйһиссәлам аңа болай дип әйткән:

– Гозәер мин булам инде ул.

Карчык, Гозәер белән булган хәлләрнең барысын да белгәч, хуҗасының бер генә сүзенә дә шикләнмичә, аның әйләнеп кайтуына шатланган. Элекке яшь һәм сәламәт вакытын кайтаруын сорап, хуҗасыннан Аллаһы Тәгаләгә дога белән мөрәҗәгать итүен үтенгән. Гозәер галәйһиссәламнең догасы кабул булган һәм карчыкның янәдән күзләре күрә башлаган.

Бу могҗиза хакында карт карчык Исраил улларына хәбәр итәргә һәм аларны Гозәер галәйһиссәлам белән таныштырырга ашыккан. Хатын-кызның сөйләгәннәренә берәү дә ышанмаган, чөнки алар Гозәер галәйһиссәламнең инде 118 яшь тулган чал сакаллы улын беләләр. Янәсе, улына 118 яшь булганда, әтисенә нибары кырык кына яшь була аламыни?! Шуңа да карамастан, әлеге ир-атның аркасында кара ярымай рәвешендәге тапны күргәч, кешеләрнең шик-шөбһәләре юкка чыккан – Гозәер галәйһиссәламдә нәкъ шундый миң булганын искә төшергәннәр.

Гозәер галәйһиссәлам үзенең кабиләдәшләрен кабаттан терелү могҗизасына инандырып кына калмаган, хәтерендә Тәүратны саклап калуы белән дә аларны шаккаттырган. Нәвухознәсыр патша Иерусалимны яулап алганда барлык китапларны юкка чыгарган, ә Гозәер галәйһиссәлам, йөз ел элек яшәгәнлектән, аны яттан белгән булган. Исраил уллары исә Гозәер галәйһиссәламнең әйләнеп кайтуына, күп еллар үтү сәбәпле, Изге Китапны хәтерләреннән җуеп өлгергәннәр. Гозәер галәйһиссәлам дога белән Аллаһыга мөрәҗәгать иткән, аның калебенә күктән нур төшкән. Ул онытылган Тәүратны искә төшергән һәм барча халык алдында аны күңелдән укый башлаган. Ләкин Гозәер галәйһиссәламнән барыбер шикләнүчеләр табылган. Шулар арасында бер карт булган. Ул карт болай дип әйткән:

– Минем бабам Тәүрат китапларының барысы да Нәвухознәсыр чыгарган җәнҗаллар вакытында юкка чыгуы хакында әйтте. Әмма Тәүратның бер данәсе сандыкка салына һәм тауга яшерелә. Аны табыйк

та, Гозәер галәйһиссәлам укыганнар белән чагыштырыйк.

Тәүратны тапканнар һәм халыкка Гозәер галәйһиссәламнең хаклыгына инанырга туры килгән: ул аларга төп-төгәл итеп Изге Китапны яттан укып биргән. Шулай итеп Исраиллеләрнең бер өлеше Гозәер галәйһиссәламгә иман китергән. Калганнары исә: «Гозәер – Аллаһының улы», – дип, адашу юлына басканнар. Бу турыда Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَقَالَتِ الْيَهُودُ عُزَيْرٌ ابْنُ اللَّهِ وَقَالَتِ النَّصَارَى الْمَسِيحُ ابْنُ اللَّهِ ۖ ذَٰلِكَ قَوْلُهُمْ بِأَفْوَاهِهِمْ ۖ يُضَاهِئُونَ قَوْلَ الَّذِينَ كَفَرُوا مِنْ قَبْلُ ۚ قَاتَلَهُمُ اللَّهُ ۚ أَنَّىٰ يُؤْفَكُونَ ﴿٣٠﴾

> **«Яһүдиләр [Гозәер [галәйһиссәлам], йөз ел үле калганнан соң терелтелеп, югалган Тәүратны яздырды. Соңыннан Тәүрат табылгач, аның яздырганына хәрефкә-хәреф туры килгәнен күреп алар]: «Гозәер – Аллаһының улы», – диде. Насаралар исә [Гайсәнең [галәйһиссәлам] атасыз яратылу һәм гадәттән тыш могҗизаларын күреп]: «Мәсих – Аллаһының улы», – диде. Аларның бу [бернинди дәлилгә таянмыйча, фәкать] авызлары белән сөйләгәннәре элекке кяфер булган [аталарының һәм, шулай ук, фәрештәләргә Аллаһының кызлары, дигән мөшрик] кешеләрнең сүзенә охшый. Аллаһы аларны һәлак итсен! Алар никадәр тайпылганнар».**

«Әт-Тәүбә», 9:30

Шушы адашкан бәндәләрнең ялган инануларын Аллаһы Тәгалә «Әл-Ихлас» сүрәсендә дә кире кага:

قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ ﴿١﴾ اللَّهُ الصَّمَدُ ﴿٢﴾ لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ ﴿٣﴾ وَلَمْ يَكُن لَّهُ كُفُوًا أَحَدٌ ﴿٤﴾

**«[Расүлем!] Әйт: «Ул Аллаһы – бердәнбер. Аллаһы – [бернәрсәгә дә] Мохтаҗ булмаучы. Ул тудырмаган һәм тудырылмаган. Һич беркем Аңа [бер яктан да охшаш, иш һәм] тиң түгел».**

«Әл-Ихлас», 112

Ягъни кешеләрдән аермалы буларак, Аллаһы Тәгаләнең балалары юк һәм Ул моңа мохтаҗ да түгел.

Гозәер галәйһиссәламнең тормыш мисалы безне бары Аллаһы Тәгаләнең генә Кодрәткә ия булуы, Аның ярдәмчеләргә мохтаҗ түгеллеге хакында өйрәтә. Раббыбыз теләгән бәндәсен гомереннән мәхрүм итә яки кабаттан терелтә, Ул тулы бер халыкларны җәзага тарта яки гафу итә ала, шуңа безнең гыйбадәтләребез бары Бер Аллаһыга гына булырга тиеш. Исраил улларының бер өлеше исә Гозәер галәйһиссәламне Аллаһының улы дип атыйлар, илаһи Бердәмлек турында оныталар, адашу юлына басалар. Ислам дине гыйбадәт кылырга лаек Зат бары Аллаһы булуы хакында белгертә: Раббыбыз күкләрне вә җирләрне яраткан, Ул барлык галәмнәр белән идарә итә, Аңа охшаш һәм тиңдәш булган башка затлар юк. Әлхәмдүлилләһ, бездә Кәлам Шәриф турында хакыйкый белемнәр бар. Аллаһы Тәгалә безгә дөрес инану юлыннан бару өчен тәүфыйк бирсә иде.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

# Нәсыйхәт

# Тәмугның рәвеше һәм тәмуг әһелләре бүлеге

Факыйһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Тәмуг уты кызарганга кадәр мең ел яндырылды. Моннан соң агарганга кадәр икенче мең ел буе яндырылды. Соңыннан каралганга кадәр янә мең ел ягылды. Ул ут караңгы кич кебек карадыр».

Язид бине Мәрсәд радыяллаһу ганһедән риваять ителде. Дөреслектә, Язиднең ике күзенең яшьләре киселми торган, ягъни һәрвакыт елаган хәлдә булды. Язидтән бу хакта соралды. Ул болай дип әйтте: «Әгәр Аллаһы Тәгалә миңа яман вәгъдә кылган булса иде: «Әгәр мин берәр гөнаһны кылган булсам, мине мәңгегә мунчага япкан булса иде», – дип, яшьләрем киселмәскә хак булган булыр иде. Дөреслектә, миңа өч мең ел кыздырылган утка ябарга яман вәгъдә кылды. Минем яшьләрем ничек киселсен».

Факыйһ радыяллаһу ганһе Мөҗәһид радыяллаһу ганһедән риваять итә. Мөҗәһид радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Дөреслектә, җәһәннәм өчен чокырлар булыр. Ул чокырларда дөя муеннары кебек еланнар һәм тимер төсле ишәкләр кебек чаяннар булыр. Җәһәннәм әһеле бу еланнардан качар. Аларны үзләренең әгъзалары, ягъни иреннәре белән алырлар. Чәч арасын тырнакка кадәр тырнарлар. Аларны ул еланнардан бернәрсә коткармас, мәгәр утка качу гына коткарыр».

Габдулла бине Җөбәер радыяллаһу ганһедән, ул Пәйгамбәребездән риваять итте. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дөреслектә, утта дөя муеннары кебек еланнар булыр. Ул еланнар бер ялау белән тәмуг әһеленең берсен тешләсәләр, ул кеше кырык ел тешләүнең авыртуын табар. Дөреслектә, утта ишәкләр кебек чаяннар

булыр. Әгәр алар берсен тешләсәләр, кырык ел ул тешләүчең авыртуын сизәр».

Әгъмәштән, ул Зәед бине Вәһһәбтән, ул Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһедән риваять итә. Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Дөреслектә, сезнең бу утыгыз тәмуг утыннан җитмеш өлешенең бер өлешедер. Әгәр безнең бу ут диңгездә ике мәртәбә батырылса, ул уттан һичнәрсә файда ала алмас».

Мөҗәһид болай дип әйткән: «Дөреслектә, бу утыгыз җәһәннәм утына сыгыныр».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Газап йөзеннән ут әһеленең иң җиңеле бер ир өчен булыр. Ул ирнең аякларына уттан ике башмак кидерелер. Бу ике башмактан аның мие кайнар, гүя ул кешенең колак алкалары, тешләре утлы күмердер, аның керфекләре ут ялкыннарыдыр. Аның эч майлары ике аягыннан чыгар. Дөреслектә, ул кеше ут әһеленең иң катысы дип күрелер, ләкин ул газап йөзеннән ут әһеленең иң җиңеледер», – дип әйткән.

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Мөхәммәд бине Фадел миңа үзенең иснәде белән Гамр бине Гастан сөйләде. Ул болай дип әйтте: «Дөреслектә, ут әһеле Мәликне дәшерләр, аларга кырык ел Мәлик килмәс, моннан соң килер һәм әйтер: «Сез торучыларсыз, ягъни мәңге бу тәмугта торырсыз».

Моннан соң үзләренең Раббыларына дога кылырлар: «Әй, Раббыбыз, безне ул тәмугтан чыгар. Әгәр без дөньяга кайтсак, беренче кебек булмас идек. Без үзебезгә золым кылучыларбыз». Аллаһы Тәгалә аларга ике мәртәбә дөнья булып торган заман кадәр җавап бирмәс. Соңыннан аларга Аллаһы Тәгаләнең фәрманы[1] килер: «Ул тәмугта рәхмәттән ерак булыгыз һәм сөйләшмәгез».

[1] Әмере (ред).

Гамр бине Гас болай дип әйткән: «Аллаһы белән ант итеп әйтәм, бу сүздән соң кавем бер сүз дә сөйләшмәс, моннан соң сызгыру һәм утта аваз гына булыр. Аларның тавышлары ишәкләр тавышына охшар, ул ишәк тавышының беренчесе сызгыру, ахыры ачы аваздыр».

Катәдә болай дип әйткән: «Әй, кавем, сезнең моннан котылу бармы? Моның өчен сезнең түземлегегез бармы? Әй, кавем, Аллаһы Тәгаләгә итагать сезнең өчен җиңелрәктер, Аллаһыга буйсыныгыз».

Әйтелде: «Дөреслектә, ут әһелләре мең ел кычкырырлар һәм аларга бу кычкыру файда китермәс». Моннан соң әйтерләр: «Без дөньяда булганда сабыр итсәк, үзебезнең максатыбызга ирешә идек, сабыр итик». Алар мең ел сабыр итәрләр, ләкин аларга газап җиңеләймәс».

Әйтерләр: «Безгә түзсәк тә, түзмәсәк тә, барыбер. Безнең өчен котыла торган урын юк. Алардан сусау һәм газапның катылыгы бетсен өчен, Аллаһыдан мең ел яңгыр сорарлар. Мең ел үткәннән соң да ялынсалар, Аллаһы Тәгалә Җәбраил галәйһиссәламгә әйтер: «Нәрсәне сорыйлар?» Җәбраил әйтер: «Әй, Аллаһым, Син Үзең аларны белүчерәк. Дөреслектә, алар яңгыр сорыйлар». Аларга кызыл болыт чыгар һәм алар яңгыр яудырылыр, дип уйларлар. Аларга ишәкләр кебек чаяннар җибәрелер. Ул кавемнән берсен чаксалар, аңардан авыртуы мең ел китмәс. Моннан соң Аллаһы Тәгаләдән мең ел яңгыр җибәрүне сорарлар. Аларга кара болыт чыгар. «Бу болыт яңгыр болыты», – дип әйтерләр. Өсләренә дөя муены шикелле еланнар җибәрелер, һәр тешләгән саен ул тешләүнең авыртуы мең ел китмәс. Бу эш Аллаһы Тәгалә сүзенең мәгънәсе: «Аларга бозыклык кылган нәрсәләре өчен, ягъни көферлек һәм Аллаһы Тәгаләгә гөнаһ кылганнары өчен газап өстенә газап арттырдык».

Бер кеше Аллаһы Тәгаләнең газабыннан котылуны һәм Аллаһы Тәгаләнең савабына ирешүне теләсә, аңарга дөньяның катылыкларына түзү, Аллаһы Тәгаләнең тәгатендә булу, гөнаһлардан һәм дөнья теләкләреннән саклану лязем булсын, чөнки җәннәт ул күңел авыруы

күрә торган эшләр белән, җәһәннәм исә нәфес теләгән нәрсәләр белән чорналды. Бу хакта хәбәрдә килде.

## Шигырь

Картлыкта акыллы кешене сабыйлыктан тыя торган нәрсә булучыдыр.
Һәр кайчан аның чигәсендә картлык уты кабынса.
Тереклектән яхшылыкны өмет итә торган ирне-кешене күрәмен.
Һәр кайчан иген сабагы яшәргәннән сон саргайса,
Явыз дустан саклан һәм аңарга тоташудан саклан.
Әгәр аннан качып котылыр хәлең булмаса, аңарга яхшы мөгамәлә кыл.
Яхшы дуска күрше бул. Яманыннан саклан.
Ул яхшы дустан, дуслыкның иң сафына ирешерсең.
Әгәр үзеңә яманлык кылмасаң.
Һәр кайчан күрше булсаң, кеше төсле кешегә һәм һәр кешегә күрше бул.
Тырыш һәм яхшы булган кешегә, аның күршелеге белән күтәрелерсең.
Әгәр берәр әһеленнән башка кеше белән, югарыда әйтелгәнне кылса,
Ул яхшы дусны табыр, ягъни яхшы дуслыкны диңгез, яки Һуд тавы артында да һич таба алыр.
Аллаһы Тәгаләнең күкләр киңлегендәге җәннәте бар.
Мәгәр ул җәннәт күңелгә мәкруһлар белән төрелгән.

Факыйһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итте. Дөреслектә, Пәйгамбәр болай дип әйтте: «Аллаһы Тәгалә Җәбраил галәйһиссәламне чакырып, аны җәннәткә җибәрде. Аллаһы Тәгалә аңа болай дип әйтте: «Җәннәткә һәм аның әһеленә

әзерләнгән нәрсәләргә кара. Җәбраил кайтты һәм болай дип әйтте: «Синең куәтең белән ант итәм, аның хакында ишетүче анда керергә тырышыр». Моннан соң Аллаһы Тәгалә аны авырлыклар белән уратып алды һәм Җәбраил галәйһиссәламгә болай дип әйтте: «Ул җәннәткә кайт һәм аңа кара». Җәбраил кайтты һәм болай дип әйтте: «Синең көчең белән ант итәм, дөреслектә, ул җәннәткә һичкем кермәс дип куркам». Соңыннан Аллаһы Тәгалә Җәбраилне җәһәннәмгә җибәрде. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте: Ул җәһәннәмгә һәм аның әһелләренә әзерләнгән нәрсәләргә кара». Җәбраил Аллаһы Тәгаләгә кайтты һәм болай дип әйтте: «Синең көчең белән ант итәм, ул җәһәннәмне ишеткән һәркем анда кермәскә тырышыр». Моннан соң Аллаһы Тәгалә җәһәннәмне төрле ләззәтләр белән уратып алды болай дип әйтте: «Ул җәһәннәмгә кайт һәм аңа кара». Җәбраил галәйһиссәлам кайтты һәм: «Синең олуглыгың һәм гыйззәтең белән ант итәм, мин анда кермәгән һичбер кеше калмас дип куркам, мәгәр ул җәһәннәмгә керерләр», – дип әйтте.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять ителә. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Тәмугтан теләгән нәрсәгезне искә алыгыз. Сез ул тәмугтан бер нәрсә дә искә ала алмассыз, мәгәр сөйләгән нәрсәне генә. Ул сөйләгән нәрсәгез сезнең искә алуыгыздан катырактыр».

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Әти үзенең иснәде белән Мәймүн бине Мәһраннан риваять итә. Ул болай дип әйткән: Бу аять иңгән вакытта: «Дөреслектә, җәһәннәм аларның барчасының яман вәгъдә кылынган урыныдыр», Сәлман башына кулын куйды, өч көн качып чыкты, аның көче җитмәде, хәтта аны китерелгәнгә чаклы».

Язид Рәкаши Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән риваять итте. Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Бервакыт Җәбраил галәйһиссәлам килә торган вакытларында Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә төсе үзгәргән хәлдә килде. Пәйгамбәребез аңа: «Ни булды сиңа? Төсең үзгәргәнен күрәм», – диде. Җәбраил галәйһиссәлам:

«Әй, Мөхәммәд, мин сиңа Аллаһы Тәгалә ут өргечләренә утка өрү белән әмер иткән вакытта килдем. Дөреслектә, җәһәннәм, кабер газабы зур дип белгән кешегә җәһәннәмнән тыныч булганчыга кадәр елаудан туктау тиеш булмас. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әй, Җәбраил, миңа җәһәннәмне сыйфатла, ягъни бәян ит», – диде. Җәбраил галәйһиссәлам болай дип җавап бирде: «Ярый, сыйфатлармын. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә җәһәннәмне яраткан вакытта аны кызарганчыга кадәр мең ел яндырды. Моннан соң агарганчыга кадәр янә мең ел яндырды. Моннан соң тагын мең ел яндырды һәм ул тәмуг каралды. Ул тәмуг кара һәм караңгылаучыдыр. Аның ялкыны һәм аның утлы күмерләре сүнми. Сине хаклык белән җибәргән Зат белән ант итәмен, ул тәмугтан энә күзе шикелле охшашы булса ачылса да, дөнья кешеләре ул тәмугның кызуыннан актыгына кадәр көяр иде. Сине хаклык белән җибәргән Зат белән ант итәм, әгәр тәмуг әһеленнән киемнәреннән бер киеме җир белән күк арасында бәйләнсә, аның сасылыгыннан һәм кызулыгыннан җир йөзенең бөтен әһеле ахырына кадәр ул тәмугның кызулыгыннан тапкан һәм татыган сәбәпле, әлбәттә, һәлак булырлар иде. Сине хак Пәйгамбәр итеп җибәргән Зат белән ант итәм, әгәр чылбырдан булган бер аршын кадәр, ягъни Аллаһы Тәгалә Үзенең китабында искә алынган чылбыр тауга куелса, әлбәттә, җиденче кат җиргә җиткәнчегә кадәр батар иде. Сине Пәйгамбәр итеп җибәргән Зат белән ант итеп әйтәм, әгәр кеше мәгърибтә газапланса, мәшрикъта булган кеше ул тәмуг газабының катылыгыннан һәлак булыр иде. Ул тәмугның кызулыгы каты, чокыры тирән, зиннәтләре тимер, эчемлеге эссе су һәм эрен, киемнәре ут кисәкләредер. Ул тәмугның җиде ишеге бар, һәр ишек өчен ул тәмугның әһеленең ирләреннән һәм хатыннарыннан бүленгән өлеш булыр». Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ул ишекләр безнең ишекләребез кебекме?» – дип сорады. Җәбраил галәйһиссәлам: «Юк, безнең ишек кебек түгел, шулай да ул ишекләрнең кайберсе кайберсеннән түбән хәлдә ачылган, бер ишектән

икенче ишеккә кадәр җитмеш еллык юлдыр. Ул тәмугтан булган һәр ишек үзенә якын булган ишектән кызулык ягыннан җитмеш өлеш катырактыр. Ул җәһәннәмгә Аллаһы Тәгаләнең дошманнары сөрелер. Әгәр ул дошманнар җәһәннәмнең ишегенә туктасалар, аларны забанилар чылбырлар һәм богаулар белән каршы алыр. Чылбырлар белән беркетелер, һәр кеше шәйтан белән бер чылбырда иптәш кылыныр. Аның йөзе өстенә кыздырылып басылыр, фәрештәләр аны тимердән булган чукмарлар белән бәрерләр», – дип җавап кайтарды.

«Җәһәннәмнән чыгарга теләгән вакытларында ул тәмугка кайтарылырлар». Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу ишекләрдә торучылар кемнәр?» – дип сорады. Җәбраил галәйһиссәлам: «Иң түбән ишек: анда икейөзлеләрдер һәм мәидә сәхабәләре җөмләсеннән ышанмаган кешеләр, янә Фиргавен әһеленнән булган кешеләр, ул түбән ишекнең исеме «Хәүийә»дер. Икенче ишектә Аллаһыга ширек китергән кешеләр. Бу икенче ишекнең исеме «Җәхим». Өченче ишектә йолдызларга табынучылардыр, ул ишекнең исеме «Сәкар». Дүртенчесе: анда Иблистер һәм аңа иярген кешеләр, аның исеме «Ләза». Бишенче ишектә яһүдиләр, аның исеме «Хутамә», – дип җавап бирде.

Моннан соң Җәбраил галәйһиссәлам Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән оялганлыктан туктады. Пәйгамбәребез аннан: «Йә, син миңа җиденче ишекнең торучыларыннан хәбәр бирмәссеңме?» – дип сорады. Җәбраил галәйһиссәлам: «Анда синең өммәтеңнән тәүбә кылмастан вафат булган зур гөнаһ ияләре», – дип әйтте. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм һушы китеп егылды. Җәбраил галәйһиссәлам аның башын, аңына килгәнчегә кадәр үзенең күлмәк итәгенә куйды. Аңына килгәч, Расүлуллаһ: «Әй, Җәбраил, кайгым зур иде, хәсрәтем катыланды. Йә, минем өммәтемнән берәр кеше утка керерме?» Җәбраил галәйһиссәлам: «Әйе, синең өммәтеңнән булган зур гөнаһ әһеле керер», – диде. Моннан соң Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм Җәбра-

ил галәйһиссәлам елаштылар. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең урынына кереп, кешеләрдән яшеренде, беркая да чыкмый торган булды, мәгәр намазга гына чыга иде. Кергәндә һичберәү белән сөйләшмәде, намазда еларга тотынды, Аллаһыга ялварды. Өченче көнне аның янына Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе килде, ишеге янында туктады. «Әссәләмү галәйкүм, әй рәхмәт йортының әһеле! Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә юл бармы?» – диде. Аңа беркем җавап бирмәде, ул елаган хәлдә китте. Гомәр радыяллаһу ганһе килде, ишек төбендә туктады. «Әссәләмү галәйкүм, әй рәхмәт өенең әһеле! Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына юл бармы?» – диде. Аңарга беркем җавап бирмәде, ул да елаган хәлдә китте. Сәлман Фәриси ишеккә юнәлде, туктап әйтте: «Әй, рәхмәт йортының әһеле, әссәләмү галәйкүм! Хуҗам Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә юл бармы?» Аңарга беркем җавап бирмәде. Бер мәртәбә елаган хәлдә, икенче мәртәбә елаган хәлдә юнәлде. Шул рәвешчә Фатыйма радыяллаһу ганһәнең йортына килде, ишеккә туктады, моннан соң: «Әй, Расүлуллаһның кызы, сиңа сәлам», – диде. Гали радыяллаһу ганһе өйдә юк иде. Сәлман радыяллаһу ганһе: «Әй, Пәйгамбәр кызы, дөреслектә, Расүлуллаһ кешеләрдән яшеренде, ул намазга гына чыга, беркем белән сөйләшми, беркемгә аның янына керергә рөхсәт бирми», – дип әйтте. Фатыйма радыяллаһу ганһә мамык бөркәнчеккә төренде һәм Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өенә юнәлде, хәтта Расүлуллаһ ишегенә тукталды, моннан соң сәлам биреп әйтте: «Әй, Расүлуллаһ, мин – Фатыйма». Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәҗдәдә елаган хәлдә булды. Ул башын күтәрде һәм: «Күзем нуры Фатыймага ни булды, миннән юк булды, аның өчен ишекне ачыгыз», – диде. Аның өчен ишек ачылды һәм ул керде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә караган вакытта каты елау белән елады, чөнки аның саргайган, үзгәргән хәлен күрде. Елаудан һәм хәсрәттән үзенең ите ашалган иде. Ул: «Әй, Расүлуллаһ, сиңа ни нәрсә инде?» – диде.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әй, Фатыйма, миңа Җәбраил галәйһиссәлам килде, миңа җәһәннәм ишекләрен сыйфатлады һәм хәбәр бирде. Дөреслектә, җәһәннәмнең иң югарысында минем өммәтемнән булган зур гөнаһ ияләре булыр. Бу мине хәсрәтләндергән һәм елаткан нәрсәдер», – диде. Фатыйма радыяллаһу ганһә: «Әй, Расүлуллаһ, алар ничек җәһәннәмгә кереләр?» – дип сорады. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Алар кермиләр, ләкин аларны фәрештәләр утка сөрерләр. Аларның йөзләре кара, күзләре зәңгәр булмас. Аларның авызларына мөһер дә басылмас, шәйтаннар белән иптәш тә кылынмас, аларга чылбырлар һәм богаулар да салынмас», – дип җавап бирде. Фатыйма радыяллаһу ганһә: «Әй, Расүлуллаһ, аларны фәрештәләр ничек җитәклиләр?» – дип сорады. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Ирләрне сакалларыннан, хатыннарны чәч толымнарыннан һәм маңгай чәчләреннән, минем өммәтемнән булган күпме картлар сакалларыннан алыныр һәм утка җитәкләнер. Ул кеше кычкырыр: «Әй, картлыгыбыз, әй зәгыйфьлегебез». Яшьләрнең күбесе сакалларыннан алынып утка сөрелер һәм ул кычкырыр: «Әй, яшьлегебез, әй күркәм кыяфәтебез». Өммәтемнән булган хатыннарның күбесе маңгай чәченнән алыныр һәм ул хатыннар, аларны Мәлик туктатканга кадәр: «Әй, хурлыгыбыз, әй пәрдәләребезнең ертылулары», – дип кычкырырлар, һәркайчан Мәлик аларга караса, фәрештәләргә әйтер: «Болар кем? Миңа явызлардан болардан гаҗәбрәге килмәде, аларның йөзләре каралмаган, күзләре дә зәңгәрләнмәгән, авызлары мөһерләнмәгән, шәйтаннарга иптәш тә кылынмаган, аларның муеннарына богаулар, чылбырлар салынмаган». Фәрештәләр әйтерләр: «Без аларны бу хәлдә сиңа китерүгә әмер кылындык». Мәлик алардан: «Кем сез?» – дип сорар. Икенче бер хәбәрдә янә риваять ителде. Дөреслектә, ул кешеләр аларны фәрештәләр җитәкләгән вакытта кычкырырлар: «Әй, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм, аһ!» Мәликне күргән вакытта, ул Мәликнең мәһабәтлегеннән Мөхәммәд

салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исемен онытырлар. Мәлик алардан: «Сез кем?» – дип сорар. Алар: «Без Коръән иңдерелгән кешеләр җөмләсеннән һәм без Рамазанда ураза тота торган кешеләр», – дип җавап бирер. Мәлик: «Коръән иңмәде, мәгәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәтенә генә», – дип әйтер. Әгәр Мөхәммәд исемен ишетсәләр, кычкырырлар һәм: «Без Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтеннән», – дип әйтерләр. Мәлик алардан: «Сезне Аллаһы Тәгаләнең гөнаһларыннан Коръәндә тыючы булмадымы?» – дип сорар. Әгәр аларны җәһәннәм авызында туктатсалар, алар сакчыларга һәм утка карасалар: «Әй, Мәлик, безгә рөхсәт бир, үзебез өчен елыйк», – дип сорарлар. Аларга рөхсәт бирелер. Алар күз яшьләре белән, хәтта аларның яшьләре калмаганга кадәр еларлар, аннан соң кан белән еларлар. Мәлик: «Әгәр бу елау дөньяда Аллаһы Тәгаләдән курыкканнан булса, нинди яхшы һәм гүзәл булыр иде. Сезне бу көндә ут тотмас иде», – дип әйтер. Аннары Мәлик сакчыларга: «Аларны утка ташлагыз», – дип әйтер. Аларны һәркайчан утка ташласалар, барысы да: «Ләә иләәһә илләллааһ», – дип кычкырырлар. Алардан ут кайтарылыр. Мәлик: «Әй ут, аларны тот», – дип әйтер. Ут: «Ничек аларны тотыйм? Алар «ләә иләәһә илләллааһү» дип әйтәләр», – дип җавап бирер. Мәлик утка: «Аларны ал», – дияр. Ут: «Ничек аларны алыйм? Алар «ләә иләәһә илләллааһ» дип әйтәләр», – дияр. Мәлик болай дип әйтер: «Анысы дөрес, әмма Гарешнең Раббысы болай әмер кылды», һәм аларны ут алыр. Алар җөмләсеннән шундый кеше булыр: аны ут ике аягына кадәр алыр; һәм алар җөмләсеннән шундый кешеләр: аларны ут ике тезгә кадәр алыр; алар җөмләсеннән шундый кешене бөеренә кадәр алыр, алар җөмләсеннән шундый кешене бугазына кадәр алыр, һәркайчан ут ул кешенең йөзенә җитсә, Мәлик: «Аларның йөзләрен яндырма, алар дөньяда күп вакытта Аллаһы өчен сәҗдә кылдылар. Аларның калебләрен дә яндырма, чөнки алар Рамазан аенда сусадылар. Бу тәмугта алар Аллаһы теләгән кадәр генә калырлар», – дип әйтер. Әйтерләр: «Әй, рәхмәт

кылучыларның рәхмәт кылучырагы, йә Хәннән, йә Мәннән». Әгәр Аллаһы Үзенең хөкемен кылса, болай дип әйтер: «Әй, Җәбраил, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәтеннән булучы гөнаһлылар ни кылдылар?» Җәбраил галәйһиссәлам болай дип әйтер: «Әй, Аллаһым, Син аларны Үзең белүчерәксең». Аллаһы Тәгалә болай дип әйтер: «Бар, аларның хәленә кара». Җәбраил галәйһиссәлам Мәликкә барыр, ул Мәлик җәһәннәмнең уртасында уттан булган минбәрдәдер. Әгәр Мәлик Җәбраил галәйһиссәламгә караса, Җәбраил галәйһиссәламне олылау йөзеннән торыр һәм: «Әй, Җәбраил, бу урынга сине нәрсә кертте?» – дип сорар. Җәбраил галәйһиссәлам: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәтеннән булучы гөнаһлы җәмәгатькә нәрсә эшләдең?» – дип сорар. Мәлик: «Аларның хәле нинди авыр, аларның урыннары нинди тар. Дөреслектә, аларның тәннәре яндырылды, аларның итләре ашалды. Аларның йөзләре һәм калебләре генә калды. Ул калебләрдә иман ялтырады», – дип әйтер. Җәбраил галәйһиссәлам: «Алардан катлауны күтәр, аларга карыймчы», – дияр. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип сөйләде: «Мәлик хәзинәчеләренә боерыр, ул хәзинәчеләр алардан катлауны күтәрерләр. Ул газаплы кешеләр һәркайчан Җәбраил галәйһиссәламнең күркәм холкына карасалар, дөреслектә, аның газап фәрештәләреннән түгел икәнен белерләр һәм: «Мондый күркәм һичберәүне күргәнебез юк, бу кол кем булыр?» – дип сорарлар. Мәлик: «Үзенең Раббысына хөрмәтле булучы, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә вәхи белән килүче Җәбраил галәйһиссәламдер», – дип җавап бирер. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исемен ишетеп, барчасы да: «Әй, Җәбраил, бездән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сәлам укы, аңа хәбәр бир. Дөреслектә, безнең гөнаһларыбыз синең белән безнең араны аерды. Янә син аңа хәлебезнең яманлыгы белән хәбәр бир», – дип кычкырырлар. Җәбраил галәйһиссәлам китәр һәм барып Аллаһы Тәгаләнең каршында торыр. Аллаһы Тәгалә: «Мөхәммәд салләллаһу

галәйһи вә сәлләмнең өммәтен ничек күрдең?» – дип сорар. Җәбраил галәйһиссәлам: «Әй, Аллаһы, аларның хәле авыр һәм аларның урыннары тарлыгы ни гаҗәеп», – дип әйтер. Аллаһы Тәгалә: «Синнән бер нәрсә сорадылармы?» – дип сорар. Җәбраил галәйһиссәлам: «Әй, Аллаһы, дөрестән дә, минем үзләренең пәйгамбәрләренә сәлам бирүемне һәм аларның яман хәлләреннән хәбәр бирүне сорадылар», – дип җавап бирер. Аллаһы Тәгалә: «Бар, ул Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә хәбәр бир», – дип кушар. Җәбраил галәйһиссәлам Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә барыр. Ул ак энҗедән ясалган чатырдадыр, ул чатырның дүрт мең ишеге бар, һәр ишекнең алтыннан ике канаты булыр. Җәбраил галәйһиссәлам: «Әй, Мөхәммәд, дөреслектә, сиңа гөнаһлы җәмәгать яныннан килдем. Алар синең өммәтеңнән утта газап кылынучылар, алар сиңа сәлам укыйлар һәм: «Ни яман безнең хәлебез, ни гаҗәеп тар урыныбыз», – дип әйтәләр», – диде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гареш астына килер һәм сәҗдә кылган хәлдә егылыр. Аллаһы Тәгаләгә сәна әйтер, ул шундый сәна ки: аның кебек Аллаһыга беркем дә сәна әйтмәде. Аллаһы Тәгалә аңа: «Башыңны күтәр, сора һәм сиңа бирелер, шәфәгать сора, шәфәгать кылынырсың», – дип әйтер. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әй, Аллаһым, дөреслектә, минем өммәтемнең явызларын тотып бетердең һәм алардан ачуыңны алдың һәм алар хакында миңа шәфәгать кыл», – дип әйтер. Аллаһы Тәгалә аңа: «Дөреслектә, алар хакында шәфәгать кылдым, утка кил һәм аннан «ләә иләәһә илләллааһ» дип әйтүчеләрне чыгар», – дип әйтер. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм барыр. Мәлик, Пәйгамбәребезне күреп, Расүлуллаһны олылау өчен аягүрә басар. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Явыз өммәтемнең хәле ничек?» – дип сорар. Мәлик: «Ни гаҗәеп, аларның хәлләре яман һәм ни гаҗәеп, аларның урыннары тар», – дип җавап бирер. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ишекне ач, катлауны күтәр», – дияр. Ут әһелләре Мөхәммәд салләллаһу галәйһи

вә сәлләмне күреп, барчасы да кычкырырлар һәм: «Әй, Мөхәммәд, дөреслектә, ут безнең тиреләребезне яндырды һәм йөрәкләребезне яндырды», – дип әйтерләр. Аларның барчасын Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм тәмуггтан чыгарыр. Дөреслектә, алар күмер булып чыгарлар, дөреслектә, аларны ут ашады. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларны җәннәт ишеге төбендә елгага алып китәр, ул «Тереклек елгасы» дип аталыр. Алар бу елгада госел алырлар, аннан сакалсыз-мыексыз, сөрмәләнгән яшь булып чыгарлар. Аларның йөзләре ай кебек булыр, маңгайларына «җәһәннәмиләр, Аллаһының уттан азатлары» дип язылыр. Җәннәткә керерләр, һәркайчан ут әһелләре мөселманнарның уттан чыкканнарын күрсәләр: «Аһ, без дә мөселман булсак иде, без дә уттан чыгарылган булыр идек», – диярләр. Аларның бу теләкләренә Аллаһы Тәгаләнең сүзе дәлилдер:

رُّبَمَا يَوَدُّ الَّذِينَ كَفَرُوا لَوْ كَانُوا مُسْلِمِينَ ﴿٢﴾

**«Кяфер булган кешеләрнең [үлем вакытында һәм Кыямәт көнендә] мөселман буласылары килер, бәлки».**

«Әл-Хиҗр», 15:2

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять ителде. Ул болай дип әйтте: «Үлемне китерерләр, ул үлем ак тәкә кебек булыр. Әйтелер: «Әй, җәннәт кешеләре, үлемне беләсезме, танышсызмы? Ул үлемгә карарлар һәм аны танырлар. Әйтелер: «Әй, ут кешеләре, үлемне беләсезме, танышсызмы?» Аңарга карарлар һәм аны танырлар. Үлем җәннәт белән җәһәннәм арасында бугазланыр. Моннан соң әйтелер: «Әй, җәннәт әһелләре, сезгә үлемнән башка мәңге калу. Йә, ут әһеле, сезгә үлемнән башка мәңге калу».

Моны Аллаһы Тәгаләнең сүзе исбатлый:

وَأَنذِرْهُمْ يَوْمَ الْحَسْرَةِ إِذْ قُضِيَ الْأَمْرُ وَهُمْ فِي غَفْلَةٍ وَهُمْ لَا يُؤْمِنُونَ ﴿٣٩﴾

**«[Расүлем!] Аларны бөтен эшләрнең [һәм Ахирәт хисапларының] карар бирелгән вакыты, кайгы көне турында кисәт. Әмма [син никадәр кисәтсәң дә] алар гафләт эчендә һәм алар [Ахирәткә] ышанмыйлар да».**

«Мәрьям», 19:39

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһә болай дип әйткән: «Фәҗир[1] һич нигъмәткә алданмасын, чөнки ул фәҗирнең артында яман теләүче булучыдыр. Ул теләүче – җәһәннәмдер».

كُلَّمَا خَبَتْ زِدْنَاهُمْ سَعِيرًا ﴿٩٧﴾

**«Сыеначак урыннары – җәһәннәм ки, [аның ялкыны аларның тиреләрен һәм итләрен көйдергәннән соң] сүнә башлаган саен Без [аларга өр-яңа тиреләр һәм итләр биреп] аның ялкынын арттырырбыз».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:97

Аллаһы Тәгалә Белүчерәктер.

*«Тәнбиһүл гафилин» китабыннан*

1 Гөнаһ кылучы (ред).

# Әдәби сәхифә

**Кукмара мәдрәсәсе мөдире Ришат хәзрәт Курамшин дини журналист һәм язучы буларак билгеле. Аның динебез кыйммәтләренә, яшәешебезнең төп максатына, әдәп-әхлак вә тәрбия мәсьәләләренә багышланган хикәяләре һәм публицистик язмалары милләттәшләребезгә инде яхшы таныш, ә бу юлы исә Ришат хәзрәт редакциягә шигъри вәгазь формасындагы дини эчтәлекле шигырьләрен юллаган. Шуларны укучыларга тәкъдим итеп, мөхтәрәм имамнар һәм абыстайлар әлеге шигъри вәгазьләрне мәхәлләдәшләренә ирештерерләр дигән өметтә калабыз.**

*«Хозур» редакциясе*

**ГОМЕР ЕЛГАСЫ**

Еллар, көннәр сулар кебек ага,
Талгын ага гомер елгасы.
Үз юлыннан киләчәккә таба
Тагын күпме аңа агасы?

Белмибез шул күпме тәкъдирләнгән,
Агым безне кая илткәнен…
Беләбез тик алда һәммәбезне
Иксез-чиксез дәрья көткәнен.

Безнең теләк-уйга карамастан,
Агым мәңгелеккә юнәлә…
Шулай алдан билгеләнгән тәкъдир
Аллаһ язган белән үтәлә.

Елга ага… Кайчак тын дулкыннар
Хәвефләнеп алга ашкына.

Кайчак ярга бәргәләнеп ала,
Килеп чыкса киртә каршыга.

Кайвакытта ачы күз яшьләре
Хыял ярларына түгелә.
Ләкин тукталырга һич ярамый –
Агым янә алга юнәлә…

Бу елганың ярларында күргән
Төрле вәсвәсәгә кызыгып,
Без саташсак – Аллаһ гел коткарды,
Дөрес юнәлештә агызып.

Ий Раббыбыз! Инде ничә тапкыр
Мәрхәмәтең илә коткардың:
Төшеп китә язгач зур упкынга,
Туры юлда безне калдырдың.

Елгабызда Иман көймә булсын,
Тәкъвалык белән барыйк ишеп,
Ә азакта шатланырга язсын
Кәүсәр елгасына ирешеп…

**АВЫРЫП КИТТЕ КАРДӘШЕМ…**

Авырып китте кардәшем,
Шуңа читкә куеп бар эшем,
Ашкындым тизрәк янына –
Тынгы салам диеп җанына.
Хәбәре бик шомлы булды,
Чарасыздан күңелем тулды…
Дустымның хәле авыррак:
Яман шеш таптылар, диде… рак…
Тиз килеп җиттем өенә.
Моңайды ул кайгы көенә:
– Шундый хәл… – диде аптырап,
– Көтмәгәндә булдым бит харап…
Шушылай гыйбрәт алганчы,
Уйлап карамадым моңарчы:
Яшәрмен озак янәсе,
Ә янымда – үлем шәүләсе…
… Дәшмичә утырдым әүвәл.
Дөрестән дә – шактый авыр хәл…
Күзләрендә тик бер сорау:
– Нигә миңа булды бу сынау?!
Нигә мин? Мин яшь бит әле!
Тормышның кызыклы һәр мәле…
Моңарчы яшәдем рәхәт,
Каян килеп чыкты бу зәхмәт?
… Карашым төбәп идәнгә,
Әйттем: Аллаһ безне сөйгәнгә
Саулыкны бирә һәм чирне –
Насыйп итеп тик хәерлене.

Аллаһның хөкеме кырыс,
Тик тәкъдиргә ышану – фарыз!
Раббыбыз кадир, шәфкатьле,
Ни бирсә дә – бул итагатьле.
Ирештеме сиңа зәхмәт –
Бел: монда ниндидер бар хикмәт.
Тоймасаң да җан рәхәте,
Авыру – Аллаһның рәхмәте.
Моңарчы ваемсыз булдың,
Онытылып, тик дөнья кудың,
Авыргач – исеңә төшә
Бөек Раббың... Ул сиңа дәшә:
– Күп чаптың инде, әй колым!
Үз-үзеңә кылдың күп золым:
Раббыңны искә алмыйча,
Күңелеңне дингә салмыйча,
Туры юлдан читкә китеп,
Кыйммәт вакытны әрәм итеп...
Бу дөнья – вакытлы торак,
Яшәп булмый монда бик озак,
Иң күбе – сиксән-туксан ел,
Соңыннан исә – мәңгелек... Бел!
Бу тормыш кайчандыр бетәр,
Һәммәбез ахирәткә китәр.
Шунысы зур әһәмият –
Яшәүнең максаты, төп ният...
Аллаһның бәндәсе булсаң,
Тормышның максатын аңласаң,
Күпме гомер бирелсә дә,

Бүген үлсәң дә, терелсәң дә,
Син инде бәхетле кеше –
Хәерлегә була һәр эшең!
«Нигә мин, ник миңа?» – дисең,
Шушы хәлгә китмәсен исең!
Якынаерга Раббыңа
Ярдәм итә авыру… Шуңа
Кайгырма китте дип саулык,
Гыйбадәтсез ул – шикле байлык.
Аллаһның рәхмәте олы,
Тик Аның ихласлы бул колы.
Иң зур байлык – ихлас иман,
Аллаһның ярдәменә инан!
Биргәненә шөкер итсәң,
Ризалыгын алып яшәсәң,
Ярдәменнән Ул ташламас,
Авыр хәлдә сине калдырмас…
Ул моны бит вәгъдә итте,
Бер әйтүе дә безгә җитте.
Аңа тәвәккәлләп яшә,
Якын дус-туганнар – янәшә!
Шунысы да мөһим, кардәш:
Раббыңа син дога кылып дәш!
Саулык сорарга бар хакың,
Бел: Аллаһ һәрвакыт бик якын!
Теләсә – шифасын бирер,
Авыру дәвасын белдерер.
Юк икән – моны кабул ит,
Бу хөкемгә риза булып кит…

Аллаһка итагать итсәң,
Кабул итеп иманлы китсәң,
Кыены дөньяда калыр,
Ахирәттә әҗере булыр.
Барысын да була бирсәң,
Шул әҗернең кыйммәтен белсәң!
...Шулай да, син әле исән
Һәм нишлим икән хәзер дисәң,
Хаталарың барлап бөтен,
Аллаһыдан син гафу үтен.
Кем хакын боздың – бәхилләш,
Һәрберсе белән күреш, сөйләш,
Мөмкинлек булганда төзәт
Башкалар белән мөнәсәбәт.
Тәүбәгә кил. Кичер. Аңла...
Күңелеңне өметкә багла,
Ләкин бу дөньяга түгел –
Ахирәткә ашкынсын күңел!
Хак максат, чын бәхет анда –
Фәкать мәңгелек тормышында!
Иманлы кешене көтә
Искиткеч яшәеш җәннәттә...
Раббыңа син ихлас ышан
Һәм зыян салмасын шайтан,
Нәфеснең кылына тиеп,
Гадел түгел бу хөкем, диеп.
Барысы алдан язылган,
Шайтан сүзе – вәсвәсә, ялган!
Шушы хәл – бары тик сынау

Тугрылыкка… Шуңа – бул уяу:
Раббыңа тугры булып кал,
Бу дөньяны корбан итеп «чал»!
Барысын Аллаһ хәл итә,
Бәхетле булырга Ул җитә…
…Күтәрде башын кардәшем
Һәм елмаеп сөртте күз яшен,
– Мең шөкер Раббыма! – диде,
– Мин бүтән кайгырмамдыр инде,
Аллаһым бар икән минем,
Туры юлны күрсәткән динем,
Аллаһтан ихлас сорармын,
Син әйткәнчә, дога кылырмын…
Ахыргы нәтиҗә – Аннан,
Мәрхәмәтле, юмарт Раббымнан.
Ни булса да – кабул итәм…
Ә сине – иртәгә дә көтәм.
Килмәсәң – шалтырат, эндәш!
Ярый син бар әле, әй кардәш!
Зур рәхмәт: килеп яныма,
Нурлы бүләк салдың җаныма…
Аллаһның рәхмәте яусын,
Дуслыгыбыз мәңгелек булсын.

**ЯУЛЫК**

Яулык ябу мөслимәләр өчен фарыз,
Фарыз, димәк, бөек Аллаһ шулай кушкан.
Тыйнак, тыныч, имин яшәр өчен яулык
Хатын-кызга гомер буе бик булышкан.

Абыстайлар шушы хакта болай диләр:
«Яулык – ул мөслимә өчен калкан кебек,
Ул шәһвәтле, азгын карашлардан саклый,
Шуңа күрә без яланбаш һич йөрмәдек!».

Кызлар яулык япса – гүзәл, нурлы була!
Егетләрнең начарлары моны күрми,
Тәртиплеләр исә «Сүбхәнәллаһ!» диеп,
Шундый кызга никахланам дип ниятли.

Яулык саклый, яулык ул бәхетле итә,
Әй мөслимә, син яулыктан аерылма!
Гыйбадәттә булып, баштан гына түгел –
Күңел яулыгыңны да син салма.

## КАЙТУ

Зина кылам диеп өйдән чыккан егет,
Ап-ак эчке кием сайлап кигән…
Күңеленнән иман качкан мәлдә
Ул шайтанга: «Әйе, ярар», – дигән.
И шатланды мәлгунь, «җиңдем» диеп моны
Һәм үзенә вәгъдә бирдертеп,
Аның күңелендәге аклыкны
Арт ягына куйды кидертеп.
И рәнҗеде, и хурланды мескен аклык!
Нәүмиз калып, үксеп елады…
Егет исә моңа төшенмичә,
Янә шайтан юлын сайлады.
«Бу мәсхәрә хәлгә ничек төштең соң син?
Миңа һаман пычрак атасың.
Син оныттыңмыни, бәндә, тиздән
Ахирәткә кире кайтасын?
Дәрт-теләкне басу өчен синең Раббың
Рөхсәт иткән хәләл юлны сайлап,
Мине рәнҗетмичә гамәл кылып,
Була иде тормышыңны җайлап!»
Шулай дия-дия һай сукранды аклык,
Хыялланып җанга кайтырга.
Ә хуҗасы… артын өстен күреп,
Нәфсен әйләндерде батырга.
Гает көнне дусты кыстап «әйдә» дигәч,
Килде егет Җәмигъ мәчеткә,
Әй утырды ул кыбырсыкланып,
Килеп капканмыни читлеккә…

Вәгазь бик үтемле булды. Имам әйтте:
«Зина – ӘҖӘТ ул, кем аны алыр,
Соңрак бу әҗәтне Аллаһыга
Үз туганы белән кайтарыр.
Бу турыда ышанычлы бер хәдистә
Аңлатыла – җәза шул булыр:
Килер вакыт – зина кылучының
Балаларын кемдер аздырыр»...
Уйга батты егет. Кайтыр юлын күрми...
Биләп алды җанын зур хәсрәт!
«Тик үкенсәң – Аллаһ гафу итә» –
Шулай диде кебек бу хәзрәт...
Кинәт туктап калды егет һәм тезләнде,
Ихлас тәүбә аны елатты...
«Кичер, Раббым!» – диде һәм шул мәлдә
Аклык күңеленә кире кайтты.

**БӘХЕТ СУЫ**

Без калада гомер итсәк тә, бу
Табигатьтән тәмам ваз кичерми:
Шәһәр янын бераз күрми торсаң,
Иләсләнгән күңел тынгы бирми…
Шулай бер көн килдем мин чишмәгә
Ни дисәң дә, чишмә суы – сихәт!
Гомер бакый аккан шушы суга
Карап торулары да бик рәхәт.
Миннән ерак түгел, янәшәдә
Утыра иде бер ир башын иеп.
Ыспай кыяфәтле, тик карашы
Әйтә иде: «Хәлем мөшкел…» – диеп.
Су тутыргач, кайтам дип кузгалдым,
Ләкин нигәдер сизмәстән үзем
Ир алдында туктап, аңа дәштем:
– Аллаһ хакы өчен – син бул түзем…
Шушы минем сүзне көткән сыман
Егет кинәт елап ук җибәрде:
– Авыр миңа бу тормышта, – диде, –
Язмыш сыртка инде байтак бәрде…
Бик бәхетсез тоям мин үземне…
Өйдә рәт булмагач, монда килдем…
Аны-моны сораштырмый гына,
Мин бу иргә шулчак болай дидем:
– Бәхет бит ул – четерекле нәрсә!
Беләсеңме аның сере нидә?
Мисал итеп бер баланы алыйк:
Аның таянычы – тик әнидә.

Безгә дә яклаучы һәм ярдәмче
Бу тормышта кирәк, бик тә кирәк!
Ә кем соң ул? Беләсеңме? Аллаһ!
Безгә тик Ул ышанычлы терәк!
– Моны, агай, ишеткәнем булды, –
Диеп җавап бирде боек тавыш, –
Садакалар да биргәлим үзе,
Тик барыбер язмыш кәүсәм авыш…
Күргәннәрне уйлап өзгәләнәм,
Нәрсә ул тынгылык – җаным белми…
Ямыйм дисәм тормыш ертыкларын –
Җебе туры килсә, сабы килми…
…Артык сорау биреп төпченмәдем,
Күңел хәлне болай да аңлады:
Бахыр бәндә шушы көнгә кадәр
Үз кыйбласын әле дә тапмады…
Шуңа күрә дәвам итеп әйттем:
– Әгәр өлкән яшьтәге әңкәңә
Елга бер мәртәбә акча биреп,
Кайтып калса дикъкать шул тәңкәңә,
Аның алда булган бурычыңны
Син үтәдем диеп хисаплама!
Шулай ук садака биреп кенә
Аллаһ хакын үтим дип уйлама…
Раббың сиңа ярдәм итсен өчен,
Булсын өчен ышанычлы терәк,
Ризалыгын алу максат итеп,
Гомер буе тырышырга кирәк.
– Гомер буе? Миннән булмастыр бу, –

Диде егет яшьле күзен сөртеп, –
Дөнья эшләреннән дөм читләшеп,
Барлыгымны тик дин белән өртеп…
– Беркем әйтми: «Дөнья  эшен ташлап,
Көн-төн намазлыкта утыр», – диеп,
Иң мөһиме – Аллаһ яратканны
Син дә яшә гомер буе сөеп!
Әгәр керсә Иман күңеленә,
Әрнү һәм борчылу аннан китәр,
Ни булса да, җан газабы тоеп,
Җәфаланып яшәү тәмам бетәр…
Син «Ләә иләәһә илләллаһ» диеп,
Нәрсә кирәк – бер Раббыңнан сора!
Бу тормышның уңыш-сәгадәте
Фәкать Аллаһыдан гына тора…
Һәм Аллаһтан башка илаһ юк дип
Кеше чын Бәхеткә ия була,
Чөнки һәр гамәле, бар тормышы
Шуннан соң хак мәгънә белән тула…
…Челтерәп аккан чишмә тавышына
Олуг кәлимәнең яңгырашы
Кушылудан гайрәтләнде җиһан,
Балкып китте ирнең күз карашы…
Бу мизгелдә аның күңеленнән
Еллар буе азаплаган хәсрәт
Гүя очып китеп юкка чыкты,
Һәм ул баш калкытып әйтте: – Хәзрәт…
Бу ни хикмәт: синең сөйләвеңнән
Нәрсәдер үзгәрде күңелемдә…

Тынычландым... Шактый уйландыра...
Тик... «аждаһа» көтә бит өемдә...
– Тынычланып уйлануың яхшы.
Ә «аждаһа» өйдә түгел – җанда!
Аны фәкать Иман ярдәмендә
Җиңеп була – бар ышаныч шунда...
Әгәр күңелеңдә Иман булса,
Анда шайтан инде ояламас,
Курку, рәнҗү, низаг һәм үкенү
Пәриләре оя кора алмас.
Изге-игелекле маяк булып
Якты өмет балкыр – шуңа инан:
Аллаһ ярдәменнән һич ташламас,
Күңелеңдә булса ихлас Иман...
Тынсуланыр дөнья, тынар хатын,
Яши башлар бәхет, шәт, өеңдә,
Шайтан-мәлгунь тормышыңны бозмас,
Ихлас Иман булса күңелеңдә.
Аңлашыла: бу дөньяда сынау,
Кыенлыклар да булмыйча калмый,
Ләкин Аллаһ ярдәм итсә, иблис
Дөрес юлдан тайпылдыра алмый.
Күңел төшкән вакытларда һәрчак
Бер Аллаһка тәвәккәлләп торыйк,
Олуг Рәхмәтенә өмет итеп,
Ярдәменнән ташламавын сорыйк.
– Гаҗәп... – диде ир-ат, – бу сүзләрең
Җәфаланган җанны нурландырды...
Күңелемдә туган якты өмет

Чирле барлыгымны савыктырды…
…Шуннан аның белән кайтып киттек,
Юлда әле байтак күп сөйләштек,
Ә бераздан шәһәр мәчетендә
Җомга намазында без күрештек.
Вәгазь бик үтемле булды. Имам
Җәмәгатькә дәшеп болай диде:
– Кем Иманга ия булды, шуның
Өлешенә олуг файда тиде!
Нинди файда? Күңел тынычлыгы,
Кылган гамәл өчен әҗер-савап,
Нурлы, сәгадәтле тормыш юлы,
Кыяматтә – ансат, җиңел җавап…
Ә аннары – мәңгелектә – Иман
Җәннәт капкасына булыр ачкыч…
Бу дөньяда да һәм ахирәттә
Бик бәхетле итә бу Ышаныч!
…Без шул көнне җомга намазыннан
Шактый әсәрләнеп кайтып киттек.
Ә соңыннан… байтак күрешмичә
Тормыш юлыбызны дәвам иттек.
…Берничә ай узды. Йомшак карлар
Бар дөньяны ак юрганга төргәч,
Күңел табигатькә талпынганга,
Киттем мин чишмәгә. Шунда килгәч,
Искитмәле кышкы күренешкә
Өнсез карап тордым гаҗәпләнеп:
Карлы туннар кигән зур агачлар
Тора иде бәстән көмешләнеп…

Кояш нурларында җем-җем килеп,
Салкын чишмә суы ага иде…
Онытылып басып торган мәлдә
Кемдер җилкәм кагып: «Агай…» – диде.
Башым борып баксам – теге ир-ат…
Ә янында – бик мөлаем хатын…
«Менә шушы инде – кулыбызга
Тоттыручы «ислам» дигән алтын!
Әйе, мин сөйләгән абзый шушы!» –
Диде егет миңа таба ымлап,
Һәм йөзендә шатлык чагылдырып,
Ул күреште ихлас ике куллап.
Шуннан соң хәл-әхвәл сораштыргач,
Читтә яшәгәне ачыкланды.
– Синең телефонны алмаганга
Хатын әрләп, ай-һай ачуланды!
Без хәзер икебез дә намазда,
Торган җирдә дини гыйлем алдык,
Аллаһ бәрәкәтләр насыйп итеп,
Кайтып, ике катлы коттедж салдык…
Намаз уку чыннан да үзгәртә:
Җанны да, фикерне дә, тормышны…
Гыйбадәттә булсаң, бөек Аллаһ
Бирә бар нигъмәтне һәм уңышны.
Ә иң зур нәтиҗә – күңел тыныч!
Ни булса да – һәрчак без догада.
Аллаһ разый булса, Бәхет суы
Чишмә кебек ага да ага да…

*Ришат Курамшин,*

*Кукмара мәдрәсәсе мөдире*